
Закир Әкбәров
Акча исе

Закир Әкбәров

Кумертауской центральной библиотеке от З. Н. Акберова с большим уважением к работникам библиотеки и к её читателям.
З. Акберов
16.09.2021г

# Акча исе

Кумертау, 2021



# *ИҖАТЫНА ИҖТИМАГЫЙ ҺӘМ ФӘЛСӘФИ ПРОБЛЕМАЛАР ХАС*

*Язучы Закир Әкбәровның чәчмә әсәрләренә күзәтү*

Укытучы, журналист, язучы Закир Әкбәровның исеме укучыларга
яхшы таныш. Ул 1947 елның 4 мартында Куерганы районының Зәк-
Ишмәт авылында туган. Стәрлетамак дәүләт педагогия институтын
тәмамлап, туган районына эшкә кайта. Гомеренең үндүрт елы
мәктәпттә үтә. Унике ел буе Күмертау шәһәрендә совет һәм партия ор-
ганнарында җаваплы вазыйфалар били. 1994 елдан бирле журнали-
стикада. Төрле елларда «Кызыл таң»ның үз хәбәрчесе, «Кумерта-
уское время» гәзите мөхәррире була.
Хаклы ялга чыккач та Закир Насыйр улы җәмәгать эшчәнлеге
белән актив шөгыльләнә. Берничә тапкыр Күмертау районы һәм
шәһәре советлары депутаты булып сайланды. 2012 елдан – Күмертау
шәһәре ветераннар советы рәисе.
1999 елдан – Русия һәм Башкортстан журналистлар берлекләре,
2004 елдан Башкортстан Язучылар берлеге әгъзасы. «Аллам сакла-
сын!», «Әрем исе» китаплары, «Почтальон малае», «Еллар һәм
юллар», «Тимергалиннар» романнары һ. б. әсәрләр авторы. Хәким
Гыйләҗев, Баязит Бикбай, Илдар Юзеев исемендәге әдәби преми-
яләргә лаек булды.
Быелтыр Закир Насыйр улына Күмертау шәһәр округы советы ка-
рары белән «Күмертау шәһәренең шәрәфле шәхесе» исеме бирелде.
Өлкән каләмдәшебезне котлап, киләчәктә дә иҗат илһамы телибез.
Төрле елларда «Кызыл таң»ның үз хәбәрчесе, «Кумертауское
время» гәзите мөхәррире булып хезмәт иткән иҗатчы каләменә
публицистик башлангыч, документаль ачыклау-
фәлсәфи уйланулар, проблемаларны эченә алган
лар хас. Иҗтимагый һәм фәлсәфи проблемаларны эченә алган
хикәяләренең бер өлешендә үткен сатирик фашлау өстенлек итсә, икен-
челәре җиңелчә юмор белән язылган. «Томанлы таңнары», «Әбек-
сюҗәтләр», «Акча исе» кебек әсәрләр З. Әкбәровның язучы буларак сю-
жетны кора белү, әдәби тел мөмкинлекләрен куллану маһирлыгын та-
гын да калкурак күрсәтә.
Соңгы берничә ел эчендә язылган «Почтальон малае» повесте,
«Еллар һәм юллар» романы әдәбият сөючеләрдә шактый зур кызыксы-
ну уятты. Романы өчен язучыга И. Юзеев исемендәге әдәби-
иҗтимагый премия тапшырылды. Аерым бер циклны тәшкил иткән,

автобиографик элементларга мул булган бу әсәрләренең беренчесендә 1950 еллардагы татар авылы сурәтләнсә, икенчесендә 1960 еллардан бүгенге көнгә кадәр вакыйгалар урын ала һәм алар армиягә, шәһәргә дә күчә. Ике әсәрдә дә төп герой авторның үзе белән тәңгәлләшә һәм барлык вакыйгалар диярлек аңа мөнәсәбәтле бирелә, я хикәяләүченең аларга карата уй-фикерләре ачып салына. «Почтальон малае» повесте «балачак, үсмерлек чоры кичерешләренә» нигезләнсә, «Еллар һәм юллар» романы «геройның өлгергәнлек чорына хас уйлануларын» колачлый. Ил тормышы, Кремль, обком турында уйланулар әсәрдә шактый урын били, ягъни эссе жанры алымнары мул чалымлана, бер үк вакытта эпик колачлыкка, «киң планлык»ка дәгъва ителә.

З. Әкбәровның «Почтальон малае» повесте Заһит исемле биш-алты яшьлек малайның балачак хатирәләре рәвешендә бирелсә дә, әсәр өлкәннәр тормышындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне ача. Хикәяләү күзәтүчән, зирәк һәм һәр күргәнен акылына сеңдереп, нәтиҗәләр ясап баручы Заһит күзлегеннән алып барыла һәм берничә юнәлештә үсеш ала: тапкыр, чая Мөнзил, беркатлы Карам, җиңел гәүдәле, өлгер Әсгать кебек малайларга бәйле сюжет сызыгы тирә-як белән танышу белемне генә түгел, баланың үзен дә сынап караучы мәктәп чынбарлыгы нигезендә тормыш авырлыгы иртә төшкән малайларның беренче чирканчык алуы рәвешендә үсә.

Балачакның якты, җылы хатирәсе икенче сызыкка – гаилә, нәсел-нәсәп җебенә күчә барган саен катлаулана, төрләнә. «Гаилә риваяте» дип бирелгән вакыйга-хәлләр, өлкәннәрнең үзара мөнәсәбәтләрен чагылдырган мизгелләр Заһитның тормышка, тирә-яктагыларга мөнәсәбәте формалашуга этәргеч ясый. Җитмешкә узган картның биш яшьлек малае булып, әтисеннән иртә укырга-язарга өйрәнеп, ике әнидән иркәләнеп үскән Заһитның дүртенче сыйныфка күчкәндә «почтальон малае» булу чоры да, әсәрдәге вакыйгалар чылбыры да тәмамлана: әтисе үлә, Габделнасыйрның кечкенә Заһитка тормыш кануннарын сабый күңеле кабул итәр дәрәҗәдә төшендерүе, ялгыш адым ясаудан сак булырга өйрәтүе атаның гаиләсен якларга омтылуы, малайның киләчәген фаразлавы буларак гомумиләшә.

Габделнасыйр егәрле, шаян телле, ачык күңелле, үзсүзле ир итеп гәүдәләндерелә. Шактый хәлле тормыш алып барган, җирне ялгыз эшкәртеп, уникe кешеле гаиләсен туендырган Габделнасыйрның колхозлашу чорында Себергә озатылудан котылып кала алуы да, ике хатын белән тормышына риза булулары да хәлиткеч вакыйгалар чылбырын тәшкил итә. Барлык мөлкәте тартып алынгач, иген эшкәртүдән читләшеп, хат ташучы булып эшли башлавы бу чордагы



иҗтимагый гаделсезлекләрне башка яктан сурәтләргә мөмкинлек бирә. Чорның катлаулы, болгавыр еллары, фаҗигага китерер сәбәпләренең гадилеге бала күңелендә күп сорауларга урын калдыра.

Герой әтисенең үзсүзлелеген күрсәтүче ике вакыйганы искә төшерә. «Хуҗа Насретдин», «Насыйр бай» кушаматларының асылын ачып салырлык тарихны сөйли. «Авызын ачса, үпкәсе күренергә торган Габделнасыйрга бирер кызыбыз юк!» дип, Габдрахман Нәфыйга исемле сеңлесен кияүгә бирергә риза булмый, егерме елдан артык вакыт үткәч тә гарьлеген оныта алмыйча, кырык ике яшен тутырган Габделнасыйр Габдрахман мәзиннең Мәрзия исемле кызын икенчегә хатынлыкка ала. Бу, беренчедән, Габделнасыйрның үзсүзлелеген күрсәтсә, икенчедән, халыкның тормышта булачак үзгәрешләрне чамалавын ачыклый: указлы мулла Габдрахман үзе кебек байларның көне бетеп барганлыгын яхшы сиземли: Мәрзиясен ышанычлы кулга тапшырып каласы килә.

Икенче очрак Габделнасыйрның өй алу вакыйгасына бәйле. Совет власте тарафыннан кысылуга көннән-көн ныграк дучар була барган авыл бае Габдрәфыйкның Урта Азиягә китәргә мәҗбүр булып, өен-мөлкәтен сатарга җыенганда төрле фаразлар арасында халыкның «Ай-һай Габдрәфыйк байның бусагасы биек, Габделнасыйр, анда менеп җитәлмичә, мәтәлеп төшеп муенын сындырмагае», дигән сүзе ирнең горурлыгын ярсытып җибәрә. Габделнасыйр өен, ун эш үгезенең алтысын, елкы көтүенең бер өлешен сата, сандык төбендәге маясын чыгара, көз җиткәндә инде гаилә авылның аргы очыннан бирге очтагы Габдрәфыйк бай өенә күчә.

Әсәрдә авыл кешеләре, аларның үзара мөгаләмәсе дә хикәяләүче геройның әтисе Габделнасыйр сызыгына бәйле ачыла: акылга загыйфьрәк Ринат, җитез Мөкәрәмә түти, саран, кызсыз Мотыйгулла, сүзчән Сафа образлары чор картинасын тудырырга ярдәм итә. Укый-яза белмәгән исәр Ринатның көн саен диярлек дәфтәренең куш битен дулкынлы сызыклар белән бизи-бизи, өчпочмакка бөкләп, җеп кәтүгеннән сыдырып алынган түгәрәкләрне марка урынына ябыштырып, кемгә булса да хат «язып» почтальонга тапшыруы – үткәннәрнең кайтавазы рәвешендә, совет чорындагы доносчыларга, шымчыларга аллегория буларак кабул ителә.

Шулай итеп, Закир Әкбәровның «Почтальон малае» повесте сабыйлык чорын кичергән малайның күңел байлыгын, тормышның әтиле чорын матур хатирәләрдә, авыр елларның фәһемле вакыйгалары фонында тергезә.

Язучының «Еллар һәм юллар» романы 2018 елда үзнәшер юлы белән басылып чыкты. Әсәр социалистик җәмгыять тудырган идеалларга ышанган, партия йөкләгән бурычларны үтәү барышында система кимчелекләрен ныграк ачыклаган, үз карашларын үзгәртергә мәҗбүр булган герой тарихы кебек кабул ителә. Әсәр үзәгендә – мәгариф системасының төрле баскычларын үткән, коммунистлар партиясенең вазыйфалы урыннарында эшләгән, соңыннан газет һәм язучылык эшенә күчкән Фазыл Габитович Хәйдәровның язмышы. Күләмле әдәби материал үзенчәлекле формага төрелгән: роман язучы һәм аның язылачак әсәренең төп персонажы булырга дәгъва итүче герой арасындагы ике атнага сузылган сөйләшү, аралашу, бәхәс рәвешендә бирелгән. Шактый тәҗрибә һәм акыл туплаган, кырык ике ел намуслы хезмәт иткән, уннан артык китап авторы булган язучының «заман герое» эзләү барышында калыккан хатирәләре үз тормышына нәтиҗә ясау кебек кабул ителә. Хатыны Камиләгә «Без синең белән әдәби геройлар була алмыйбыз, чөнки тормышта тирән фаҗигаләр кичермәдек», дигән сүзләрне яшәлгән елларына бәя, тормыштагы гаделсезлекләрне искә төшерү кире кага. Совет идеологиясе тарафыннан тудырылган күзаллауларның чынбарлыкка ерак булуы хакыйкатькә әйләнә.

Романдагы төп сюжет сызыгы геройларның студент һәм яшь елларын бәян итә. Камилә белән Фазыл, икеләнүләрен җиңеп, ымсындыргыч мизгелләрне үтеп кавышалар, бер ул белән бер кыз үстерәләр, оныклар тәрбиялиләр. Фазыл төрле җитәкче урыннарда эшли, заман каршылыкларын кичәләр, үткәндәге идеалларга шикләнеп карау чорына аяк басалар.

Студентлар тормышын, иҗади мохитне җентекле сурәтләү, укытучы һөнәренең нечкәлекләрен, җитәкчеләрнең холык-фигылен уңышлы ачу, геройларның характерын гына түгел, чор картинасын тудыруга да ярдәм итә. Ил күләмендә барган вакыйгалар, төрле үзгәрешләр турында хикәяләү укучыны биздермәслек итеп чама белән бирелгән. Әсәрдә «заман, чор тудырган авырлыклар өчен аерым шәхесләр җаваплы» дигән фәлсәфи фикер тоемлана. Фазыл алдында торган киртәләр, сынаулар артында ялган Ватан сугышы ветераны Фәхриев, шикаятьчеләр, педагогик хезмәт ветераннары Кыямова белән Сайрановадан башлап, Министрлар советындагы Хашимов, беренче секретарь Бирюковларга кадәр кылган мәкерле эпгамәлләр тора. Әйтерсең, Солтанов, Айтуганов, Байназаровлар, су өстендә йөзгән көймә суга капланмасын өчен тигезлекне саклау максатыннан алар янәшәсендә яшәргә дучар ителгәннәр. Кешелек



җәмгыятенең чынбар-лыкны кабул итүдәге ешлыклары төрле булу чүплектә казынучы «намуслы фәйләсуф», зиннәтле сарай янында кечкенә алачыкта яшәп яткан элекке бай түрә Мисбах язмышында ачык күрсәтелә.

Әсәр ахырында хикәяләүче чынбарлыктан шактый ерак дөньяда яшәүче, уйлап чыгарылган герой Фазылны үзе дөрес дип танырга кыючыскан хакыйкатькә ышандыра. Киләчәккә өметен югалтмаган, дөрес яшәдем микән, дигән сорау өстендә кат-кат уйланган ир үзенең дә әсәр герое булырга хакы барлыгына ышанса да, ялган акчага сатылган дөнья башка заман героен – әрсез шома типны таплан, үз әсәренә керткән. Нәтиҗәдә, яшәешнең кырәшкән торуы, шуна да үзең сайлаган юлдан тайпылмау – ялганны, гаделсезлекне җиңеп чыгуның бердәнбер юлы дип раслана, кеше һәм җәмгыять арасындагы бәрелеш һичкайчан туктамас алышны хәтерләтә башлый.

Язучының былтыр матбугатта басылган «Тимергалиннар» романында да 1970–1980 еллардагы, ягъни үзгәртеп кору чорына кадәрге авыл тормышы тасвирлана. Әсәрдәге вакыйгалар колхоз рәисе һәм аның өч улына бәйләп бәян ителә. Иҗтимагый яңгырашлы вакыйгалар белән берләштән язучы әсәр тукымасына шәхси-интим сызыкны да оста алып бара. Абыйсы белән энесе арасындагы көндәшлек, яшьлек дәрте һәм туганлык җепләре бәрелеше укучыны битараф калдырмый.

Кыскасы, З. Әкбәров әсәрләре тел-бизәкләр белән артык чуарланмаган сөйләме, мавыктыргыч вакыйгалары, халык аңында милли традицияләргә нигезләнеп формалашкан фикерләү куәсе, тапкырлыгы белән укучыларын үзенә тартып тора.

Бу китапка Закир Әкбәровның соңгы вакытта язылган ике әсәре керде: «Акча исе» повесте һәм «Бидрәш илчесе» сатирик романы. Әсәрләрнең икесендә дә заманыбызның гадәти геройлары – авыл һәм шәһәр халкы, хезмәт ветераннары, укытучылар, хокук саклау органнары хезмәткәрләре, кече һәм зур түрәләр – гадәти булмаган хәлләргә тарыйлар. Акча, зур байлык белән бәйле бу сынаулардан ничек чыгалар соң алар? Моның алдан сөйләп укучыларның кызыксыну хисен сүрелтәсе килми. Бары язучының геройлар язмышына бәйле заман проблемаларын күләп тә, җитди дә бәян итүе укучыларны битараф калдырмас дип ышанырга гына кала.

***Альбина Хәлиуллина,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*М. Акмулла исемендәге БДПУ доценты.*

# Акча исе

*Повесть*

## 1

Мәнин тавы артыннан кояш борынын күрсәтте. Ай батып бетмәгән иде әле, төне буе җирне яктыртып йөреп йончуыннанмы, әллә кулдашының шулай балкып килеп чыгуыннан көнләшепме, төсен җуя биреп, Түгәрәк урманы өстендә өерелгән томан арасына кереп яшеренергә чамалады. Сәфәргали карт күтәрмәгә чыгып басты, колачын киң җәеп бер киерелде, бер сузылды, тәү яртылаш чыккан кояш ягына карап ташлады, аннары, күзен кысып, каш сикертеп, ак шәленә төренә биргән айны, сәламлады.

Дөнья матур!.. Менә шушы июнь иртәсенең ямьлелеге белән генә түгел, кояшның һәм айның яктылыгы бар кешегә дә тигез төшүе белән дә матур. Хәер, кулларыннан килсә, кайсы бер бәндәләр алай тигез яктырттырмаслар да, йә булмаса, Хода биргән яшәү чыганакларыннан файдаланган өчен һәр кешегә налог салырлар иде. Уйларының кире юнәлеш ала башлавыннан котылу өчен, йорт хуҗасы яраткан җырын борын эченнән генә көйләп алды: «Ай югары, ай югары, айга менәсем килә. Айга менеп, түбән карап, сине күрәсем килә-ә-ә...»

– Күрәсең килгәч, күр соң, менә бит чыктым. Бер дә әти җибәрми, әни рөхсәт итми дип тормадым, – Сөт чиләген тотып, карты янына чыгып баскан Зөләйха карчык ишек алдын яңгыратып көлеп җибәрде. – Илле дүрт ел элек тә, шушы җырыңны мөңгерәп, авыл артындагы пар каен янында менә шулай минe көтеп ала идең, әле һаман шул гадәтеңне ташлый алмыйсың.

Карчыгының көлүенә карты кушылды.

– Яхшы гадәтне ташламыйлар ул, әнисе. Үзең дә матур, сиңа арналган җыр да матур булгач, нишлим. Дөнья да матур бит!

– Дөньясы аның матур да ул, яңгыр яуса, чоланың түбәсеннән чарлап су ага, мунчаның идәнен алыштырасы бар, мичен яңадан чыгартсаң да мишәйт итмәс иде. Югыйсә, яккан саен төтен, күзләрне әчеттерә.

Сәфәргали карт, күккә күтәрелеп баруыннан туктап, капыл гына җиргә егылып төште.

– Һи, әнисе, әллибез аны... Баш имиң булсын да, кул-аяклар сау булсын...



– Акчасы булмаса да ярыймы?

– Стройматериал алырга акчасы да кирәк шул. Кем әйтмешли, акча бездә бер букча! Июнь пенсиясенең түләүләрдән, чәй-шикәрдән калганын печән хәстәрләүгә тотынсак, июль белән августынынкына кирәкле материаллар алырбыз.

– Кеше яллмаска әйтәсеңме?

– Нигә кеше яллап торыйм мин. Әле дәрманым бар... – Сәфәргали карт сыегая барган беләкләрен селкеткәләп куйды.

Карчыгы аңа мыскыллап карады.

– Йә, ярар, әтәчләнмә. Бар, тизрәк малларыңның астын ал, мина бит саварга да кирәк.



Карчыгы сыер сауган арада карт тавыкларына җем чыгарып сипте. Аларның кыланышын кәлемсерәп күзәтеп торды. Кояш чыгып барганда ук Кызыл әтәчләре кирта башына менеп «Кикрикүк! Кикрикку-үүк!» – дип сөрән сала иде инде. Моны ул көндәлек мәшәкате исәпли. Яисә дә, ул сөрән салмаса, Кояш чыкмаячак. Хәзер аның икенче мәшәкате: үзе дә тукла-ну, тавыкларын да туендыру. Җиргә сибелгән җим арасыннан иң тулы, иң тәмле бөртек сайлап таба да, «Кот-кот-кот» дип яраткан бичәләренең берсенә дәшә. Анысы шундый ук җимне чукуыннан туктый да, йөгереп килеп, әтәч сайлаганын чукып ала. Әтәч, кукраеп, тавыгы тирәсендә бөтерелә, «Корк-корк» дип үзенең булдыклылыгы белән масая. Күңелле күренеш!..

Сыеры белән башмагын көтү җыю мәйданына чыгарганда аның кәефе яхшы иде әле. Тозкүз Гыйлван очрап кына күтәренке кәефен бераз боза төште. Баканыкыдай кабарынкы күзләрен тәү аның маллары ягына юнәлтте, аннары тишәрдәй итеп хуҗаның үзенә карады. Сәлам бирергә дә нияте юк иде, ахрысы. Сәфәргали: «Әссәламмәгаләйкем, Гыйлван кордаш», – дип исәнләшкәч кенә, йөзенә битараф хис чыгарып: «Сәлам, сәлам», – дигән булды. Үзе тагы да Сәфәргалинең сыеры белән башмагын күздән кичерде.

– Симертә беләсең малларыңны, картлач, кабыргалары тырпаеп тормый. Колхоз исән чакта икмәкне тонналап-тонналап каердың шул. Бураларың игене белән дә, оны-фуражы белән дә һаман тулыдыр әле. Ә без мескеннәр?.. – Гыйлван еларга җыенган баладай кул гына селтәде дә, үзенең өч сыеры, биш башмагы ягына ишарә ясады. Бу аның үзенчә мактануы иде. Гомер буе колхоз эшендә сыдырылдың, янәсе, һаман да малларыңны ике баштан

арттыра алмадың. Менә мин колхоз эшенә төкереп тә бирмәдем, авызым гел бал да майда булды.

– Синең дә малларың да, күренеп тора, ярыйсы кышлаганнар, Гыйлван, – Сәфәргали тагы да ни әйтергә дип уйланып торды да, – Теге вакытларда ни колхозга, ни авылга өч тиенлек файдаң тимәсә дә, тартып-сузып яшәмисең... – дип өстәде.

– Әй син, Кызылавыз, минем байлыкны санама, тартсам да үземнеке, сузсам да үземнеке.

– Синеке шул, синеке. Йомран да өенә туплый да туплый бит Аннары берәр төлкегә табыш була да, эзсез-нисез юкка чыга.

Гыйлван яшьтәшенең дә ачырак итеп нидер әйтергә авызын ачкан иде, Сәфәргали аны тыңлап тормады, юлында булды. Аларның бар гомере бәхәстә узды. Яшь чагында Гыйлванның Зөләйхага күзе төшкән иде. Ә армиядән кайтып төшкән Сәфәргали кашыкка салып йотарлык кызны тегенең авызыннан тартып алды. Ай, ул чактагы татлы хисләр, кискен бәрелешләр... Дөрес эшләде Сәфәргали. Зөләйхасы, тегенең әрсезлегенә карыша алмый, аңа чыгып куйса? Күз алдына китерүе дә кыен. Кайчак карт шаяртып та алгалый. Гыйлванга чыкса, янсе, чолан түбәсе дә акмас, мунча идәненә дә шыгырдап торган имән такта түшәлгән булыр, миче дә төтәмәс иде.

Гыйлван хәлле яши. Үз мәшәкате белән генә яши. Хәтта бер күзенә ак төшкән Гашүрәсен дә урамга чыгармый дип әйтерлек. Гомер буе Ырынбур юлын таптап сәүдә итте. Колхозның кайсы бер аркылы яткан байлыгын да урап үтмәде. Шуның белән бәйле бер мәрәкә хәлне авылның өлкән буын кешеләре һаман да онытканнары юк. Колхозга маллар азыгына кушып бирү өчен «мочевина» атлы ашлама кайтартканнар. Бу, форсаттан файдаланып, тоташ бер капчык шул даруны чөлдергән. Дару бит ул микъдарын белеп файдалансаң гына дару, артыгын тамызсаң агуга әйләнә. Гыйлван әлеге капчыкны тоташлае белән утлыкка бушаткан. Иртән абзарына чыгуга барлык малы тәгәрәшеп ята икән. Комсызлык турында сүз чыкканда, авыл халкы гадәтенә: «Тозкүз Гыйлван булдыңмы әллә?..» дип битәрләү кереп калган.

Өчкуянда эче телле халык яши. Гыйлванның башка эгълекләрен дә онытмыйлар. Җәйнең иң кызу вакытында Ырынбур автобусыннан «ах» та «ух» килеп ике капчык күтәреп килеп төшкән бу.

– Нәрсә күтәреп кайттың тагы? – дип кызыксынып икән тукталышта торганнар. Берәү булса, дәшми дә китеп барыр иде. Гыйлван



капчыктан бер шешә алган да тегеләргә күрсәткән. Беләсезме Ырынбурда черегән алмадан әчетелгән бу бормотуха күпме тора? Туксан тиен. Тоташ шешәсе туксан тиен! Ә мин сусап килүче алкашларга төнлөрен аны өч сумга очырам. Бер шешәдән саф табыш ике сум ун тиен. Борыңгыз сизәме инде акча исен? Аңкый бит!..

Тире җыючы вазыйфасын да тоташ бизнеска әйләндереп алган иде ул. Сарык тиресе китерәләр, хәмер колларына ул чыгара да шул шешәсен тоттыра. Хәмерне өнәмәүчеләргә майлы куллары белән кесәсеннән таушалган өчлек чыгарып суза. Берчак аңа үтеп барышлый колхоз рәисе сугылган.

– Гыйлван туган, сарык тиресе ята, әрәм булмасын, диюем.

– Бик хуп, бик хуп, Гомәр абзый, мә...

Алдынгы колхоз рәисе ярлы яшәмәгәндер. Әмма учына төртелгән әлеге өчлекне күргәч, ул да гарьләнгән.

– Соң, Гыйлван, бар авылны алдап яшисең, хет мине, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалерын, райком бюросы әгъзасын, мыскыл итмә инде.

– Бәй җитмәдеме ни, Гомәр абзый, мә тагы бер тәңкә.

Рәиснең әйтер сүзе калмаган, кул гына селтәгән дә «УАЗ»ында гүләтеп китеп барган. Бөкрене гүр генә төзәтә алырына ышанган кеше иде шул ул.

Тагы бер мәзәк хәлгә Сәфәргали әлегрәк үзе шаһит булды. Әлеге автобус тукталышы, әлеге капчык күтәргән Гыйлван.

– Ни алып кайтып киләсең, кордаш.

Тәүдә сәүдәгәр дәшми-нитми генә узып китәргә чамалаган иде. Тик әлеге мактанчыклыгы өскә чыкты, булса кирәк.

– Балта!

– Балта? Үзебезнең «Хозтовар»да тулып ята ич...

– Үзебездәгесе күпме тора? Биш тәңкә... Ырынбурда балтасы тәңкә ярым, сабы – бер тәңкә. Мин «ә» дигәнче балтасын сабына кидерәм дә тәңкә ярым саф табыш эшлим. Акча исеме? Акча исе!..

Болар инде күптән, совет власте чорында ук, булган хәлләр. Кем белә, аз-маз белеме булып, фикерләве дә дөнья кирәк-ярагы белән генә чикләнмәсә, бәлки, ул да бизнесмен булып китәр иде. Юк, китәлмәс иде. Бердән, аның заманы үткән, картлыгы бугазыннан алган, икенчедән, башыннан ашкан көнчеллеге...

Нишләп авылның иң җибәр кызына Гыйлван түгел, Сәфәргали өйләнде? Нишләп Сәфәргалине президиумга утырталар, Гыйлванны

түгел? Нишләп Сәфәргалигә орден бирделәр, Гыйлванга түгел? Гыйлванның акчасы күбрәк, дөньясы баерак ич!

Хәзер инде ул Ырынбурдан арзан товар ташый алмый, икенче төрле кәсеп тапкан. Хәҗәтләре төшкән авылдашларына процентка акча биреп тора. Меңне алдың икән, бер ай эчендә мең ярым итеп түлисең. Рәсәй банклары халыкны талау буенча дөньяның барлык башка илләре банкларын узып киткән. Сәфәргали карт газет тә укый, телевизорда карый, бу турыда бик тә хәбәрдәр. Бурычлыдан ун процент та түләтәләр, егермене дә, вакытында түли алмаса, «пени» атлы штрафын да салалар, хәтта «коллектор» атлы бандитларын да җибәрәләр. Ләкин хәтта алар да Тезкүз Гыйлванга җиткерә алмый. Алар проценты еллап исәпләнә, Өчкуян банкирыныкы - аена илле, димәк, елына – алты йөз. Мең алып бер елга суздың икән – чыгар көшәлегеңнән җиде меңеңне!.. Авыл халкы намуслы бит ул, аны бернинди «коллектор» белән куркытуның кирәге калмый.

Сәфәргали картның ул яктан иманы камил. Әлегә беркайчан да Гыйлванга йомышы төшкәне юк. Төшмәячәк тә!..

Көтү куып кайткач та өенә кермәде әле ул. Карчыгы ут алачыгында «чыж» да «пыж» ниндер әзерли, алачыкның ачык ишегеннән тәмле исләр бар ишек алдына тарала. Әйткәне бар иде бит инде, иртән ашказаннарны яңа үткәрелгән каймаклы чәй белән дә ризалатып була, нигә мәшәкатьләнәсең, дип. Юк, күп еллар механизатор ирен иртән басуга коймак-кыстыбыйлар белән сыйлап җибәрергә, кичен итле аш белән каршы алырга күнеккән шул ул. Хәлиулла мәрхүмнең ялкау Мәмдүдәсе кебек түгел. Иртән – чәй, төшкелеккә – чәй, кичен тагы чәй. Көне буе тузан йотып, җир сөреп кайткан иренне шулай каршы алып кара әле. Хәтта юаш Хәлиулланы да чыгарыннан чыгарырсың. Мәмдүдәсе гадәтенчә:

– Кайттыңдамы, әтисе? Хәзер самавырым кайнап чыгар, рәхәтләнеп утырып чәй эчәрбез, – дип каршы алган икән.

Хәлиулла кызып китеп:

– Синең бетмәс чәеңә төкерим мин, – дип сүгенгән дә, тәтен борхытып утырган самавырны торбасы ние белән бәрәңге бакчасы артындагы буага чыгарып аткан, имеш. Өчкуян халкы бу күңелсез дә, мәзәк тә вакыйганы һаман онытканы юк. Ничек онытсыннар инде? Үткер күзле, чәчән сүзле Валит Мәмдүдә белән Зөләйхага арнап такмак та чыгарган бит: «Хәлиулла Мәмдүдәсе чәй эчә дә «пес» итә, Сәфәргали Зөләйхасы йон эрли дә эш итә». Теге бичә ялкаулыгын



ташлады микән, юк микән, анысы Сәфәргали картка караңгы. Чөнки Хәлиулланың бакыйлыкка күчүенә инде байтак еллар узган. Ә бит алар яшьтәшләр иде. Сәфәргали картның да вак-төяк чирләре юк түгел. Бер акыллысы әйткән ди бит – «Җитмешкә җиткәндә иртән бер җиреңдә сызламый икән – димәк, син үлгәнсең...» Март аенда җитмеш алтысы тулып, җитмеш җидегә китте, әлегә, Аллага шөкер, үз көнен үзе күрә, үз дөньясын үзе көтә.

Әнә бит каз, үрдәк бәпкәләре дә йокыларыннан торып чыккан, бар ихатаны тутырып шаулашалар. Аларның тагарагына кичтән әзерләп куелган болгауны салырга, тыкрыктагы чирәмгә чыгарырга... Озакламый Уфада көн күргән кызы белән кияве кайтып төшәр. Озакка түгел, алар эшле кешеләр, бер-ике көнгә генә. Аның каравы оныклары Эмилияне әбисе белән бабасы карамагына калдырып китәрләр. Күңелле булачак! Бәпкәләрне Җәмиләләре (татар өчен ят исемне алар санга сукмый) карар, көннәр буе шулар белән мәш килер. Былтыр кайтканында:

– Бабай, алар гел генә минем арттан ияреп йөриләр, мине мамалары дип думают, наверное, – дип нәтиҗә чыгарган иде.

– Инкубатор бәпкәләренең әниләре юк шул, кызым, күрәсең шулай уйлыйлардыр, – дип елмайды карт. Әтисе белән әнисе Җәмиләне алып киткәндә:

– Бәпкәләр уже выросли, хәзер алар мине әниләре дип не думают, – диде. – Тик һаман арттан калмый ияреләр...

– Хәзер кемнәре дип уйлыйлар икән соң?

– Сестралары, диптер...

Көлештеләр. Быел инде биш яшен тутырып кайта. Әбисе, бабасының куанычы, юанычы булып кайта. Ай-ай ярым торса, бәпкәләрне дә карашыр, татарчага да юньләбрәк өйрәнер, бабасы белән бергә бозауларын да каршы тауга чыгарырлар.

Быел сыерлары соң, май ае очланып килгәндә генә, бозаулады. Шуңа күрә бозауны әле ихатадан чыгарганнары юк. Печән уртларга өйрәтә генә әле аны карт. Үләннең иң йомшагын, иң хуш ислесен урак белән урып капчыклап алып кайта да, кечкенә көлтәләр бәйләп киртәгә элеп куя. Ике атналык бозау кинәнеп чәмчени. Менә әле дә муенын сузып картның чалбарына кыстырылмаган күлмәк итәген ялмарга чамалый. Әнисенә ошап, аклы-кәрәнле булып дөньяга килгән бозауның карт җилкәсен сыйпый, колаклары арасын кытыклый.

Дөнья ямьле, яшәү тәмле. Җир шарын, аның байлыкларын бүлешеп бетә алмый кыйкылышкан, алтын дип, акча дип аналарын сатып җибәрергә әзер бәндәләр чукынып кына китмиләрме…

Сәфәргали картның таралып-таркалып барган уйларын, ут алачыгыннан килеп чыккан Зөләйхасының яңгыравыклы тавышы бүлде.

– Әтисе, кер инде, чәем кайнады, коймагым пеште…

## 2

Өчкуян авылының исеме җисеменә туры килми, авылы зур, исеме кечкенә. Туры китерик диеме инде, заманында колхозны «Победа» – «Җиңү» дип атаган иделәр дә ул. Хуҗалыкның гөрләп яшәгән, даны республикага яңгыраган заманнары да булды. Алары инде хәзер әлкән буын өчкуянлылар өчен онытылып барган төш кебек, яшьләр өчен – әллә чын, әллә фантазияга бай картлар уйлап чыгарган риваять кенә. Узган гасырның сиксәненче елларында купкан агулы давыл бер колхозны гына таркатып калмады бит, тоташ СССР-ны юкка чыгарды. Сәфәргали картның шифоньердагы кешелеккә кия торган костюмы түшенә тагылган Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почет билгесе» орденнарын, «Хезмәт батырлыгы өчен» медален бик үк санга сугучы юк. Урыс тәресе итеп эшләнгән хәзерге заман орденнарын да бит җир сөреп икмәк үстергәннәр түшенә түгел, җир байлыгын, ил байлыгын талап, миллиардларга хуҗа булганнар түшләренә тагалар.

Әйе, Өчкуян зурдан әкренләп кечерәя барган борынгы авыл. Уңай ягы шул, авылның бирге очына ярты гына чакрым булыр, олы юл үтә. Аннан арырак тимер юлы, ике юл авылга җитмәс борын кисешә. Кисешкән төшләрендә хәтта шлагбаум белән каравылчы будкасы да куелган. Төп героебыз башыннан үтәчәк мажаралар Өчкуянның географик торышы белән бәйле булмаса, боларын, бәлки, җентекләп тасвирламас та идек.

Сәфәргали бер кулына зур капчык төреп алып, икенче кулына урак тотып авыл очына чыкты. Аның печәнлеге ерак түгел, әмма гетне дә (олы юлны халык элеккечә шулай атый), тимер юлны да аша үтеп чыгарга кирәк. Җәй башланып кына тора әле, болындагы үләннең чыгышын да чамалар, бозавына күчти дә алып кайтыр. Хәлеңнән килгән дә булыр иде, җиңел автомобиль алмады ул. Көннәр буе, ал-ял белми, трактор, комбайн кабиналарында сел-



кенә, тәнен машина руле артына утырсынмы? Тәү – ДТ-54, аннары – ДТ-75 тракторлары, СК-3, СК-4, Дон-1500 комбайннары… Колхоз-да иң беренче булып К-700-не үзләштерде. Һай, аның куәте, аның типлеге! Газга ныграк бассаң, «Москвич», «Жигули»ларың бер яктарак торсын! Хәзер инде олы юлда «Жигули» түгел «Волга»сы да юк. Гел берсеннән-берсе текә иномарка. Тизлекләре дә… Куышып, узышып, әллә кая ашыгалар, әллә кая чабалар, юл аша чыгарлык түгел. Карт, берәр аралыгы булмас микән дип, көтә бирде. Озакламый, чынлап та, ерактарак машиналар агымының очы күренгәндәй булды. Күрәсең, шлагбаумны ябып, поезд үткәрәләрдер. Инде дә кыза башлаган асфальтка аяк басарга чамалаган иде, бер әкерттәй ак джип, «выжт» итеп килеп туктап, аның юлын бүлде. Машина ишеге ачылып китте, аннан чәче-башы тузган, футболка-джинсис тиргә манчылган аюдай гәүдәле бер урыс сикереп төште. Чын мәгънәсендә аю! Аюдай бандит!.. Җитмәсә сул кулы беләктән түбән, ашыгыч кына уралган, бинт аша каны саркып чыккан.

Карт куркаклардан түгел, шулай да шөбһәгә төште. Таларга уйлый түгелме соң аны бу юлбасар?!. Көпә көндез. Нәрсәсенә кызыксын? Капчыгы белән урагын тартып алсынмы? Тик ул картка һөҗүм итмәде, хәтта көчәнеп елмайган да булды, әмма күзләре боздай салкын иде.

– Как зовут тебя, старик?

Картның ачуы килде.

– Безнең Өчкуянда тәү кешегә сәлам бирәләр.

– Хәл-әхвәл сорашып торырга вакыт юк. Кабаланам…

– Ярар, Сәфәргали абзыең булам мин, Сәфәргали Байтимеров.

– Сафар… Сафари… Ладно, пусть Сафари. К тебе, мужик, большая просьба. Вот кейс… – Урыс кабинасыннан уртача зурлыктагы чемодан кебек нәрсә алып картка тоттырды. – Спрячь подальше, никому не рассказывай, никому не показывай, не сегодня, так завтра заеду. Только не вздумай меня облапошить. Голову тебе отверну! Если в целости сохранишь, долю отстегну…

Ни эшләсен карт? Ярдәмгә мохтаҗларның үтенечен кире кагып өйрәнмәгән ул. «Отверну»сыннан курканнан, «отстегну» сына кызыкканнан түгел, әнә шул гадәтенә тугрылык саклап:

– Ладно, – диде. – Онытма, Мин – Сафари түгел, Сәфәргали Байтимеров, авылның бу як очыннан бишенче йорт. Пятый дом, аңладыңмы?

Карт аңына килгәндә, теге машина күздән югалган иде инде. Ни булды соң бу? Әллә күзенә генә күрендеме? Алай дисәң кулында әлеге чемодан. Кеше-кара күргәнче аның ышерергә кирәк. Ул кейсны тиз генә капчыгына тыкты. Ул арада машиналар агымы тагы да көчәйде. Юлы уңмасына ышанган карт инде борылып кайтып китергә җыенган иде, тормозын сызгыртып, тагы бер машина килеп туктады. Кап-кара тәрәзәсе төшә бирде. Аннан өлгергән кабактай йомры, такыр итеп кырдырылган бер баш күренде. Тегесе дә бандит, монысы аңардан да текәрәк бандит икәне күренеп тора. Бу нинди көн булды соң әле? Нишләп бандитлар Сәфәргали картны үз иттеләр?..

– Ты давно стоишь здесь, мужик?

Безнең авылда кешегә тәү сәлам бирәләр, дип әйтергә уйлаган иде, әйтмәде. Андыйларга ана сөте белән кермәгәнне, тана сөте белән керми инде ул. Шулай да:

– Яңа гына килдем, – дип җавап кайтарды.

– Белая «Тойота», номер – три семерки, московский регион, проехала?

– Мин – авыл карты, сезнең иномаркаларыгызда, номерларыгызда, регионнарыгызда не разбираюсь. Юк, күрмәдем.

Теге «Кабакбаш» ямьсез итеп сүгенде, карт ягына карап «лач» итеп төкерде дә, сүндерелмәгән машинасының газына басты. Аныса ач арысландай үкереп алга ыргыды.

Әйе, бер-берсен сагынып, бер күрешүгә зар-интизар булып йөрүче дуслар түгел болар. Әлеге шул байлык бүлешүчеләр токымыннан... Аюы кача, Кабакбашы куа, Кабакбашы куа Аюы кача. Сәфәргали капчыгында урын алган кейс өчен микәнни? Вәт галәмәт! Телевизорның НТВ каналында көне-төне күрсәтелгән атыш-үтерешле сериалларның бер ястарак торсын... Карт кышның озын кичләрендә аларны карашатырып утырырга да форсат таба, китап укуны да кечкенәдән яраттты ул. Теге вакытларда мөмкинлеге булмады дип әйтерлек, хәзер сайлап-сайлап кына китабын да укыштыра. Быел кыш Ильф белән Петров дигән әдипләрнең «Унике утыргыч»ы белән «Алтын бозау»ын укыды. Остап Бендер атлы яһүднең мажараларын көлә-көлә, иң кызык җирләрен әбисенә иштерә-иштерә укыды. Ул чакларда да булган, хәзер дә. Тик ул чактагы бур үзе билгеләгән кагыйдә чикләреннән чыкмаска тырышкан. Хәзергеләр өчен бернинди кагыйдә дә юк. Акча исе аларның нәфесен ачыра, акылдан яздыра... Атсалар аталар, кисәләр кисәләр, морадларына ирешү өчен бернинди каршылыклар алдында да туктап калмыйлар...





Сәфәргали карт әлеге мажараны авылдашларыннан берәрсе күзәтеп тормады микән дип, як-ягына каранды. Юк, әле юлга кузгалып өлгермәгәннәр икән. Ул, капчыгын җилкәсенә салып кайтып барганда гына өч-дүрт авылдашы очрап сәлам бирделәр.

– Әссаламмәгаләйкем, Сәфәргали җизни.

– Вәгаләйкем-әс-сәләм, кайниш.

Монысы Зөләйханың ике туган энесе Зәбир булды.

– Исәнмесез, Сәфәргали бабай.

– Саулармы, саулармы, балалар...

Болары мәктәп укучылары. Күрәсең район үзәге Тукмаклыга йомышлары төшкәннәр. Ә бәлки әле, Ырынбургадыр да. Хәзер олысы-кечесе йөреп ята. Олысы-кечесе дә ул, тик Тозкүз Гыйлванга юлда ни калмаган? Өендә генә акча сугып ятмый...

– Сәлам бирдек, колхоз алдынгысына, – диде ул, мыскыллы карашын көндәшенә төбәп.

– Өчкуян банкирының сәламенә сәлам белән җавап бирдек, – диде Сәфәргали коры гына.

– Таңлап кайдан кайтып киләсең?

– Менә Ырынбурга бардым әле, капчык тутырып урак алып кайтып киләм.

Иртән көтү куганда гына очрашканнарын Гыйлван оныткан да иде, булса кирәк.

– Кит әле? Нишләтәсең ул чаклы уракны.

– Сатам. Борынгы заман эш коралы булса да, хуҗалыкта бик кирәк нәрсә бит. Үзебездә юк, Ырынбурда берсе йөз тәңкә. Йөзгә алдым, өч йөзгә сатам. Саф табыш – ике йөз. Байлык синең кесәңә генә агарга тиеш димәгән ич. – Карт мыек астыннан гына елмайды да ары китте. Гыйлван авызын ачып торып калды.

Карчыгы кибеткә чыккан иде, булса кирәк, аныса уңай булды. Нәрсә алып кайттың, печәнең кайда, дип төпченеп маташмас. Веранда тактасында утырган остаханәсе бар аның. Анда верстагы, чүкече белән балтасы, пычкысы белән ышкысы, башка эш кораллары... Шунда керде. Ашыкмый гына кейсны капчыктан чыгарды. Ничек ачыла икәнен чамалап торды. Нәрсә икән бу серле кап эчендә? Дәүләт әһәмиятендәге документлармы? Булмас!.. Ул кәгазьләрнең иминлеген бандитлар тәэмин итәргә тиеш түгел. Алтын-көмешме, асылташлармы? Монысы булырга мөмкин. Сәфәргали карт үз гомерендә кеше

байлыгына кызыкмады. Шуның өчен кейсны ачып карамаска да хәл иткән иде инде. Бүген, йә булмаса иртәгә, диде ич. Килер, алып китәр, шуның белән эш тә бетәр. Баласыннан баш аяк. Ул кейсны, верстак астына урнаштырып, йомычка белән күмеп куйды да, чыгу ягына юнәлде. Тик инде ишеген бикләргә җыенганда хәвефле уй башына китереп суккандай булды. Теге бәндәләр гади бандитлар гына булмый, террорчылыр булса? Әлеге капта шартлаткыч мәтдә ятса? Яки хәрбиләрдән берәр секретный җайланма чәлдергән булсалар?!. Галәмәт!

Сәфәргали карт кире борылды, остаханәсенең ишеген эчтән бикләде, кейсны верстак өстенә алып куйды, тагы уйланып торгандай итте. Ике йозакның ике төймәсенә басканда ирексездән күзләрен йомды. Шартласа, ичмасам, күзләре мәхшәрне күреп өлгермәсен. Бикләнмәгән дә булган, йозаклар «челт» итеп ачылды, шартлау тавышы яңгырамады, ут, төтен бөрхымады. Карт күзләрен ачты. Тартмада!.. Тартмада шыгрым тулы акча иде...

Остаханә эче ят ис белән тулды. Акча исе... Сәфәргали картның күзләре, төтен әчеттергән кебек, яшькә чыланды, куллары пешкәндәй булды. Ул, тартманы ябып, тиз генә верстак астына тыкты, алачыгын ябып бикләп алды, капка төбенә чыкты, хәзиналы тартма хуҗасы күренми микән дип, олы юл ягына күз ташлады. Юк, юлда җилдергән машиналар бихисап, аклары да каралары да җитәрлек, теге өч җиделе ак джип кенә күренмәде. Менә хәзер көтеп утыр көне буе бүген дә, иртәгә дә аның килүсен. Чыгып китсә, ул юкта килер дә, карчыгының котын алыр.

3

Оскар Ефимович Сац – бай кеше. Сац фамилиясе йөртсен дә, ниндиләр ивановлар, петровлар, сидоровлар кебек, хәерчелектә көн күрсенме. Юк, кайсы бер туксанынчы еллар бандитлары кебек, юл басмады ул, базар сатучыларын да таламады. Чубайс, «ваучеризация» атлы галәмәт уйлап итеп, үз кешеләренә «акция» атлы кәгазьләр рәвешендә бушка дип әйтерлек таратып биргән ил байлыгыннан өлеш кенә эләктереп кала алды. Тәүге маллардә бу хикмәткә хәтта үзе дә аптырап бер булды. Кичә генә башкала фәнни-тикшеренү институтларының берсендә асна йөз дә уи тәңкәгә кече фәнни сотрудник йөген тарта иде. «Йөк» дисәң хәтере калыр, ни эше, ни ашы. Шуңа Мәскәүдә дүрт кешелек гаиләңне асрап кара...



Хәтта, бик аптырагач, бер иптәшенең киңәшен тыңлап, Кавказ төбәкләрендә постель кирәк-ярагы дефицитка әверелүеннән файдаланып, сәүдә белән шөгыльләнергә дә маташып карады. Ике зур чемодан простыньядыр, мендәр, юрган тышлыгыдыр төяп, барып төште ул андагы бер шәһәргә. Күрәсең, законсыз сәүдә белән шөгыльләнергә теләгән адәм бер ул гына булмагандыр-да, милиция бу эшкә күз йомып карамагандыр. Вокзалда ук эләктереп алдылар да, чемоданнары-ние белән урындагы милиция бүлегенә, тәфтишче каршына китереп бастырдылар.

– Әһә, – диде милиция кече лейтенанты, озын борынлы, зур мыеклы кавказ кешесе, – Капгыңмы спекулянт!

– Спекулянт түгел мин, иптәш майор... – дип мышкылдады галимлеккә кандидат. Куркудан микән, капыл гына томаулап китеп, кәкре борынынинан маңка ага башлаган иде. – Мин...

– Нәрсә син? Мин тегү фабрикасы директоры, дип әйтергә телисеңме?

– Юк, мин НИИ-да кече фәнни сотрудник.

– Если и сатруднык, мышками прастыня таскать? Знаеш, на сколко тянет твой прыступлыние. Чытыре года, сядеш как мыленкый...

Спекулянтлыкка кандидат кесәсеннән кульяулык чыгарып, күз яшьләрен сөртте, бүлмәгә яңгыратмаска тырышып, борынын сеңгерде.

– Иптәш майор...

– Майор түгел, кече лейтенант кына...

– Сез барыбер майор булачаксыз.

Милиционерның кырыс йөзе ачыла бирде.

– Иптәш лейтенант... Ике бала... хатын... йөз уи тәңкә зарплата... утыртмагыз, зинһар! Бер юлга гафу итегез, зинһар!..

Кече лейтенантның да йөрәге таш түгел икән.

– Пырвый, паслыдный раз!.. – диде ул каты итеп. – Да вычера штоб твайй наги здес не было! Поезд – в сымнадцат нол-нол.

Сацның тормышы зур һәм кечке вакыйгаларга бай булды. Тик Нью-Йорк – Москва самолётында уйланып килә торгач, ул нишләптер шушы кечкенә вакыйганы исенә төшерде. Кечкенә, әмма исенә төшергән саен һаман да кара тут йөзе кызылга манчыла. Нинди мескен хәлгә калган иде бит ул анда.

Ә хәзер ул кем! Сац әфәнде! Оскар Ефим улы галиҗәнәпләре! Тупланган байлыгы җитәрлек, җылы океан буендагы вилласында

шуны ашап кына ятса да, булыр иде. Тик, өстәлеп тормаса, зур байлык та кими бара шул. Җитмәсә, улы белән кызыннан да рәт чыкмады. Аларның томанлы Альбионда белем алулары беләнмени. Акча исен тоемламагач, акча эшләргә өйрәнмәгәч... Хатыны картайганда тыртайган дигәндәй. Ел саен машина алыштыра, миллион, миллион ярымлык кына булса бер хәл. Соңгысы бит ун биш миллионга төште. Ә туннары, ә башка затлы киемнәре. Шәшке тун гына ярамый, аңа шиншилла кирәк!..

Шулай булгач, эшләргә туры килә шул. Федераль кимәлдә дә урнашкан булыр иде дә ул. Андагы министрларның тормышын энә күзеннән үткәреп кенә торалар, түбәнгәрәк бик игътибар биреп бармыйлар. Саңка өлкә хөкүмәтендәге финанс министры вазыйфасы да бик ярап ята. Төшеме тегеләрнекеннән ким түгел, ә җаваплылыгы йомшаграк...

Уйларының көнелсез юнәлеш алуын чамалап, ул янында «мыш» та «мыш» йоклап килгән юлдашына күз ташлады. Яшь, чибәр! Кашыкка салып йотарлык. Кемнеке – аныкы! Саңның сөяркәсе тап шундый булырга тиеш! Диңгездә су коена-коена йончыган мескен. Әйдә ял итсен. Кайткач, йончыдым дип, ялындырып торырлык булмасын...

Күптән түгел ишеткән анекдот исенә килеп төшеп, аны елмаерга мәҗбүр итте. Бер әһел, имештер, хатынын ияртеп, зур мәҗлескә барган. Берсеннән-берсе дәрәҗәле, берсеннән-берсе бай халык. Көмешкә чөмереп, тозлы кыяр ялап йөргән чакларын оныткannар. Аксөякләр булып кыланалар... Анекдот герое хатынын аларның тәрҗемәи хәле белән таныштыра икән. «Әнә теге сары чәчле, юантык гәүдәле даманы күрәсеңме? Ул безнең боссның сөяркәсе!» «Ничава гына икән», – дигән бичә, босс сөяркәсенә сынаулы караш ташлап. «Ә монысы, – дигән ире, кара чәчле, кара күзле яшь хатын ягына ишарә ясап, – безнең креатив директорның сөяркәсе...». «Бусы да ярыйсы сөяркә...» – дип бәһалаган тегене ир хатыны. Мондый гадел бәһалар иренең аңын томалаган, булса кирәк. «Бусы – минем сөяркә!» – дип ычкындырган ул ялгыш. Хатыны да уйлап тормаган, ире күрсәткән бичәнең барлык зиннәтләрен тишәрдәй карашы белән барлап чыккан да: «Ә безнең сөяркә барысыныкыннан да чибәррәк!» – дип кычкырып җибәргән, имеш.

Финанс министры, сөяркәсен фатирына кертеп калдырып, туры Золотаревкадагы дачасына кайтып төште. Анда аны көнелсез хәбәр көтә иде. Сакчыларының берсе, иң ышанычлылардан саналганы,



юкка чыккан. Аның белән бергә «Явыз Иван улын үтерә» атлы картинасы артына яшерелгән сейфта сакланган акчалары да... Картинасытина артына яшерелгән сейфта сакланган акчалары да... Аның укучына килгәндә, Илья Репин үзе төшергән рәсем түгел ул. Аның укучыларының берсе тарафыннан эшләнгән күчермә генә. Шулай булса да, ларының берсе тарафыннан эшләнгән күчермә генә. Ә сейфы менә шушы дүрт катлы йорт кыйммәт хакка алынган нәрсә. Ә сейфы менә шушы дүрт катлы йоркыйммәт хакка алынган нәрсә. Ул хәтле үк ис тында яшерелгән дүрт хәзинә тартмаларының берсе. Тегеләрендә алтын-көмеш-китәрлек, чәч йолкырлык югалту түгел. Тегеләрендә алтын-көмешләр, асыл ташлар, долларлар, евролар... Монысында күптән түгел бер бизнес «Акула»сыннан каерып алган агач акчалар...

Беркатлырак укучыбыз башында: «Нишләп полициягә мөрәҗәгать итмәде икән?» – дә сорау да туарга мөмкин бит әле. Ничек итсен ди инде? Бердән, полиция түрәләре, ул чаклы акча хөкүмәт чиновнигына кайдан килгән дип, кызыксына башлавы мөмкин. Икенчедән, җинаятьчене барыбер тапмаслар, угрыныкын бур урлаган дип, күл селтәрләр дә куярлар. Санкт-Петербург мэрының кызы Ксения фатирларының берсеннән тартма тулы алтын-асылташ-ларын чәлдерү вакыйгасы ни белән тәмамланды? Миллион долларга торыш иткән байлыкны? Берни белән дә тәмамланмады. Бары Русия халкы күңелендә, әле эшләп, ни әтисе белән әнисенә, ни илгә тырнак очы чаклы да файда китереп өлгермәгән кызыкайга ул чаклы миллионнар кайдан килде икән, дигән сорау гына уятты. Монысы элегрәк, әле халык аптырау сәләтен онытып бетермәгән чорда, булган хәл. Хәзер инде өйрәнеп беткәннәр. Фәлән-фәлән губернаторның урлап җыйган байлыгын өч көн, өч төн санаганнар, барыбер очына чыга алмаганнар – берәү дә аптырамады. Бары миллион доллар торган авторучкасы гына байтакларның кызыксынуын уятты. Фәлән-фәлән генерал, әйткәндәй, бар төрмә сакчыларының түрәсе, учына дистәләгән миллионнарны йомган – аптыраучы юк.

Шулай булгач, зур булмаган өлкәнең тыйнак кына чиновникларының берсе байлыгына кем аптырасын? Акча ул су кебек. Бер урында җыелып ята-ята да үзенә агар юл таба. Әйе, гарьләнде Сац әфәнде. Иң тугрылардан саналган хезмәтчесе бит. Ничек тапкан? Ничек сейфының кодын белеп алган да, ничек ачкан? Үзен бик тә акыллыга исәпләгән яһүд бу очракта хата җибәргән иде шул. 28081963 – үзе генә хәтерендә тота торган сан, янәсе! Шефының мең тугыз йөз алтмыш өчтә, егерме сигезенче августа дөньяга килгәнен Аю белмәгәнме дә, башкалар белмиме? Бу инде, чагыштырып әйткәндә, өенең тимер ишеген хәтәр йозак белән бикләп алып, ачкычны ишек төбендәге чүпрә астына яшереп куюга бәрабәр.

Кыскасы, ике атналык отпускысыннан соң Сац әфәнде, ниһаять, эш кабинетына барып утырды, Урал якларыннан хәбәр көтте...

4

Сәфәргали карт та көтте. Акчалы тартма хуҗасы энә килер, менә килер дип көтте. Йорт мәшәкатьләреннән бераз бушанса, остаханәсенә кереп шакы-шокы килә торган гадәте бар аның. Бу көндә кермәде. Йозакка бикләнгән алачык хуҗабикәсенең дә игътибарыннан



читтә калмады. Гомердә булмаган хәл!.. Өчкуянда халык йорт кура-
сын гына түгел, авылдан чыгып китмәсә, өен дә бикләп йөрми.
Зөләйха карчык өй алдында үскән шомырт агачы ышыгыннан озак
кына картын күзәтеп торды. Әле җиргә бик үк чүгеп бармаган озын
сыны, тамырлары калку күрекле куллары, дөньяның бик күп ыгы-
зыгысына исе китеп бармас тоелган, үз-үзенә ышанган йөз кыяфәте,
уйган еллар акка буяган чәче, чәченә ияреп тигез агарган мыегы...
Башка кеше белдерме-юктырмы, картының халәтен Зөләйха
карчык әнә шул мыегына карап та билгеләргә өйрәнгән. Мыек, тарак
белән тараганлай, урынында тигез ята икән, күңеле тыныч, тычкан
сагалган песинең арка йоны кебек, тырпаеныкыраган икән, күңелен
нидер борчый, ныграк тырпайган булса, эчендә давыл уйный. Әле
әнә шул сизгер мыегы керпе энәләре кебек тырпайган. Зөләйха
карчык картына сокланып та, җалланкырап та карап торды.
Сокланмаслык түгел шул. Илле дүрт ел элек тә авылның менә дигән
егете иде. Әле дә кешегә сүзе үтә торган абруйлы картларның берсе.
Зөләйхасына сүз тигезмәде, житешлектә яшәтте... Күңелен нәрсә
борчыганы турында сорарга әйткән иде дә, бу уеннан кире кайтты.
Теләсә, үзе сөйләр әле. Әлегә сүз булсын дип кенә дәшкән булды.
– Әтисе, нәрсә ишек алды буйлап тегеләй-болай йөрисең?
Бәрәңге утар вакыт житә. Хет анау тәпкәнең сабын яңартыр идең.
Башка вак-төяк эш тә бетмәгән...
Нәрсә дип җавап кайтарсын карт? Бер капчык акча алып кайт-
тым, шуның хуҗасын көтәм, дисенме? Иртән башыннан үткәргән
хәтәр хәлне сөйләсә, карчыгының өенеге тотып, егылып китәр.
– Эш – бүре түгел ул, урманга качмас, дип шаяртудан ары китә
алмады.
Урамга чыгып, бераз капка төбендә басып торды, олы юл ягын
күзәтәсе итте. Юлда шул ук ыгы-зыгы, тик авылга борылып керүче
машина гына күренмәде. Авыл хакимияте башлыгы Корамшин
машинасыннан төшеп сәлам бирде.
– Ни хәлләр, Сәфәргали абзый? Нишләп ялгыз каргадай моңаеп
басып торасың? Әллә район үзәгенә алып барып килимме үзеңне?
Рәхәтләнеп бер типтереп кайтырбыз...
Карт шаяртуга шаярту белән җавап бирде.
– Хәлләр ашауга карап, Сәүбән энем. Ә ашау әлегә Аллага
шөкер! Пенсияне китереп торалар. Типтерүгә килгәндә, ул заманнар
узган инде, әйдә хәзер сез яшьләр типтерегез... Чамасын белеп...

– Их, Сәфәргали абзый, Сәфәргали абзый, без, яшьләр дә, хәзер алтынчы дистәне куабыз шул…

– Вакытлы-вакытсыз ни йомыш төште Тукмаклыда? Анда бит сезне галәттә таң белән җыеп сабак укыталар.

– Әллә инде? «Срочно» дип шалтыраттылар. Ниндидер ЧП булган диме? Шулай бит ул: Мәскәүдә атышсалар, безне җыялар, Кавказда шартлатсалар, безне җыялар. Янәсе, профилактика!..

– Аңысы да кирәктер дә ул, Сәүбән энем. Тик ул җыелышлары элек тә күп була торган иде, хәзер аннан да күбрәк, ахрысы. Чит илләрдә бездән көлеп тә маташалар, булса кирәк. Имеш анда эшләр бармаса, җиң сызганып эшләргә тотыналар, бездә эш бармаса, җыелыш үткәрәләр. Шулай түгелме?

Бу фикерне дәвам итәргә Корамшинның нияте юк иде.

– Җыелышлар үткәрәләр дә ул, монда бер күпер генә төзергә дә акча бирмиләр… – дип әңгәмәне тәмамлады да, юлында булды.

Инде кереп китәм дип, карт янкапкасын гына ачкан иде, алдына кояштай балкып Фәйрүз килеп басты.

– Әссаламмәгаләйкем, күрше бабай!

– Исәнгенәме, Фәйрүз улым…

Кияүгә чыга алмый картаеп барган әнисенең бердән-бер улы булып дөньяга килгән бу егет, аңа зур шатлык китерә алмады. Акылга җиңелрәк булып үсте ул, шуңа күрә мәктәптә биш ел укып маташып, ике сыйныфтан да ары китә алмады. Әмма кара эшкә әрсез булып үсте.Әнисе дөнья куйганына да биш-алты ел үтеп киткәндер, ярдәмгә мохтаҗлыгын сиздергәне юк. Киресенчә, күпләр ярдәм сорап аңа үзләре мөрәҗәгать итәләр. Кар көрәсенме, утын ярсынмы, кәтү көтешсенме – берәүнең үтенечен дә кире какмый. Акча да сораганы юк. Утырып ашарга риза, хәмер тәкъдим итсәләр борын чөерә. Кәнфит – татлы, тавык ите – тәмле, аракы атлы сасы суны нигә чөмерәләр икән? Бу сорауга Фәйрүз җавап таба алганы юк әле. Авылның кайсы бер адәмнәре аны бар белеме ике генә сыйныф булганы өчен дә, халык-ара сәясәттә, кайсы бер дөньяви мәсьәләләрдә сирәк йөзгәне өчен дә түгел, менә шушы «сасы суны» сапга сукмавы өчен, булса кирәк, акылга җиңел дип исәпли.

Шулай ук акылсызмы бу егет? Әллә Ходай Фәйрүз кебекләрне башкаларга мисал булсын дип яраткандыр? Адәм баласы туартумастан алдарга өйрәнә, үсә-үсә адым саен дип әйтерлек алдый башлый. Менә әле генә Сәфәргали карт әбисенең, нигә инде болынга барып бозауга печән алып кайтмадың, дигән соравына юньлерәк җавап



таба алмагач, әллә нишләп ялкавым килде, дип алдады ич… Ана
хәтле, Ырынбурдан бер капчык урак алып кайтып килэм дип, Тозкүз
Гыйлвангa буш хәбәр әйтте. Фәйрүз булса, тотар да, Аюдай гәүдәле
урыс бер тартма акча тоттырып китте, дияр иде. Тегеләй яхшымы,
әллә болаймы – анысын бер Ходай да Фәйрүз үзе генә беләдер.
Түгәрәк йөзе бераз сипкелле, чәчә-кашы җирән, дөньяга һәрчак бала-
ларча кызыксынып караган күзләре дә көрәннән җирәнгә тартым.
– Бүген ни эшлибез, күрше бабай? Абзарың чыгарылмаган бит
әле, әйдә шуны эшләп ташлыйк…
– Юк, Фәйрүз улым, әле иртәрәк, тагы берәр атна кибә бирсен.
– Бирсен соң. Тик бер атнадан берүзең генә чыгарма, миңа әйт.
Син инде картаеп барасың. Чүлмәк Вәли беләсеңме синең турыда
нәрсә диде.
– Нәрсә диде Вәли?
– Сәфәргали карт бирешкән инде, комы коелып бара, диде.
Ә мин, күрше генә яшәп бер җирендән дә комы коелганын
күргәнем юк әле, дидем. Дөрес әйткәнменме?
– Бик тә дөрес әйткәнсең, Фәйрүз улым. Молодчина.
Егет күзләрендә шатлык очкыннары балкып китте.
– Алай булгач, балыкка барып килик соң. Айчумган ятуында
инде балык үрчегән ди.
Бүлә елгасы, ярымбожра хасил итеп, Өчкуянны кәнчыгы-
шыннан чикләп ага. Авылдан өч-дүрт чакрым түбәнрәк елганың ин
тирән бер төшен халык «Айчумган ятуы» дип йөртә. Узган елларда
Сәфәргали карт, Фәйрүзгә ияреп кармак тотып чыгып, шул ятуда
чабак каптырып утырганы бар. Быел әле аларга андый форсат
тимәде. Яхшы булыр иде дә соң, борчулы уйларыннан да бераз ары-
нып иде. Тик шушы хәвефле мәлдә йортын ничек калдырып китсен?..
– Кем әйтте? – диде карт, көлемсерәп.
– Соң шул Чүлмәк Вәли әйтте инде. Шамбылар да үрчегән ди.
Араларында хәтта тәртә буйлыклары да бар ди. Миңа күп кирәкми.
Тәртә буйлык бер шамбы эләктерсәм… эләктерсәм…
– Нишләтер идең?
– Соң бүләләр идем дә, таратыр идем. Билләһи, арты авылга
житәр иде бит ул.
Карт кычкырып көлеп җиборде.
– Фәйрүз улым, минем бүгенгә вакытым чамалырак. Бу эшне без
калдырып торыйк. Эләктерүен эләктерсәк, ул шамбыны ничегрәк
тартып чыгару мәсьәләсен дә уйлый торырга кирәк бит әле.

– Анысы уйланылган инде, күрше бабай. Абзарың башында өялы саплы багор ята бит. Менә шуның белән эләктереп тартабыз да чыгарабыз... Буталәп, үзебезнең урамга өлешәбез. Волигә генә бирмик.

– Аны нишләп рәнжетергә булдың соң?

– Алкаш бит ул, күрше бабай. Көн дә эчә, хатынын кыйный... Шамбыдан аңа өлеш чыгарсак та, сатып эчәчәк бит ул аны.

– Дөрес уйлыйсың, Фәйрүз улым...

## 5

Сәфәргали картның йокысы йокы булмады. Нишләптер теге Аю белән Кабакбаш төшенә кереп изаладылар. Берсе аңа пычак күрсәтә, икенчесе пистолет белән яный. Сәфәргали карт тегеләрдән котылырга тырышып, Бүлә буендагы әрекмәннәр арасына качарга тырыша, аннан мескен картны карчыгы куып чыгара. «Шул кирәк сиңа, шайтан карт! Шул гына җитмәгән иде сиңа!..» Уянып китеп, җиңел тын алгач, аны Зөләйхасы, чынлап та, караваттан куып төшерде.

– Бар диванга чыгып ят әле, әтисе. Бер дә генә йокларга бирмисең... Тукай әкиятендәге кебек: «Су анасы мин, китер, кайда минем алтын тарак? Бир! бая көндез алып качты синең угълың, карак!» – дип тәрәзә шакысалар. Сәфәргали карт куркыр, әмма аптырамаган булыр иде.

Ярый әле шакымадылар...

Иртән, көтү куып кайткач, ул, юк йомышын бар итеп, авыл хакимиятенә китте. Корамшин йөзагын ачып, эш бүлмәсенә кереп кенә тора иде. Нишләптер йөзе караңгы. Шулай да авылның хөрмәтле кешесенә начар кәефен күрсәтмәскә тырышты.

– Таң белән ни эшләр бетереп йөрисең, Сәфәргали абзый? Берәр йомышың бармы әллә?

Карт кепкасын салды, кулъяулыгын чыгарып тирсез маңгаен сөртеп алган булды.

– Йомыш дип... әллә ни йомыш та түгел инде, Сәүбән энем. Әле кәефең дә бик юк, ахрысы. Башка вакыт берәр форсат табылырдыр. Эш арасында шеш булып йөрмим, диюем. – Карт кулын селтәде дә, чыгып китәргә ниятләвен белдерде.

– Юк, кергәч утыр инде, Сәфәргали абзый. Кәефкә килгәндә... Беләсеңме, кичә Тукмаклыдан ни ишетеп кайттык? Утыргычыңа тотынырак утыр, егылып төшә күрмә. Атышканнар! Безнең авыл биләмәсе чигендә атышканнар. Һәрберсе өлкәсенә чыгып өлгерсәләр булмаганмы шунда. Йөз метр гына калган бит!



Сәфәргали картның күкрәк читлегендә кара карчыга талпына биреп куйды.

– Безгә дә килеп җиттемени инде ул галәмәте. Мәскәү, Питерларында гына атышып юансалар җитмәгәнме?

– Юанып кына калмаганнар шул, Сәфәргали абзый. Бер–берсен дөмектергәннәр, авыр туфраклары җиңел булгырылар. Ничек алай туры китерә алганнардыр, берсенең маңгае тишек, икенчесенең күкрәге. Андый да була икән!

– Ни бүлешә алмаган соң ул бәндәләр?

– Әнә шунысы гаҗәеп тә. Машиналары, берсе ак джип, берсе кара джип, икесе дә Мәскәү якларыннан икән. Аларда бернинди байлык та, шартлаткыч-фәлән дә тапмаганнар.

Теге кара козгын картның күкрәгендә тагы кузгала биреп куйды. Чынлап микәнни?.. Ул озак кына уйлана биреп торды.

– Шулай булгач... Кешеләре юк – проблема да юк. Кайчандыр шушы сүзләрне даһи Сталиныбыз әйтеп калдырган ич...

Корамшинның караңгы йөзе ачыла бирде.

– Анысы шулай да ул. Минем авыл советы территориясында эшләнгән җинаять бит. Былтыр берәү дә булмады, быел тәүге яртыеллыкта ук ике мәет. Имеш, бүген үк, халыкны җыеп, әлеге профилактик чараны үткәрергә...

– Җый соң!.. Тәүге мәртәбәме ни. Депутатларыңны чакыр, укытучыларны, клубтагыларны, конторда утырганнарыңны... Нотык тот. Агай-эне, мәскәүлеләр кебек, бер-берегезне рәнҗетмәгез, атышмагыз, кисешмәгез, диген. Болай да таланган халыкның милкәтенә борыныгызны сузмагыз, диген. Акча исе – ул бик агулы ис, кешене котырта, чыгарыннан чыгара, акылдан язу чигенә җиткерә, диген.

Корамшин Сәфәргали картка аптырап карап торды.

– Акча исе? Син дә юк-барны уйлап чыгарырга оста, абзый. Акча – акча инде ул, аның нинди тәме дә, нинди исе булсын?..

Сәфәргали картның бу мәгънәсез әңгәмәне дәвам итәргә тәкате калмаган иде. Алачыгына яшереп куелган теге байлык хуҗасыз калган ич! Хәзер ул нишләргә тиеш?

Иртәнге чәйне кабалан-кабалан эчте дә, йозагын ачып, остаханәсенә керде, Зөләйхасы күзәтеп тормый микән дип, ачык ишектән ихатәсенә күз ташлады. Юк, аның үз мәшәкате мәшәкать. Ишекне ябып, эчтәге келәсен каптырып ук куйды. Калтыранган кулларын кыенлык белән буйсындырып йомычка астыннан әлеге тартманы тартып чыгарды. Аны верстак өстенә урнаштыргач та әле, ачырга

кыймый байтак кына икеләнеп торды. Ачты. Кейсның алтын ялатылган бите тагы кулын пешереп алгандай булды. Шыгрым тулы акча! Бер кая да китмәгәннәр, юкка да чыкмаганнар. Пөхтә итеп капларга төрелгән биш меңлекләр. Бер кабында йөз данә – биш йөз мең! Андый акчаны Сәфәргали картның үз гомерендә күргәне булмады. Күрмәс тә! Туктале, ничек инде күрмәсен ди? Менә ич! Шыгырдап торган биш меңлекләр, шыгырдап торган каплар! Санап караган иде – исе китте. Йөз кап! Илле миллион!.. Хуҗасы, шушы байлыкны Сәфәргали карт кулына калдырып, җәһәннәмгә олаккан. Хәзер Сәфәргали Өчкуянда бер генә кешенең дә, хәтта Тәзкүз Гыйлваннның да, төшенә дә керми торган байлык белән ни эшләргә тиеш?!

Карт, карчыгы күзенә чалынмаска тырышып, бозавын арканлады да, бәрәңгелеге очындагы чирәмгә алып чыкты. Әйдә, алып кайтып сыйлаганны гына көтеп тормасын, чемченергә үзе өйрәнсен. Анысының тәү казык тирәсендә түгәрәк ясап чапканын, аннары киң дөньяны гаҗәпләнеп күзәтеп торуын, ниһаять «керт», «керт» итеп йомшак, сусыл үләнне кәйшә башлавын көлемсерәп күзәтеп торды. Төшен чыгып су эчереп керергә кирәклеген дә чамалады. Кечкенә мәшәкатьләре борчулы уйларыннан аны азга булса да арындырып торды.

– Бозавыңны ирекә чыгарырга иртәрәк түгелме әле, этисе? – дип каршы алды аны карчыгы. – Арканына уралып казалап ятмагае...

– Әйдә өйрәнә торсын. Аның үгез булып үсеп җитүен көтәргәме ни.

Чыккалап, күз-колак булып торырмын. – Аллага шөкер, – дип җиңел тын алгандай булды ул. – Әле берни дә сизмәгән икән.

Үз гомерендә халәл җефетеннән яшереп берни эшләгәне юк иде әле аның. Дөньяны киңәшләшә-киңәшләшә көттеләр. Менә хәзер ни эшләргә икән? Ул миллионнарны хөкүмәт карамагына тапшырыргамы? Хәзинә тапсаң, шулай эшләргә кирәк икәнен ул белә. Хәтта тапкан кешегә егерме биш проценты бүләк рәвешендә кайтарылырга тиеш икәнлеге турында да хәбәрдар. Илле миллионның дүрттән бер өлеше уникe миллион ярым буламы? Ярыйсы! Тик көтмәгәндә аның кулына төшкән байлык берничнди дә хәзинә түгел ич. Кайдандыр урланган акчалар. Угрыныкын бур урлаган мөлкәт. Күптән түгел бер Мәскәү полковнигының фатирыннан миллиардларны КАМАЗ-га төяп чыгаулары турында ил шаулап калган иде. Әйткәндәй, тиз оныттылар. Хәтта теге мут хәрбине утыртмадылар



да, булса кирәк. Тиз онытылуы да андый хәлләрнең еш булып торуына бәйледер инде.

Ярый, Сәфәргали карт кейсны полициягәме, прокуратура фәләненәме, районның башка берәр түрәсенәме алып барып тапшырды ди. Ни эшләрләр? Шатланырлармы? Әйе, һичшиксез шатланырлар! Хөкүмәт кесәсенә тыгылып кына барган түрәләр җилдән килгәнгә ничек куанмасыннар инде!..

Байтак еллар булып үткән бер вакыйга исенә төште. Үсмер генә чагы иде әле. Авылда һәм тирә-якта яшәгән тизлеге белән: «Чатан Вәгыйз заемга илле мең акча откан икән!» – дигән хәбәр таралды. Илле меңнең генә түгел, юньләп кулларына илле сумын да тотып карамаган гади халык өчен бу, чынлап та, сенсацион вакыйга булды. Кемнәрдер аптырады, кемнәрдер көнләште, кемнәрдер акыл белән иңләп булмаслык байлыкны ничек тотынырга мөмкин икәнлеге турында бәхәсләште. Мин булсам тегеләй эшләр идем, мин булсам болай эшләр идем, янәсе. Авылның ул вакыттагы бердән-бер сәрхуше Зәбих кенә нәтиҗәне берниндиикеләнүсез чыгарып куйды. Түгәрәкләп исәпләгәндә, бу акчага уналты мең җиде йөз бутылка килә, көн дә бер шешә түңкәрсәң дә кырык алты елга җитә бит бу егетләр! Вәт шәп! Синең болай да юшкын баскан ашказаның белән череп беткән бөерләрең кырык алты ел түгел, кырык алты көнгә дә чыдамас, диләр икән. Зато теттереп яшәп калам, дип күкрәк суккан, имеш. Ярый әле ул акча Зәбих кебекләргә эләкмәгән. Хәер, эләкмәсә дә озак яши алмады мәрхүм. Кышның зәһәр суыгында, төнен бәдрәфкә чыкканда, өенә юл таба алмый туңып үлде.

Ә Вәгыйз җилдән килгән акчага урын да тапкан иде дә ул. Барыбер бәхетле яши алмады. Җәйгә чыгу белән үк шыгырдап торган карагайдан алты почмаклы йорт салдырды. Рәтен ничек тапкандыр, авылда беренче булып «Москвич» атлы җиңел машина алды. Ул вакытта әле хәтта колхоз рәисе дә ат җигеп кенә йөри иде. Вәгыйзнең байлыгы, күрәсең, өй белән машинадан да артып калгандыр. Аның колхоз эшен бик санламаган улын авыл халкы еш кына салмыш килеш күрә башлады. Шундый халендә машинасын юл читендәге телеграм баганасына бәреп челпәрәмә китерде. Ахрысы да, әнә шул гадәти халендә диванда тәмәке тартып йоклап китеп, өйләренең көлен күккә очырды. Ярый әле Вәгыйз иске өен сүтеп алмаган иде. Бөтенләй урамда торып калмады. Аның юньсез улы (хәзер инде исеме дә авыл халкының исендә калмаган) читкә китеп юкка чыкты.

Юктан бар булган зур байлык кешегә бәхет китерми. Менә шундый нәтиҗәгә килгән иде ул чакларда Өчкуян халкы. Нәтиҗә ясадылар һәм оныттылар. Сәбәбе булмаса, Сәфәргали карт та исенә төшереп маташмас иде.

## 6

Моңысы булган икән баласы, алда көткән әле анасы, дип халык. Оскар Ефимович Сацның Мәскәү янәшәсендәге ямьле нарат урманын байлар өчен коттедж бистәсе төзергә төзелеш компаниясенә сатканнан килгән откаты – аның бихисап байлыгының зур булмаган бер өлеше генә (бер лимон «яшелгә» дә тулынкырамый) икәнлеген укучыларыбызга төшендереп китү урынлы булыр. Зур булмаса да юллатып таптырган булыр иде ул аны. Тик арл-тирә гене дигәндәй уяулык күрсәтеп маташкан хокук сакчылары әнә шул миллиардлар белән исәпләнгән «бихисап»ны чокып чыгарып өлгергән иделәр инде. Мәскәүдәге үзенә, хатынына, кызына, улына теркәлгән дүрт фатирыннан да байтак таптылар, дачасындагы яшерен сейфларда сакланган долларлар белән евроларны да КАМАЗга ук булмаса да инкассатор машинасына шыплап төяп алып чыктылар. Бер кейс агач акча кайгысымы ни монда?..

Сәркәсе фатирына качып өлгергән Сац, тизрәк чит илгә чыгып таю мәшәкате белән булып, авызыннан тартып алынган әлеге «бихисап» өчен кайгырырга да онытты. Аның калган гомеренә чит илләр банкларындагысы да җитәрлек иде. Җитәрлек кенә түгел, баштан ашырлык!..

...Сәфәргали картның башына «келт» итеп бер фикер килмәсә, бу көнен дә уйланып, хәвефләнеп үткәрер иде әле. Тагы керде алачыгына, тагы ачып карады. Таң алды төшедәй эреп юкка чыкмаганнармы, янәсе. Юк, тезелешеп яталар. Тик ятмыйлар, ачкан саен, алачык эченә кырку ис таратып, картның борынын кытыклап яталар. Менә шушы мәлдә килде карт башына әлеге акыллы фикер. Чын акча түгелләр болар, ялган акчалардыр. Ай саен почта хезмәткәре кулына китереп тоттырган пенсия акчасыннан мондый ис килми, ләбаса. Әлеге бандитлар басканнар-басканнардыр да, бүлешә алмый, бер-берсен дөмектергәннәрдер... Димәк, хафаланып изаланасы юк, тотырга да мунча миченә ягарга!.. Әйе, яндырырга!.. Әйдә, көлләре күккә очсын. Туктале, чын акча булып куйса? Шушы хәтле байлык күккә очамы?..



Икенче көн таң белән Сәфәргали карт Ырынбурга барып килергә җыенды. Бу карар карчыгын аптырашта калдырды. Ни булды соң бу картына? Ике көн инде үзенә урын табалмый. Йокысы йокы түгел. Остаханәсенә бер керә, бер чыга. Шакылдаганы да ишетелми. Мыегы да гадәттәгедән артык тырпайган...

– Ырынбуры нигә кирәк булды инде сиңа, этисе? Ул турыда бер дә сөйләшмәгән идек бит әле...

Ни дисең?

– Хәзер бит, әнисе балта, чүкеч белән мәшәкатьләнү чоры үтте. Юньле генә инструментлар хәстәрләргә иде: электр пычкысын да, электр ышкысын да, дрель белән шөрепләрен дә... Веранда башын ябарга, мунча идәнен алыштырырга... – дип хәйләләргә туры килде.

– Нигә, аларны Тукмаклыда гына алып булмыймы ни?

– Тукмаклыда тукмаклыча, Ырынбурда ырынбурча... Сиңа нәрсә алып кайтыйм?

– Миңа хәзер ни кирәк. Ходай булганын киеп туздырырга язсын. Хәер, ишек алдында өстерәргә бер аяк киеме алып кайт. Хәзерге калушларнең бер дә рәте юк. Бәлки, чын үзбәк калүшенә юлыгырсың.

Өчкуяннан Ырынбурга сәгать ярымлык юл. Машиналар чебен урынына кайнашкан шушы юлда анда барып кайту кыен эш түгел. Автобус тәрәзәсеннән дала манзарасын күзәтеп бара торгач, Сәфәргали карт яшьлек хатирәләренә дә бирелеп алды. Унынчыны бетеп киткән иде ул армиягә. Хыялы: хезмәтен тутырып кайту да, Ырынбур авыл хуҗалыгы институтының механизация бүлегенә керү. Нигә Ырынбур, нигә Уфа түгел? Юл йөрү чыгымнарын исәпкә алып. Артында әтисе юк. Каһәрле сугышта ятып калды. Кошчылык фермасында эшләп йөргән әнисенең дә исәнлеге чамалы. Тик, хезмәт итеп кайткач, әлеге планына үзгәреш кертергә туры килде. Әнисе бөтенләй аяктан егылды. Урта мәктәпне тәмамлап кына йөргән Зөләйхасына өйләнде. Аларны ташлап институтка китсенме? Кашыкка салып йотарлык Зөләйхасын кем карамагына калдырып? Гыйлван аның тирәли бөтерелми микән дип, төннәрен ут йотып узгарсынмы? Белем алу теләген механизаторлар курсы белән чикләргә туры килде. Юк, Сәфәргали карт үкенеп яшәмәде. Әле дә үкенми. Аны бит заманында тракторчылар бригадасы җитәкчесе итәргә дә маташып карадылар, гараж мөдире вазыйфасын да тәкъдим иттеләр. «Юк, – диде. – Миңа бит мулла үзе Сәфәргали – бөек сәяхәтче исемен биргән. Нишләп конторда счет төймәсе тартып утырырга ти-

еш мин?» «Туктале, нинди сәяхәтче буласың ди инде? Авылдан чыкканың юк дип әйтерләр. Җәен, кышын йә комбайн, йә трактор кабинасында тузан йотасың». «Тузан йотмасаң, ипи ашамыйсың ул, энем. Сәяхәтчелеккә килгәндә инде, басуларда минем ничәмә ничә чакрымнар узганны чамалыйсыңмы? Кырык елда җир шарын өч тапкыр урап чыкканмын. Вот!»

Шәһәрнең «Яшел базар» янәшәсендәге иң зур универмагын сайлады ул. «Универмаг» дип элек кенә атыйлар иде, хәзер кыегына ат башы хәтлек утлы хәрефләр белән «Гипермаркет» дип язып куйганнар. Эченә кергәч тә исе китте. Дүрт катын тоташтырып эскалатор йөреп тора, йөзәрләгән бүлекләрендә ни генә сатмыйлар!.. Барысы да бар, тик үзбәк калуше генә юк. Ырынбур хәтле Ырынбурга килгәч, буш кул белән кайтып булмый бит. Ул эш кораллары рәте буйлап үтте. Монда да нәрсә генә юк: пычкысымы, ышкысымы, боравымы, кыскычымы. Хәтта сабаны белән кар көрәгечен дә куйганнар, бетон болгатам дисән, болгаткычы да бар. Сәфәргали картның аларны карап йөрүе аптыравыннан түгел, андыйлар Тукмаклыда да бар. Нәрсә алса, үзенә карата сатучылар күңелендә шик уятмас?..

Дрель булгач дрель. Яхшысын сайлады, тишек тишәргә генә түгел, шөреп борырга да җайлатылган. Кассага килде, кесәсеннән әлеге биш меңлекне чыгарып, аппарат артында утырган яшь кенә, чибәр генә кызыкайга сузды.

– Доченька, вот на старости лет электродрель решил приобрести...

Кыз күтәрелеп картка карады, ягымлы елмайды, үзебезчә дәште.

– Дөрес эшлисең, бабай. Агачны кул бораву белән бораулау чоры үткән инде. Моның белән хет агачны, хет кирпечне, хет тимерне...

Картның суынып барган эченә җылы кереп киткәндәй булды. Кыз акчаны ниндидер яктыга куеп карыйсы итте. Ялганмы, түгелме икәнен алай да белеп була микәнни? Юк, аның белән генә чикләнмәде, касса аппараты янәшәсендә утырган балалар уенчыгы кебек кенә бер механизмның ярыгына тыкты. Анысы шыгыр-шыгыр иткәндәй булды, яшел күзе янды, акчаны икенче ярыгыннан китереп чыгарды. Яшел күз – ул уңай бәһа, светофордагы кебек. Карт шуны аңлады, җиңел итеп тын алды, кулъяулыгын чыгарып тирә агып төшеп барган маңгаен сөртте, мәләем кызның елмаюына елмаю белән җавап бирде.



– Мәгә, бабай, сдачасы. Исән-сау кулланыгыз.

Гипермаркетның азык-төлек бүлегенә кереп, кәнфит-пәрәник, кибеттән чыккач, базар рәтләрен үтеп, үзбәкләрдән өрек-чикләвек сыман тәм-том алды. Сатулашканда бер үзбәк картының аягына күзе төште. Ялкылдап торган читек кигән, читек өстеннән тегесеннән дә болайрак ялкылдаган галош. Чын үзбәк калуше! Зөләйхасының хыялы! Сәүдәгәр күңеле сизгер була бит ул.

– Нәрсә, әкә, минем читек-кәвешемә күзең төштеме әллә?

– Читегенә түгел, кәвешенә... Сат...

– Була ул, әкә, – Үзбәк хәйләкәр елмайды да, капчыкларының берсеннән пар галош китереп чыгарды. Күрәсең, өрек сәүдәсе белән генә чикләнми, үз иленнән тормыш кирәк-ярагы да китерә.

– Ике пар алырга мөмкинме, кордаш? – Сәфәргали карт күңеленә үзенә дә бик ошап киткән уй килде: Бер пары абзар арасында киярга, берсе урамга чыкканда...

– Хет ун пар ал.

Дөньялар үзгәреп киткәнче, Өчкуян урамнары да шаулап-гөрләп тора иде. Халыкның эшлисе эшенә бара, эшеннән кайта, йомышлысы, төрле йомышларын үтәп, авыл советы, колхоз идарәсе, районо китапханә тирәсендә чуала, балалар бакчасы белән мәктәпкә бетләре, хастаханә тирәсендә чуала, балалар бакчасы белән мәктәптә тә үзләренчә кайный. Хәзер тормыш сүлпәнләнде. Урамга төнен түгел, көн үзәгендә чыксаң да, кеше күрермен димә. Ә шәһәрдә икенчерәк. Элек ничек чебен урынына кайнашсалар, хәзер дә шулайрак. Картлары картлар инде. Яшьләренең кием-салымына, үзләрен тотышына заман үз үзгәрешләрен керткән. Егетләре-кызлары төрле сүрәтле футболкадан, ботлары, очаларына сылашып торган джинсы чалбардан, колакларына радиоалгычмы, магнитофонмы проводы тыкканнар, кулларында кесә телефоны. Сөйләшер, танышыр, сөешер генә чаклары, берсенең берсендә эше дә юк сыман. Автовокзал янәшәсендәге эскәмиядә автобус көтеп утырганда, карт бер гаиләгә игътибар итте. Яшь хатын кашыкка салып йотарлык чибәр, ир торганы белән баһадир, яңа туган балалары коляскада. Анысының авызына имезлек каптырып куйганнар да иксесе дә әлеге смартфон атлы уенчыкка текәлгәннәр, аннан әллә нәрсә эзлиләр, табалар да булса кирәк, кашлары җимерелеп тә китмәли, елмаеп та алалар, берсенә, йә сабый балага елмаймыйлар, уенчыкка елмаялар.

Әллә яшьләрнең күбесенең өйләнә, кияүгә чыга алмаганына, өйләнеш-кәнләрнең күбесе аерылышуына шушы заман уенчыклары да гаепле микән?

Менә шундыйрак тойгылар кичереп кайтып барганда, Сәфәргали карт бүген үзенең ярыйсы ук куркыныч адым ясаганын исенә төшереп, дертләп куйды. Алып килгән акчасы ялган булса? Сатучы кыз аны полиция кулына тапшырса? Алары җинаять эше кузгалтса?.. Анннары исбатла аларга үзеңнең хөкүмәт җинаятьчесе фальшивомонетчик түгел, хезмәт ветераны, орденнар кавалеры Сәфәргали Шәехмәт улы Байтимеров икәнлегеңне...

7

Зөләйха карчык карты алып кайткан күчтәнәчләргә, үзбәк килүшенә куанды, әмма күңелендә туа башлаган шигенең арына алмады. Нидер булды аның картына, гомердә булмаган хәл, ниндидер серен анардан яшерә. Бозавын ихатага алып кайтып япкач, малларын көтүдән каршылагач, Зөләйхасы сыер саварга утыргач, тагы кереп бикләнде алачыгына. Тагы шакылдаган тавыш чыгармады... Карты берәр нәрсә ишетепме, белепме, аптырапмы кайтса, карчыгы үз гомерендә аның авызыннан серне тартып алганы булмады. Бар уй-фикерләре, шикләре, икеләнүләре уртак булды. Ә бу юлы?..

Карт, остаханәсенә кергәч, ишек келәсен элгәч, йомычка өеме астыннан әлеге тартманы чыгарды, бераз уйланып торды, курка бирербәк чылтлатып алтын ялатылган ике йозакны ачты. Кулына килеп кергән акчалар сихыр беләнме, әллә башка бер галәмәт беләнме юкка чыкса, бәлки, җиңел итеп тын алган булыр иде. Юк! Яталар, син дә мин тезелешеп яталар, бар алачык эченә, бәлки әле алачык эченә генә түгел, бар йортына, бар авылгадыр да, ят ис чыгарып, яталар. Карт бер капка көндез тотынылган хәрам акча урынына үзенең халал биш меңлеген тыкты, уйланыбрак торгандай итте дә кейсны япты, кире урынына яшерде. Карчыгы сыерын савып бетеп кенә тора иде, күрмәде, сизмәде дигән уй белән алачыгының ишеген бикләп алды. Хатын-кыз җир астында елан кейшәгәнен дә сизә икәнлеген яхшы белә дә, үзен-үзе тынычландырган булды.

Аның бу төне дә йокысыз үтте. Илле миллион! Аның карамагында!.. Дөнья тарихында реаль шәхесләрнең, китапларда әдәби геройларның байлык артыннан ничегрәк куулары турында хәбәрдар ул. Мәктәптә укыганда Гогольның «Үле җаннары»н өйрәнгән иде алар. Чичиков атлы бәндәнең помещиклардан үлгән крепостной крестьяннар сатып алып йөрү тарихы исендә. Кешеләрне алдап акчаларын алуның дүрт йөз ысулын белгән Остап Бендер мажараларын да кышның озын кичләрендә Зөләйхасы белән бергә көлә-көлә укыган



иделәр. Зөләйхасы гомер буе авыл китапханәсендә эшләгәч, алар укымый кем укысын инде.

Ә хәзерге караклар? Нинди юллар белән кешеләрне, хөкүмәтне талап баюларын тасвирларга хәтта Гоголь, Салтыков-Щедрин, Ильф, Петровларның да фантазиясе җитмәс иде. Нинди генә кыйтгада тумасыннар, нинди генә милләттән булмасыннар, нинди генә ысуллар кулланмасыннар, аларны бер сыйфат берләштерә: ничек тә зур байлыкка ия булу, кеше ирешмәгәнгә ирешү, кеше кыланмаганны кылану, бар дөньяны аптырату.

Сәфәргали Байтимеров бай яшәмәде, әмма тартып-суырып та көн күрмәде. Байлыкка омтылдымы ул? Юк, андый нәрсә аның ике ятып бер төшенә дә кермәде. Гомумән, нигә кирәк ул андый максат? Кешенең ике тамагы юк. Бүлә елгасы аръягына бер нәрсә дә алып китеп булмый, кәфенгә төрәчәкләр дә озатачаклар. Әлеге «геройлар» да бит кабуын капканнар, йота алмаганнар. Чичиковны фашлыйлар, Остап Бендер да бәллүр хыялы Рио-де-Жанейросына барып җитә алмый, румын чик сакчылары тарафыннан таланып миллионыннан яза. Алары алар инде, әллә булганнар, әллә булмаганнар? Хәзерге Русиянең иң күренекле буры Березовский нинди язмышка дучар булды? Лондондагы фатирында әллә буылып, әллә агуланып тончыкты...

Сәфәргали карт байлык артыннан кумады, байлык эзләмәде, байлык аны үзе эзләп тапты. Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына – шушы була микән? Бу Аллаһы эшеме, әллә шайтанныкымы?.. Ничек кенә булмасын, ул бит берәүне дә алдамады, берәүне дә таламады. Көтмәгәндә кулына килеп кергән бар байлыкны үз мәнфәгатендә файдаланса?..

Әйтик, яңа йорт салды ди. Бер катлы гына түгел, хәзер ике катлы белән дә әллә кемнәрне көнләштерә алмассың, өч катлыны. Алдына мәрмәрдәнме, гранитданмы баганалар куеп, баганалар өстенә бакыр рәшәткәле «терраса» атлы мәйданчык урнаштырып, «Рублевка» атлы авылда яшәгән Мәскәү байларыныкына охшатып. Әнә, әллә әнисе яшендәге, әллә әбисе үк чаклы Алла Пугачевага өйләнгән кәмитче Максим Галкин җиде катлы итеп төзеткән. Шул йортын фазенда дип тә, коттедж-фәлән дип тә түгел, замок, ягъни дә кальга дип атаган. Сәфәргали карт андыена ук үрелмәс, өч катлы тыйнак кына коттедж Зөләйхасы белән икесенә таман гына булыр. Йә, төзетте ди, җәйге ямьле иртәләрнең берсендә йокысыннан торып, террасага чыгып басты ди. Күңелендә әлеге шул җыры: «...эләп куйдым читәнгә. Күзем төшсә, күңелем төшми синнән башка бүтәнгә». Ул арада, көмеш

чиләгән тотып, сыер саварга Зөләйхасы килеп чыкты ди. Нигә көмеш? Соң, миллионер бичәсе була торып, гади калай чиләк тотып йөрмәс бит инде. Менә дигән карагайдан буралган абзарга чаклы да җәяү бармас, Ырынбур гипер-маркетындагы кебек эскалатор эшләтеп куярга туры килер. Ярар, шушы дөньяны коруга байлыгының егерме миллионы китте ди.

Сәфәргали карт, маллары астын тазартып, бозавын тауга чыгаргач, чөкердәшә-чөкердәшә, иртәнге чәй, юк, чәй түгел, кофе эчәләр. Аннары киенеп-ясанып чыгалар да төймәсенә басмастан үкереп кабынырга торган салам эскерте дәй зур джипка утырып гүләйт итеп кайтарга Тукмаклыга, йә Ырынбурның үзенә үк сыпырталар. Тукта, бәлки, иномарка джип алганчы, иномарка трактор гына алыргадыр? Алдында көрәк, артында соскы, тагырга арбасы, сабаны, тырмасы, чалгысы, ургычы. Үзе дә бозавына урак тотып үлән урып йөрми, авылдашларына да ярдәм итә. Тозкүз Гыйлваннан башкасына... Әмма тракторга утырып Ырынбур белән Уфага барып булмый бит. Димәк, икесе дә кирәк!.. Тагы ун миллион...

Үзенә әлеге кием-салымы да ярар. Түшенә орден-медальләре тагылган кәчтүме бар, кышлык кияр туны бар. Ә менә Зөләйхасын баштан-аяк затлы киемнәргә төрендерергә кирәк булачактыр. Җәйгелеген Сәфәргали карт анык кына күз алдына китерә алмады. Кышкылыкка пимике тун, юк, шәшке генә дә түгел, «шиншилла» атлы күсе тиресеннән тегелгән тун алып җибәрерләр. Иң бай олигархларның бичәләре шиншилла тун кия икән дип газитта укыган иде ул. Аягына берничә көзгеләрдән калышмый ялкылдап торган французский итекләр. Бот төбенә җитә язганнары... Шиншилла тун киеп башына гади дебет шәл ябынып йөрмәс бит инде. Ак төлке тиресеннән тегелгән бүрек тә юнәтергә туры килер. Карчыгының җитмеш яшенә бүләк иткән алкасы гади алтыннан гына, кечкенә, матур колакларына бриллиантлы алкалар алып тагу да мишәйт итмәстер. Боларына да ун миллионнан ким чыкмас... Менә сиңа кырык миллион. Калган уны инде Уфадагы балаларына.

Сәфәргали карт кибеткә чәй-шикәр алырга китеп барган карчыгын күз алдына китерде: Башында песец бүрек, өстендә шиншилла тун, аягында бот төбенә җитә язган французский итекләр... Авылның бар бичәләре тәрәзәләренә капланганнар, көнләшүләреннән йөзләре бозылган. Күз алдына китерде дә, үзе дә аңгармастан, кеткелдәп көлеп җибәрде.



Зөләйхасы уянды, авыз эченнән мыгырдангандай итте дә, картын тагы диванга куып җибәрде.

Болар барысы да йокысый алмый изаланып ятканындагы буш хыяллар. Карчыгы белән аның үзенә ни кирәк? Берни дә кирәкми. Хәләл көчләре белән корган дөньялары түгәрәк. Уфадагы балаларына кирәкме?

Юк. Кызы Таңсылу троллейбус йөртә, кияве Зәбир торак-коммуналь хуҗалыгында тир түгә. Машиналары бар, фатир зурайткандагы ипотекаларын түләп беттеләр. Хәзер үз балаларына ярдәм итәләр. Әлеге ун миллионны аларга тамызса ни эшләрләр? Зәбирен бөтенләй эчкече үк дип әйтеп булмый, әмма кунакта–фәләндә рюмкага башы белән төшеп бара. Җилдән килгән акча аны бөтенләй сәрхүшкә әйләндермәсме? Картның исенә капыл гына сугылыптан соңгы елларда булган бер вакыйга төште. Тукмаклыда революциягә чаклы ук тезелгән спирт заводы эшли иде. Бик кирәкле чималны тимер юл белән Ырынбурга ул чакларда тимер юлнең төрле почмакларына озаталар. Егерме чиләк сыешлы тимер мичкәне ни- юл юк, ат җигеп ташыйлар. Егерме чиләк сыешлы тимер мичкәне чек Бүлә елгасы әрәмәлегендә төшереп калдырганнардыр: арбалары ватылыпмы, эчепме, сугышыпмы – анысын шайтан гына белә. Гайнәви атлы авылдашлары тапкан, арбага ничек төягәннәр, йортына алып кайтып, келәтенә бикләгән. Иртән кереп чөмереп ала икән, төшен дә керә икән, кичен дә. Колхоз складыы мөдиренең гел генә салмыш йөрүенә Өчкуян халкы күнегеп тә киткән. Хуҗалык мөлкәте кулында бит. Шул байлыкның кечкенә өлешен тамагына тамыза икән, колхоз белмәс әле, янәсе. Озакламый келәттәге эчемлекнең төмен аллы-артлы үсеп килгән өч малай да белеп алган. Алар да булыша икән атиларенә. Бу гыйльләнең азагы ни белән беткәнен Сәфәргали карт юньләп хәтерләми. Малай гына иде бит әле ул чакта. Гайнәви инде күптән мәрхүм, аның уллары да дөньяда юклар. Гомумән, нәселләре корыды Хисмәтовларның.

Юк, әлеге хәрамның бер генә тиенен дә үз файдасына, балалары файдасына тотынмас!

Ә кем файдасына тотынырга бу акчаны? Авылы, туган төягәнең берәр җыртыгын ямаса дөрес булыр. Әйтик, күпер. Бүлә елгасы аша күпер. Елгалары җәен генә чалбар балагын күтәреп кичеп чыгарлык. Көзге яңгырларда, язгы ташкыннарда кулга өйрәтелмәгән яшь айгырдай ажгыра. Колхозның бер өлеш кырлары аргы якта була торган иде. Язын чәчүгә техника, орлык, ашлама чыгарганда егерме биш чакырым урап чыгаралар. Күпме эш, күпме

мәшәкать! Колхоз рәисе Сафин, Ходай авыр туфрагын җиңел итсен, заманында күпер төзетте. Бөрҗән якларыннан карагач бүрәнәләр ташытып төзетте. Тик елга Бөрҗән карагачларын да саңга сукмады, биш-алты елдыр түзде, аннары, чыгарыннан чыгып, теге карагачларны Ырынбур якларына агызып алып китте.

Хәзер инде колхоз юк. Елга аръягындагы басуларны фермер Фәткулла гына эшкәртеп маташа. Ул да, Бүләнең холкын белгәнгә күрә, анда бодай белән арыш икми, көнбагыш кына чәчә. Ул эш инде Бүлә ярларына кайткач, соңлап кына, башкарыла. Уңышы күпме буладыр, анысын ул үзе генә белә, җир туңып кырпак төшкәч кенә җыеп ала.

Сәфәргали картның бу эшләрдә кайгысы юк дисәк, дөрес булмас. Әмма аны, аны гына түгел бар авылдашларын, борчыган нәрсә – зыяратның су аръягында булуы. Монда тәү килеп төпләнгән карт, бер атып өч куян алуы белән мактанган аучы Галиәхмәт, үз йортын Бүлә аръягында төзегән булган. Аның янәшәсендә башка кардәшләре дә. Тик яши-яши тека ярның ел саен ишелә барып йортларына якынлашуыннан хәвефләнгәннәр дә, әйләп Бүләнең бирге ягына күченеп беткәннәр. Ә ата-бабалар күмелгән зыярат аргы яктагы калкулыкта торып калган.

Бу дөньядагы мәшәкатьләреннән авылдашлары җәен арынса кичүдән алып чыгаралар, кышын – боз өстеннән, язын-көзен инде әлеге егерме биш чакырым урап... Күршеләрдән оят! Җирдә егерме беренче гасыр хөкем сөрә бит! Төп юртына кайтканда, әрвах шулай күршеләр күперенннән урап кайтырга тиешме? Корамшин нидер хәстәрләп маташа, булса кирәк, тик бер дә нәтиҗәсе чалымланмый...

8

Сәфәргали карт Корамшин кабинетының ишеген шакыды, «керегез» дигәнне көтми, ача бирде. Түрә анда берүзе генә түгел иде. Мәктәп директоры белән тәкәтмә өстәл артында кара-каршы утырып алганнар, бирелеп китеп гәпләшәләр. Шыгырдап ишек ачылуга икесе дә карашларын картка юнәлттеләр. Карт аларга комачауламас өчен ишекне кире ябарга уйлаган иде, тик кабинет хуҗасы керергә чакырып кулы белән ишарә ясады.

– Сауламы әле, егетләр... – Әйе, үз күреп «егетләр» дип эндәште, «Сәүбән Сәйдәшович», «Габит Сабитович» дип эндәшсә,



арытабангы әңгәмәсенең бик тә рәсми килеп чыгарын чамалады. Хәзер инде бабай корына кереп барган «егетләрнең» йөзләре яктырып китте. Алар бит икесе дә заманында Сәфәргали мәктәбен үткән җитәкчеләр. Тәү Сәүбәне уңыш җыю чорында Сәфәргали комбайнында штурвальный булып йөрде. Ул, урта мәктәпне тәмамлап Уфага авыл хуҗалыгы институтына киткәч – Габите. Сәүбәне зоотехник булып авылга кайтты, озак та үтми аны комсомолның райком секретаре итеп үрләттеләр. Заман җилләре комсомолны партиясе белән бергә каядыр очырып алып киткәч, кире авылга кайтты. Габите дә, пединститут тәмамлагач, әллә кайларга чыгып китмәде, туган мәктәбендә балаларга рус теле һәм әдәбияты укытты, менә байтак еллар инде директор булып эшли. Начар эшләми, Өчкуян урта мәктәбе районда алдынгылардан исәпләнә. – Сезгә комачауладым, ахры, егетләр.

– Юк, юк, Сәфәргали абзый, – дисештеләр икесе дә.

Мәктәп директоры урыныннан торды. Хакимият башлыгы каршысындагы шул урынны Сәфәргали картка тәкъдим итте. Үзе чыгу ягына юнәлгән Гайсаровны:

– Тукмаклыга бергәләп барабыз, Габит Сабитович. Зав. РОНО-сы белән дә чикаләшәбез, кирәк икән район башлыгына да бергә керәбез, – дип эләктереп калды. Аннары карт ягына борылып, – Сволочьлар! – дип сүгенде.

– Кемнәрне шулай бик каты сүгәсең, Сәүбән Сәйдәшович?

– Кемнәрне булсын, тегеләрне инде, – Корамшин уң кулының имән бармагын түшәмгә төбәде.

– Районда утырганнарынымы ни?

– Аларын да. Өстән нинди фарман төшә, йөз илле процентка җиткереп үтәү өчен тиреләреннән чыгарга әзерләр. Ә тегеләре... Тәү илне таркаттылар, партияны юкка чыгардылар, ил байлыгын бүлешеп алдылар. Хәзер инде балалар ямьлешы белән уйныйлар. Үзең белмәгән-ни эш бар, Сәфәргали абзый. Хастаханәбезне ябып куйдылар, чират мәктәпкә җитте. Имеш, оптимизация. Оптимизация түгел бу, язучы Марсель Сәлим әйтмешли, япимизация.

– Нигә, мәктәпне дә ябарга әйтәләрмени, Сәүбән энем.

– Ябуын ук ябмыйлар, тугыз еллык мәктәпкә калдырырга әйтәләр.

Имеш, өлкән сыйныф укучыларын, автобуста йөртеп, район үзәгендә укытачаклар. Бу бит балаларны җирдән аеру, туган төбәгеннән биздерү!.. Өчкуян мәктәбе районда иң тәү ачылган

урта мәктәпләренең берсе. Тоң тугыз еллыкка калдырырлар, аннары – башлангыч, аннары инде ябуга да чират җитәр. Мәктәп булмагач авыл буламы ни? Болай да яшьләр авылдан китеп бетеп бара…

– Яптырмаска кирәк, Сәүбән Сәйдәшович.

– Мәнә шул турыда киңәш кордык та инде Гайсаров белән. Йә ярар, Сәфәргали абзый, пиндидер йомышың бар, булса кирәк! Әйт… Урыслар бит: «Соловья баснями не кормят», – диләр…

– Йомыш дип… Йомыш та түгел инде ул, Сәүбән энем, авыл халкының уртак хәсрәте. Бүлә аша күпер булыр микән берчак, булмас микән, дияүем. Безне дә аргы якка аткарырга күп калмаган. Максимовка аша урап алып чыгарсыз микән?

– Их, Сәфәргали абзый, минем тагы бер авырткан җәрәхәтемә тоз сибәсең бит. Хәзер өч ел инде проект-смета документациясе анау сейфымда ята. Бюджетта акча юк дип, төзелеш башлауны ел саен кичектерәләр. Берсеннән-берсе уздырып коттеджлар төзергә, берсеннән-берсе тәкәррек иномаркалар алырга, әллә кайсы якларга сәфәрләр кылырга ил акчасы җитә, күпер төзергә акча юк!..

Бу кызып китүенең нәтиҗәсезлеген аңлап, булса кирәк, хакимият башлыгы тынып калды.

– Ә ул төзелешкә күпме акча кирәк соң, Сәүбән Сәйдәшович?

– Сер дисәң сер түгел, Сәфәргали абзый, әлеге кәгазьләрдә утыз миллионга чыгарып куйганнар инде. Ә монысын сиңа сер итеп кенә әйтәм: егерме миллионы җитә аның, калган уны – откатка.– Хакимият башлыгы ике бармагы белән авызын бикләгән хәрәкәт ясады. Сер итеп кенә, абзыкаем. Берәүгә дә – ләм-мим! Белеп-нитеп калсалар, миңа да кайтүк, күпер турында да оныттырга туры килер…

Сәфәргали карт та тормыштан ул чаклы артта калган кеше түгел. Заман казанышы откатның ни икәнлеге турында хәбәрдар.

– Кемгә?

– Анысын инде мин дә белмим, Сәфәргали абзый. Нәнди кесәләргә барып ятадыр да, кемнәрнең байлыгын тагы да кабартадыр?

– Ярар, Сәүбән энем, күп сүз – буш сүз, диләр. Әйдә мәсьәләгә икенче яктан килеп карыйк әле. Әйтик, утыз миллион табылды ди…

Хакимият башлыгы картка гаҗәпләнеп карап торды.

– Ничек табылды ди, Сәфәргали абзый? Кайдан табылды ди? Кайда яткан капчык тулы акча? Кем төшереп калдырган аны? Кызык кеше син, Сәфәргали абзый. Моңа чаклы бер дә буш сүз сөйләми идең.



– Буш сүз түгел. Укымышлы адәмнәр әйтмешли, чисто теоретически. Мәсәлән, бар ди ул бер капчык акча…

– Ярар, теория икән теория. Бер кайда да хисапланмаган, беркемнең счетка да кермәгән утыз миллион акчамы?..

Сәфәргали карт чак кына, утыз түгел, илле миллион дип, ычкындырып ташламады.

– Әйе, утыз миллион.

– Аны син ничек күз алдына китерәсең, Сәфәргали абзый. Тегендәге бурлар, – Корамшин тагы да тырпайган бармагын түшәмгә юнәлтте, – Счеттагы, ягъни дә мәсәлән, компьютер исәбендәге миллионнарны, миллиардларны чит ил банкларына күчереп чын акчага әйләндереп кесәләренә салырлар бит. Әле генә юк иде, менә бар. Төзелеш өчен түләргә акчаны бит капчыклап тотып йөрмиләр. Ул бюджетка язылган, хакимият счетына кергән булырга тиеш.

– Соң, заманында колхозыбыз бит байтак биналарны әрмәннәр яллап төзетте. Килделәр, төзеделәр, акчаларын алып кайтып киттеләр… Әле дә шулай эшләп булмыймы ни?

Картның ныкышып утыруына хакимият түрәсе аптырый ук башлаган иде инде.

– Кем рәхсәт бирсен инде Сәфәргали абзый, андый төзелешкә? Әле бюджет акчасы бүленгән халдә дә проект-смета документациясен әллә ничәмә тапкырлар тикшерүләр, әллә кемнәрдән әллә ни чаклы кул куйдырулар… Аннары төзелеш фирмалары арасында конкурс оештыру, иң тиз, иң арзан, иң сыйфатлы итеп төзүчесен сайлап алу… Күптән бетте ул «Әрмәнстрой» трестлары. Бу очракта «иң-иң» дип инде, билгеле, «Прокоп» төзелеш фирмасы табылачак. Төшемле подрядны район хакимияте башлыгының кияве Константин Олегович Прокопчукка бирми, кемгә бирсеннәр… Әлегә, Сәфәргали абзый, менә шулай коры сүз болгатып кына утырырга кала.

– Димәк, иләмәгән, сукмаган, улым, сиңа бер ыштан кебегрәк була инде безнең әңгәмә, Сәүбән энем.

– Өстенә бастың, Сәфәргали абзый. – Хакимият башлыгы кычкырып көлеп җиборде. Аннан капыл гына туктады да гаҗәпләнебрәкме, әллә шикләнебрәкме картка карады. – Туктале, кайдан килде синең башыңа җирдә аунап яткан миллионнар турында хыял?

Әллә бер-бер нәрсә сизенде инде дип, карт хәвефләнеп куйды, сүзне шунда ук икенчегә борды.

– «Фәткыйр планы» дигән әйтемне ишеткәнең бармы, энем?

– Ник ишетмәскә. Бушка хыялланган кешегә, Фәткыйр планы корып утырма әле монда, диләр.

– Безнең авылның гына әйтеме ул. Заманында авылыбызда карчыгы белән Фәтхрахман атлы карт яшәгән. Яшьтән эшләргә яратмаган, балалары булмаган, хәерчелектә күп күргәннәр. Икесе дә хыялланырга яраталар икән. Нигез ташына чыгып утыралар икән дә, карты сүз башлый ди: «Әби, әнә Вәнихә тавы өстендә болытлар куера. Хәзер килеп яңгыр явып җибәрсә? Гади яңгырдан файда юк, бәлки, иген явар, вет шәп булыр иде», – ди икән.Карчыгы карты сүзләрен хуплый ди: «Яуса да ул безнең ишек алдына гына яусын, Мөкәррәмә ишек алдына бер бөртеге дә таммасын. Саран ул, җәймә пешереп ашарга бер калак он да биреп тормады». «Бар әле, бар, карчык, йөгереп кенә кер дә өйдәге бөтен паласларны, киезләрне, юрганнарны җыеп алып чык. Иген, чынлап та, яварга охшый, ишек алдын тутырып җәеп куярга кирәк». Көтәләр ди болар шулай иген яуганын көннәр буе палас өстендә утырып. Без дә синең белән «Фәткыйр планы» корып утырдык, булса кирәк, Сәүбән Сәйдәшевич. Гаепкә алма...

Өчкуянның өчтән бергә торып калган кибете төбендә дүрт-биш бичә гәпләшә иде. Ул кибете дә райпо карамагыннан ничек-тер Фәткулла фермер кулына күчеп өлгергән иде. Азыкка хакны ничек теләсә, шулай куя, кибетен дә кайчан ачарга теләсә, шунда ача. Иген игүен ташларга, сәүдә белән ныклап шөгыльләнә башларга чамалый, имеш. Иген игеп кем баеган, дип зарлана икән. Бичәләр әңгәмәсе дә, бәлки, шул турыда булгандыр. Карт ул әңгәмәгә кысылып торуны артык санады, аларга сәлам бирде дә ары китте.

Мәктәп ихатасында бер төркем бала кайнаша иде. Берәүләре чүчкә туташларе утый, икенчеләре су сибә. Бу ямьле күренештән карт-ның тәшә барган кәефе күтәрелә бирде. Директорлары да яннарында. Габит Сабитович Сәфәргали картны күрде дә, янкапкадан чыкты.

– Бая гына күрешкән идек инде, Сәфәргали абзый, менә тагын очрашырга язган. Тегендә хәлләрегезне сорашып торырга форсат булмады, йә сөйләп кит соң: ничек көн күрәсез, Зөләйха апа ни хәлдә, авырсынмыйсызмы, берәр ярдәм кирәкмиме? Тимур коман-дам бар минем, эшегез булса, «ә» дигәнче эшләп ташларлар...

– Безнең хәләр ул, Габит энем, зарланырлык түгел. Кем әйтмешли, ат юк урамда, кайгы юк бурауда. Пенсиясен ай саен ки-



тереп торалар. Менә мәктәп хәлләре мактанырлык түгел икән дип ишеттем әле. Ничек соң, чынлап та ябарга әйтәләрме?

– Кызганычка каршы, мәктәпне урта мәктәп статусыннан мәхрүм итәргә әйтәләр. Дәһшәтле сугыш елларында урта мәктәп итеп эшләтергә акча булган, хәтта укытучыларга ягулык, лампаларына керосин биргәннәр, юньлерәк киенеп йөрсеннәр дип, күлмәклек, ко-стюмлык материал... Ә бүген? «Подушевое финансирование» атлы нәрсә уйлап чыгардылар, ягъни акчаны балалар башына бүлү. Шәһәр мәктәпләре өчен, бәлки, бу нәрсә начар түгелдер, анда бала-лар күп, бездә бит елдан-ел кими. Быел өлкән сыйныфларны кыскар-тырлар, киләсе елга – урта сыйныфларны. Даныы Өчкуян урта мәктәбе башлангыч мәктәп булып калырмы? Тормыш бит кайчан да булса рәтләнеп китәр, балалар күпләп туа башлар, аларны кайда укытырбыз? Булганны ябу, юкка чыгару җиңел ул, булмаганны булдыру ай-һай авыр.

– Соң, район түрәләрен ямаска күндерергә кирәк.

– Алары Уфага сылтана, Уфасы – Мәскәүгә...

– Әллә Мәскәве дә берәрсенә сылтанамы, Габит энем?

Директор йөзендә саран елмаю хасил булды.

–Ышансаң ышан, Сәфәргали абзый, ышанмасаң – юк, сылта-налар!

– Кемгә?

– Кемгә булсын, Америкага! Имеш, анда балалар укыту түләүле. Бездә дә бар укыту-тәрбия барышын түләүлегә күчереп ба-рабыз. Имеш анда «ЕГЭ» атлы бердәм имтиханнар үткәрелә. Без дә балалар белемен ЕГЭ ярдәмендә генә сынарга тиешбез. Балаларга сорау-җаваплар ятлатып, аларны үзаллы фикерли алу сәләтеннән мәхрүм итәбез... Баш җитәрлек түгел!..

– Сезнең баш та җитмәгәч, Габит энем, безнеке ничек җитсен инде?

Көн дә район үзәгенә йөртелергә дучар балаларны нишләтәбез соң? Әллә дим, теге подушевое финансированиегә өстәмә акча кушып мәктәпнең өлкән сыйныфларын саклап алып калабызмы?

– Нинди өстәмә акча ул, Сәфәргали абзый?

– Әйтик, ул акча табылды ди...

Мәктәп директорының фантазиясе дә хакимият башлыгыны-кыннан ары китмәгән икән.

– Бүлмә әрәмәсендә аунап ятамы ул шыгрым тулы акчалы кейс? Әллә Айчумган ятуына ташлап киткәннәрме?

Хәер, бусының күзаллавы тегесенекеннән дөреслеккә якынрак килә икән. «Капчык» дими, «кейс» дя, әйтерсең үз күзләре белән күргән, «шыгрым тулы» ди.

– Мин бит болай гына, Габит энем... Саубән Сәйдәшевич әйтмешли, чисто теоретически...

– Алай гына «Фәткыр планы» була шул ул, Сәфәргали абзый. Юктан бар булган акчаны ничек легализовать итәсең дә, ничек бюджет акчасына кушып җибәрәсең?

– Ярар, ярар, Габит энем, ул турыда сүз куертмыйк. Әллә орден, медальләремне тагып Тукмаклыга мин барып килимме? Җәмәгатьчелек фикерен дә ишетсеннәр, диюем. РОНО мөдиренезгә дә әйтер сүземне әйтермен, хакимият башлыгына да халык фикерен җиткерермен...

Мәктәп директоры уйланып торасы итте.

– Юкка мәшәкатьләнеп кенә йөрүең булмас микән, Сәфәргали абзый? Хәер... Тамчы тама-тама таш тишә, диләр бит. Барып кара сон...

## 9

Зөләйха карчык тынычлыгын тәмам югалтты. Илле дүрт ел бергә яшәгән картына әллә ни булды. Аңардан нилер яшереп, остаханәсенә кереп бикләнә. Анда хәмер алып куеп йөрмәгәнедер диесең, андый гонаһы гомердә булмады иренең. Дөрес, кунакларда чамасын белеп кенә тоткалый иде. Хәмер җиңелчә башына сукканда әлеге шул яраткан җырын җырлап та җибәргәли иде: «Ай югары, ай югары, айга менәсем килә. Айга менеп, түбән карап, сине күрәсем килә». Яраткан җырын, «Зөләйха» исемлесен! Яратып алган, яратып яшәгән халал җефете Зөләйха, яраткан җыры «Зөләйха»!..

Әллә Зөләйхасыннан бизеп башка берәрсенә күзе төштеме? Унсигез яшьлек чибәрләрне карата алмаса да, кырык биш-илледәге тол бичәләрнең башын әйләндерерлек төсе, сыны, дәрте, куәте бар әле аның. Юньле ир метр сиксәннән башлана дигән мәрәкә бар. Авылдашлары аны гомер буе «Озын Сәфәргали» дип атап йөртте. Ярый әле комбайнның кабинасы юк, трактор кабинасына ничек сыя икән, дип көлә дә торган иделәр. Әле дә, кайсы бер картлар кебек, җиргә чүгә башламаган. Бөдрә чәче агарган, әмма сирәкләнмәгән дә дип әйтерлек. Берчак Тозкүз Гыйлван халык алдында



көнләшеннән: «Бәй,бәй, Сәфәргали, чәчең ап-ак булган, ләбаса!» – дип көлеп маташкан икән. Сәфәргали: «Ак булса да чәч бит әле ул!» – дип тегенең коштта ялтыраган пеләшенә ишарә ясаган.

Озынча йөзенә дә әле аның узган еллар сырларын бик күп салмаган. Гыйлванның түгәрәк йөзе генә базда ятып шиңгән бәрәңгегә охшап бара. Гыйлванның яшькелт күзләре күптән төсен югалткан. Шуңа күрә дә «Тозкүз» атамасы биргән дә инде аңа авылдашлары. Картының көрән-кара күзләре һаман да очкыннар чәчәргә сәләтле. Картайса да, матур картая ала торган кешеләр була. Зөләйханың карты әнә шундыйлар токымыннан. Зөләйханың шиге әллә, чынлап та, дөреска чыгарга уйлый микән? Алачыгына бикләнеп, әллә янә мәхәббәте белән кесә телефоны аша серләшәме? Тик торганнан Ырынбурга чыгып китте. Үз әбиен үзбәк калүше белән ризалатып, тегенә бүләккә алтын алкамы, йөзекме алып кайтты микән әллә? Юктыр! Булмас! Яшь чагында тирәсендә бөтерелгән бер чибәргә дә карамаганны, картайганда тыртаймас. Заманында авылга, институт тәмамлап, агроном кыз килгән иде. Яшь, чибәр. Колхозның алдынгы механизаторына гашыйк булган дигән хәбәр тараттылар. Аны үзенә каратырга, гаиләсеннән аерып кайларгадыр алып чыгып китәргә маташкан диделәр. Бу гайбәттән Зөләйханың күңеле кителә бирде, әмма ул аны тышка чыгармады. Ә теге кыз үз мәхәббәтеннән үзе исереп йөрде-йөрде дә, туган якларына кайтып китте.

Әлеге хафалары да бушкадыр Зөләйха карчыкның. Тик картының соңгы көннәрдә үз-үзен тотышында ниндидер сер бар. Әнә бит, иртәнге чәен эчте дә, район үзәгенә барып кайтырга җыенды. Бу юлы Зөләйха карчык ризасызлыгын белдерми кала алмады.

– Тагы ни калмаган инде Тукмаклыда сиңа, этисе?

Сәфәргали карт ни әйтергә белмичә торды.

– Ни... Күптән пенсия бүлегенә барып килергә җыенып йөри идем, әнисе. Эш стажымны яңадан тикшертеп, пенсиямнең күләмен яңадан чамалатып карарга иде. Стажга керми калган елларым бар, булса кирәк. – Карт тотлыкты, ни әйтергә белмичә торды да, – Ятып калганчы, атып кал, диләр бит, – дип өстәде.

– Нигә, пенсияң җитми башладымы ни? – Шулай инде ул, яшьләргә күзең төшсә, пенсия генә җитми, дип өстәргә чамалаган иде дә, телен тешләп тыелып калды. Йөзенә битарафлык битлеге каплап, – Дәртләнгәч, барып кайт сон, – дигән булды.

Дәртләнүен дәртләнде дә ул Сәфәргали карт, тик пенсия фондына барырга түгел. Карчыгы аның кәефен шикләнүе белән төшерә алма-

ды. Берәр карарга килер дә, серс белән уртаклашыр, киңәшләшер... Кәефен аз-маз кырганы шул булды: автобусны алар Гыйлван белән бергә көтеп алдылар. Очрашкач, сүз дәшешми булмый бит.

– Йә, Сәфәргали, кайларга юл тоттың? Тукмаклыгамы, әллә Уфаның үзенә үкме? Син дә тик ятмыйсың... – диде Гыйлван, авылдашына тишәрдәй итеп карап.

Сәфәргали теләр-теләмәс кенә:

– Вак-төяк йомышлар белән, район үзәгенә, – дип җавап бирде.

– Мин дә Тукмаклыга барып кайтам әле. Пенсия билгеләп утырганнарны пыр туздырасым бар.

Сәфәргали карт ирексездән көлеп җибәрде. Ул карчыгына, пенсия фондына барам, дип алдап чыгып китте, ә бу адәм, чынлап та, анда китеп бара икән. Кызык!..

– Нигә пыр туздырасың аларны, Гыйлван?

Гыйлванның йөзе кызарынды-бүртенде, еларга җыенган баланыкыдай кыйшайды.

– Көлмә. Ничек була инде бу: бер авылда яшибез, гадукларбыз, син аена унсигез мең аласың, минем унга да тулмый. Өстәмәсәләр, Уфага жалу белән барам дип куркытам. Куркмасалар, мул гына ришвәт тәртәм. Аңа гына хәлем житәрлек минем. Көлмә! Көлке кәлә килә, артыннан куа килә, диләр. Пенсиямне синекеннән артыграк ясатмасам, исемем Гыйлван булмасын!

– Кулыңнан килсә, ясат соң...

Таяк таянып алган Гыйлван автобуска алгы ишектән керде, кешелеккә кия торган костюмына орден, медальләрен таккан Сәфәргали – арткы ишектән. Янәш утырмадылар. Сәфәргали картның башына капыл кызык кына фикер килде. Теге кейсны Гыйлванга ачып күрсәтергә иде. Көнләшүеннән йөрәге ярылмас иде микән?.. Билгеле, мондый «бәхет» Гыйлванга бер кайчан да эләкмәячәк...



...Аңа эләкмәс, әмма Зөләйха карчыкка эләкте. Ул, картын озаткач, кош-кортын карады, яшелчә түтәлләренә су сипте, иртәнге сөтен, кичкесенә кушып, сепаратордан үткәрде, икмәк алырга кибеткә барып килде, кичкелеккә карты кайтуына аш салырга дип суыткычтан ит алып куйды. Халык телендә «тавык чүпләсә дә бетмәс» дигән эшләр дә әлмы-күпме вакытка бетеп тора икән. Хәл алырга дип, ут алачыгы түбәндәге эскәмиягә килеп кенә утырган иде, әллә кайсы төшендә туган шиге тагы күңелен кимерә башлады. Ахры



да түзмәде, остаханә ишеге түбәндә бусагa ролен үтәгән ташны күчхәл белән күтәрә бирел, ачкыч алды, ишекне ачты. Үзенә дә оят, күпме гомер итеп, картының кесәсенә генә дә тыгылып караганы юк иде аның. Анда күзе күнеккән тәртип: һәр эш коралы шүрлекләрдә үз урынында. Ырынбурдан алып кайткан электр бораны гына катырга тартмасыннан алынмаган, шул килеш верстагы өстендә. Гаҗәп... Сынап карамый ничек түзде икән? Тагы бер тәгалсезлек карчыкның игътибарын үзенә җәлеп итте. Пычкы вагын, йомычканы карты бит иплән кенә себереп ала да муенча почмагында утырган зур тартмага аткара иде. Көзен сарымсак түтәлләренә сибәргә менә дигән ашлама. Җыештырмаган, верстак астында өелеп ята, анда нәрсәләр яшергәнгә ишарә итеп ята. Карчык шунда кулын тыкты, аңысы шунда ук чемодан тоткага эләкте, тартып чыгарган иде – уртача зурлыктагы чемодан. «Дипломат» та диләр, «кейс» дип тә атыйлар, ахрысы. Эчендә нәрсә? Картының Ырынбурдан яшь сөяркәсенә алып кайткан бүләгеме әллә? Затлы күлмәкме, джемпер-фәләнме? Алтын ялатылган бикләренә ике кулының ике бармагы белән баскач, кейс үзеннән-үзе чылтлап ачылып китте. Зөләйха карчык чел-тлатеп күзләрен йомды. Аларын йомганчы ук күреп калганы да җиткән иде. Сөяркә шатландырырлык күлмәк, йә джемпер булса да, ул чаклы аптыраган да, куркмаган да булыр иде. Күзләрен тагы ачты, егыл да кит, карты яшереп куйган кейста шыгрым тулы акча! Иллешәрлек белән йөзәрлек кенә дә түгел, гел биш меңлекләр!.. Өстәге рәттә дүртләп кабы житми житүен, аның бит калганы да исәпләсәң исән китәрлек!.. Зөләйха карчык, хәзинәне урнаштыргач, аңгы-миңгә килеп, ишек алдына чыкты. Нәрсә уйлап, ничек янар иде икән, ярый пошу белмәс күршеләре Фәйрүз килеп керде.

Айчумган ягуына балыкка

– Зөләйхаттәй, Сәфәр бабай кайда? Айчумган ягуына балыкка барабыз, тәртә озынлык шамбы тотабыз, дигән иде...

Карчык акылга бер тәрлерәк күршесен бер кайчан да раинжеткәне юк. Утыртып сыйлап та чыгара, өстен-башын да карап торыр иде. Бу юлы аның җавабы корырак чыкты:

– Сәфәргали бабаң Тукмаклыга китте, Фәйрүз. Шамбыны синнән башка да эләктергән инде ул...

Фәйрүзнең күзләре маңгаена менде.

– Кит әле, Зөләйхаттәй! Чынлапмы? Озынынмы? Тәртә буйлыгынмы?..

–Иң озынын, иң юанын!..

Автобустан төшкәч, Сафаргали карт озын урам буйлап районның төрле конторлары урнашкан мәйдан ягына табан атлады. Анда барып җиткәнче дә әле байтак могъҗизага хәйран калып барды. Кибетләр, кибетләр, кибетләр! Әйтерсең, гади район үзәге Тукмаклы түгел бу, Американың Кыргый Көнбатышында уисигезенче йөз башында калкып чыккан шәһәрчек. Кибетләренең этамалары гел генә әллә немец, әллә француз, әллә инглиз телендә. Зур-зур банклар! Алары «Экспресс-займ» атлы кечеләре белән чиратлаша. Берсенең башындагы утлы язу гына ни тора! «Деньги немедленно!» Бу язуны күреп, карт кесәсен бөтәрләп тотканын сизми дә калды. Хәзер, әзмәверләр йөгереп чыгарлар да, баштүбән әйләндереп кесәсендәге акчасын бушатып алырлар кебек тоелды. Аннысын исән-имин генә үтеп киткән иде, күзенә икенче вывеска чалынды: «Деньги мигом!» Бу юлы куркмаса да, адымын тизләтте. «Ваши деньги здесь!» дигән язулы бина турына җиткәч кенә җиңел тын алгандай булды. Бар икән әле дөньяда игелекле адәмнәр! Аптекалар да күп! Кечкенә шәһәрчеккә нигә кирәк булгандыр ул чаклы даруханә? Теге акча тәкъдим иткән конторга кереп җитәрлек хәтле акча аласың да, аптекага кереп күңелеңә охшаган дәва сайлыйсың. Рецепт язарга табибе-фәләне дә кирәкми, әнә телевизор үзеңне ничек дәваларга көнетөне өйрәтә...

Сафаргали карттан, бигрәк бер катлы дип, көләргә ашыкмыйк, кадерле укучыларыбыз. Барысын да күрә, барысын да белә, барысын да аңлый ул. Әле менә шушы көлкеле уйлары белән күңелен генә юата...

## 10

РОНО мөдире Сиргалин йокысыннан бүген соң уянды. Башы авырта, күңелендә элеп алып селкеп салырлык бер генә юньле фикер дә юк. Кичә Уфада балаларның җәйге ялын оештыру барышы турында киңәшмә үткәргән иделәр. Мәгариф турысенә Тукмаклы районының бу юнәлештә эшләп җиткермәве турында әче-әче генә тәнкыйть сүзләре дә ишетергә туры килде. Болгакка җиткәч, икс иптәше белән кафега кергәләр, әлеге «макталуларын» ярыйсы ук юдылар... Кайткач бичәсе Суфиядан каты гына эләкте. Имеш, ул булдыксыз. Бердән-бер уллары Эдикны Артекка җибәреп кенә дә ял иттерә алмый. Хакимият башлыгы Кривоносов менә дигән йорт төзетеп куйды. Мәскәү Рублевкасына алып барып утыртса да,



йөзенә кызыллык китерерлек түгел. Аның урынбасары Чураев йортына да кемнәр генә сокланмый!..

– Соң, җаныкаем, Чураев бит хакимият башлыгының төзелеш буенча урынбасары... – дип каршылашып маташкан иде дә ир, хатыны аның авызын тиз япты.

Ул урынбасар гына, ә син директор исеме күтәреп йөрисең. (Күптән түгел генә РОНО мөдирләренең вазыйфасын директор дәрәҗәсенә күтәргәннәр иде. Анысы дөрес булгандыр, югыйсә, фермада да мөдир, РОНО хәтле РОНОда да мөдир. Тигезсезлек ич бу! Эш хакларын да ярыйсы ук күтәреп, бу тигезсезлекне тигезләп куйдылар).

– Соң, малайны ял итәргә Кырымга җибәрү мәсьәләсе хәл ителгән, дидем бит инде...

Суфиясының ачулы йөзе бу хәбәрдән генә язылмады.

– Ә йортың! Һаман башын яптыра алганың юк. Ә машинаң? Мәскәүдә генә җыелган «РЕНО»га утырып чыгарга оят, билләһи! Юньле адәмнәрнең бичәләре ел саен тун алыштыра, минем шәшке туныма өч ел тулып дүртенче китеп бара...

Бу битәрләүләрне Сиргалин көн саен ук булмаса да, көн аралаш диярлек ишетә. Аек чакта ишетүенә күнегеп беткән инде, бахмурдан башы чатнап барганда бигрәк кыен.

Эшенә барып утыргач, секретарь кызына;

– Берәүне дә кертмә, кәгазьләр өстендә эшлисем бар, – дип әмер бирде.

Анысы, билдәнме, билдән түбәнрәктәнме сыйпар микән, сыйпамас микән, дисбрәк көтеп торасы итте. Сиргалинда яшь бичәнең биленнән дә, билдән түбән төшеннән дә сыйпау кайгысы юк иде. Секретарь моны аңлады.

– Кофе ясап кертимме, Харрас Хафаевич?

– Керт...

Кофе чөмереп, аңгы-миңге килеп утырып, бер сәгать чамасы вакытын үткәргәндер, алгы бүлмәдә ниндидер ыгы-зыгы купты. Ул арада ишек «шар» ачылып китте, кабинетына озын гәүдәле бер карт килеп керде. Аның артында секретаре чәбәләнә иде.

– Мин рөхсәт итмәдем аңа, Харрас Хафаевич!.. Мин...

Түрә секретарена чыгарга ишарә ясады. Йөзенә мөмкин хәтле усаллык чыгарып сөмсез картны күзеннән үткәрде, «Вон минем кабинеттан!» – дип куып чыгарырга чамалаган иде, күзе карт түшендәге наградаларга төште. Сөмсез булса да, гади авыл карты түгел икән. Ә

анысы бирен булмагандай кулын пиджагының кабарыбрак торган кесәсенә тыкты, аннан нидер чыгарды да түрә өстәленә салды. Өстәлгә «шап» итеп килеп яткан ике кап акчаның исе бар бүлмәгә таралгандай булды. Ике кап – тоташлае белән миллион!

– Б-бу нәрсә? – диде кабинет хуҗасы, телен чак әйләндереп.

– Акча, – диде Сәфәргали карт, йөзенә исе китмәгән кыяфәт чыгарып. Сезнеңчә әйтсәк, «бабло» буладыр инде.

– Миңа, намуслылардан намуслы җитәкчегә, ришвәт төртергә чамалыйсыңмы ? – Хәзер ишек ачылып китәр дә анда кара киемле адәмнәр килеп керер кебек тоелды аңа. Бүлмәдә әзгә генә тынлык урнашты. Хокук сакчылары күренмәде.

– Ришвәт түгел, Сиргалин әфәнде, спонсор ярдәме генә. Акча җитми дип Өчкуян мәктәбен тугызъеллыкка калдырырга җыенасыз икән. Менә шул җитмәгән акчагызга Өчкуян авылы халкыннан зур булмаган өстәмә. Әлеге уегыздан кире кайтуыгызны үтенәбез…

Директор җиңел итеп тын алгандай булды. «Педагогика» журналы белән әлеге капларны өстәле тартмасына сыпырып төшерде. Күз алдына нишләптер капка төбенә чыгып йодрык болгап калган Суфиясы килде. Йодрык болгаганда гына ямьсез ул, елмайса, бар дөнья ямьләнеп китә. Кичен кайтып кереп, капларны шапылдатып бичәсенең бизәнү өстәленә ташласа, елмаймый кала алыр микән. Бәлки, берсен генә тоттырыр, ул берсе дә өе башын ябарга да, хәләл җефетенә чираттагы шәшке тун алырга да җитәр. Икенчесенә диңгез буйларына барып, ярыйсы ук калкып барган корсагын кояшта кыздырып кайтыргадыр. Секретарь белән бергә…

Сиргалин һаман басып торган картка урын күрсәтте.

– Сез кем буласыз, абзый кеше? – диде.

– Утырып озаклап тормыйм, Сиргалин әфәнде, – диде карт, кул сәгатенә күз ташлап. Мин – элекке «Җиңү» колхозының элекке алдынгы механизаторы Сәфәргали Байтимеров. Хаклы ялда булсам да, дөнья мәшәкате җитәрлек. Әлеге үтенечебезне аяк астына салып таптамассыз дип, ышанып килдем.

– Шушы хәтле абруйлы ветеран башын иеп килгәч, уйлап карарга туры килер инде, – диде түрә, тотлыгуыннан һаман арына алмый.

– Уйлап карамагыз. Хал итегез, – диде карт коры гына. Тракторы белән басу башына барып туктап, сөререгәме, сөрмәскәме дип, уйланып торган игенчене күз алдына китерә аласыңмы? Син дә ябаргамы, ямаскамы дип икеләнеп утырма…



Сиргалин картны озатырга алгы бүлмәсенә чыкты, аңа кулын сузды. Тик карт кул бирмәде, «Хушыгыз» белән генә чикләнде. Хәрам акча тотып йөреп, аның кулы болай да пычранып беткән. Менә хәзер хәрам эш тә эшләде инде.

Сиргалинның башы авыртуы басылгандай булды, күңеле күтәрелә төште. Хәтта утырган килеш сикырап та алды әле ул. Колагына диңгез шавы, акчарлаклар чыңгылдашуы ишетелеп киткән дәй булды. Егет сүзе бер була дилэр бит. Уйлап, икеләнеп утырмас, Өчтуган мәктәбен түгел, Максимовка мәктәбен кыскартыр. Өстән оптимизация планын төшереп утыручыларга барыбер түгелмени…

…– Миңа, кызым, район башлыгы урынбасары Чураев әфәнде кирәк иде, – дип эндәште Сәфәргали приемныйда утырган тулы гәүдәле бичәгә. Тулы гәүдәле генә түгел, чынлап та юан! Адәм боГына торыш беләкләре күлмәгенең кыска җиңенә чак сыйган, түшләре, эчетергә куелган камырдай кабарып, ачык изүеннән ташып чыгып бара. Сәфәргали карт бу зиннәтләргә туры карамаска тырышты. Ә хатын башкарып утырган әһәмиятле эшен, тырнак шомартуын, бүлми генә бер сүз белән җавап бирде:

– На больничном.

Мәгариф бүлеге түрәсе каршындап каушамаганны, Сәфәргали карт бу бичә каршында каушап калды.

– Бик кирәк иде бит әле, кызым.

– Барыгызга да кирәк, – диде усал ханым битараф тавышы белән, – Сез кырым чирүеләй, Чураев берүзе.

– Хастаханәдә ятамы, әллә өендә генә дәваланамы?

– Өендә булса әллә мәшәкатьләр идегезме? Кешегә юньләп авырырга да ирек бирмиләр…

Сәфәргали карт югалып калды, әйтер сүз табалмый бераз уйланып торды. Башына капыл гына бер хәйлә килде.

– Мине яхшы белә ул. Үзе: «В любой момент обращайся!» – диде. Дөресен әйткәндә, бу сүзләрдә арттыру да юк иде. Быел кыш Тукмаклы районын оештыруга сиксән ел тулу хөрмәтенә узгарылган тантанага Корамшин Сәфәргали картны да алып килгән иде. Район хакимияте башлыгы Кривоносов бер төркем ветераннарга, шул исәптән Сәфәргали Байтимеровка да, сәхнәгә чакырып, район хакимиятенең рәхмәт хатын тапшырды. Тантаналы җыелыштан соң кафедә мәҗлес үткәрделәр. Сәфәргали картның урыны Чураев белән янәш туры кил-

де. Ачык кеше булып чыкты, сөйләшеп, мәрәкәләшеп, көлешеп утырдылар. Шунда әйтелгән сүзләр иде бу.

– Нам не разрешено любому давать адреса, телефоны руководителей района, – диде бичә нишләптер урысчалап.

– Мин сезгә «любой» түгел, ветеран, Хезмәт Кызыл Байрагы, Октябрь Революциясе орденнары, «Хезмәт батырлыгы өчен» медале кавалеры Сәфәргали Байтимеров! Өчкуян чаклы Өчкуяннан килгәч, йомышымны йомышламый кайтып китәсем юк.

Секретарь бичә шунда гына, әлеге шөгыленнән аерылып, башын күтәрде, картка карады. Алдамый икән, түше тулы наградалар. Карт үзе атаганнардан тыш та байтак әле.

– Адресын бирәм, тик куып чыгарса, үзеңә үпкәлә, – диде. Улица Сосновая... Нарат урамы, бишенче йорт. Чуртан күле буенда...

Чураевның күптән түгел төзелеп беткән йорты, чынлап та, табигатьнең иң матур почмакларының берсендә урнашкан иде. Чураевныкы гына түгел, район хакимияте башлыгы Кривоносовныкы да, прокурор белән судьяларныкы да, мәгариф бүлеге җитәкчесенең әле башы әбылмаган коттеджы да. Аста җәйрәп яткан күл, калкулыкта, нарат урманы арасында менә шушы йортлар. Берсеннән-берсе зурлар, берсеннән-берсе матурлар. Соңгы елларда һәр шәһәр читендә яңгырдан соң гөмбәләрдәй калкып чыккан мондый бистәләрне халык күптән инде йә «Дворяннар оясы», йә «Патша авылы» дип атарга күнеккән.

Башка йортлар ихаталарында тынлык, бер Чураев йортының ишеге алдында эш кайный. Биш-алты ир-ингилдер корылма төзү белән мәшгуль, «аварып яткан» хуҗа үзе дә шунда, төзүчеләрен дәртләндереп йөри. Нарат ышыгындагы өстәлгә мул гына сый да куелган. Йөзе байтак алсулануына караганда хуҗа кеше өмәчеләрен генә сыйлап чикләнмәгән, үзе дә ярыйсы ук сыйланып алганн. Монысы Сәфәргали карт өчен уңай да булды. Кабинетында аек утырса, ничек кабул итәр иде әле. Монда янкапканы ачып керергәме-кермәскәме дип икеләнебрәк торган картны кочагын җәеп каршы алды.

– О-о-о! Өчкуян ветераны! Нинди җилләр безнең якларга ташлады?

– Җилләр ташламады, Сафа Тайфурович, зур йомыш белән килдем, теге вакыт «любой момент» дигән идегез бит... Мин, үзегез әйтмешли, Өчкуян ветераны Сәфәргали абыегыз булам.

Картның исемен оныткан иде ул, әмма:



– Хәтерлим, хәтерлим, Сәфәргали абзый, теге вакытны, – дип елмайган булды. Йомышын качмас, очрашу хөрмәтенә берне тотып җибәр әле.

Эчкечеләрнең гадәтен яхшы белә карт. Андыйлар сыеннан йөз чөерсәң, дошманына әйләнәсең. Шуның өчен хуҗа белән чәкәштергән булды, хәтта чак кына уртлаган хәрәкәт тә ясады.

– Мин монда, Сәфәргали абзый, өмә оештырдым әле. Болничный алмасаң, форсат тими. Беседкам һаман эшләнмәгән, ә җәй үтеп бара.

Сәфәргали карт ни әйтергә белми аптырабрак торды. Җәйнең кызу эш көнендә ялган больничный белән йортында бәйрәм итеп яткан түрәнең, биләһи, кыска ыштанын салдырып, арт ягын чыбыклар иде ул.

– Дөнья булгач аныcы да кирәк инде..., – дигән булды. – Мин инде бөтен авылдашлар исеменнән килдем сезгә, Сафа Тайфурович. Бүлә аша күпер юклыгы халыкны нык интектерә бит. Проекты да бар икән. Ничегрәк башлап җибәреп була соң ул эшне?

– Эш... эш... эш. Гелән эш! Ял да итә белергә кирәк бит, Сәфәргали абзый. Кая, тотыйк әле тагы берәрне, – хуҗа төзүчеләре ягына ишарә ясады, – Алар әйдә эшләсеннәр... Мин бит бушка эшләтмим, түлим. Беләсеңме, бу йортны төзүгә күпме акча китте? Тартып-сузып чак җиткердем. Әле һаман тартам-сузам... Бассейны кирәкме? Кирәк! Беседкасы кирәкме? Кирәк! Тагы әллә нәрсәләре кирәк! Менә шуңа эч пошa, йөрәк яна, әйдә тотыйк әле тагы берәрне. Бу сиңа, Сәфәргали абзый, простой хәмер түгел, «Виски» дип атала ул...

Сәфәргали карт әлеге шул сүзләрен кабатлаудан узмыра алмады.

– Дөнья булгач, барысы да кирәк инде, энем. Безгә ни шул күпер...

– Булыр ул күпер. Акча җитми бит! Быел булмаса, киләсе елга булыр. Киләсе ел булмаса, аннан ары.

– Туктале, Сафа Тайфурович, быел булмавы билгеле инде. Ничек шуны киләсе ел планыгызга кертеп җибәрергә икән? Аныcын хәзер үк хәстәрләргә кирәк бит.

– Бу, Сәфәргали абзый, катлаулы мәсьәлә. Күперегезнең проект–смета документациясе әлегә экспертиза да үтмәгән. Күз алдына китерәсеңме-юкмы район бюджетында шуны гына үткәрергә дә акча юк. Әйтергә дә оят!..

– Күпме? – дип ычкындырды карт үзе дә сизмәстән.

Түрә «Виски» атлы эчемлектән аларган күзләрен картның йөзенә юнәлтте.

– Нәрсә күпме?

– Әнә шул «икспиртизә» атлы нәрсәгезне үткәрергә күпме акча кирәк?

– «Акча» дип, авыз тутырып әйтергә дә оят, Сәфәргали абзый! Всего-навсего один миллион...

Карт яй гына пиджагының сул кесәсендә яткан ике капны китереп чыгарды, аларны сый өсталенә, алеге «Виски» шешәсе янәшәсенә урнаштырды. Хуҗаның күзләре тагы да алара биреп, көтүдән кайтып капкасын танымый торган сарыкныкына охшап калган иде. Ул байтак кына сүз дәшәлми торды.

– Б-бу н-нәрсә?

– Миллион, – диде карт, йөзенә булдыра алган чаклы битарафлык чыгарып.

Хуҗа капларны кулына алды, аларның авырлыгын чамалап та, иснәп карагандай да итте.

– Нинди миллион?

– Шыгырдап торган миллион.

– Шыгырдап торган икәнлеген үзем дә күрәм. Кайдан?

Карт наратлар арасыннан зәп-зәңгәр булып күренгән күк ертыгына ишарә ясады.

– Аннан... Әнә шул «икспиртизә»гезне үткәрергә дә безнен күперне икенче ел планына кертергә. Аңлашылдымы, Сафа энем.

– Шылды, Сәфәргали абзый. Попробуем...

– Пробовать не надо, Сафа энем, эшләргә кирәк!..

Карт чыгып китте, түрә, кулына ике кап акча тотып, аптырап калды. Исенә килә биргәч, акчаларны шорты кесәсенә тыкты, тагы рюмкага хәмер коеп йотты, үз эшләре белән мәш килгән төзүчеләргә ягына күз ташлады. Алары күреп-нитеп калмадылармы, янәсе. Бу могъҗизага нинди бәһа бирергә дә белмәде. Хыялыр Ильяс килеп китмәде дә инде аның йортына, гади авыл карты. Аптырарлык! Баш җитәрлек түгел! Кесәсеннән чыгарды да бирде... Әлеге шул, бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына, ди. Шул миллионны кайдан сәрмәргә белмирәк йөргән чагы иде аның. Кривоносов быел кәз пенсиягә китә. Өстә бер түрә бар, түрә дисәң, хәтере калыр, зур булмаган чиновник. Вазыйфасы бик зур булмаса да, җитәкче кадрларга алмашка кандидатлар исемлеген төзү, бушаган вакансияларга кемнәрне алып барып тыгу мөмкинлекләрен чамалау, кирәк чагында, зур түрә колагына үз тәкъдимен тишү – аның карамагында. Күптән түгел генә Чураевны чакырып әңгәмә корган иде. Соңыннан Чураев әңгәмәгә район җитәкчеләре арасыннан тагы бер-ике кеше чакырылуы турында белде. Әзерлек бара! Озакламый алеге адәм ялга китергә җыена икән. Форсатын туры китереп, кесәсенә шушы ике капны тыксаң, бик тә урынды булачак!.. Чураевның күтәренке кәефе тагы бер баскычка күтәрелде. Ул җырсызмонсыз үсте, үз гомерендә бер генә җыр откан иде. Өченче сыйныфта укыганда Гөлчирә апалары өйрәткән җыр. Җырлыйсы килеп китте. Урынлы-урынсыз дип тормады, авыз эченнән генә шул җырны көйләгән булды: «Куып җитәрбез, узып китәрбез Америкаларны якын илларда»...

## 11

Ришвәт алулары авыр микән, җиңел микән, алып карамагач, Сәфәргали карт аңысын белми. Ришвәт бирүләре ай-һай кыен! Тотсалар, тәртүчесен дә йомучысын да юкка гынаутыртмыйлар икән. Түрәләр алдында үзен тыныч кына тоткандай итеп күрсәтсә дә, картның аркасы буйлап кара тирләре акты. Үзен дуңгыз тизәгендә ятып аунагандай хис итте.

Кайтып та керде, карчыгы, чәй кайнатып, өстәлгә район үзәгеннән кайткан тәм-томнарны куйганчы, мунчасын ягып та җибәрде.

– Йомышың булдымы соң, этисе? – диде Зөләйха карчык, өстәл артына утыргач. Алачыктагы хәзинәне күреп көн буе ут йотуы турында башлап әйтәсе килмәде. Үзе сөйләп бирер әле дип өмет итте.

– Булды, әнисе. Исәпләре дөрес икән, аллә нәрсәләр юллап йөрисе түгел. Йөргән, әнә Гыйлван йөрсен. Нишләп син уйсигез мең аласың, минеке унга да җитми дип минә бәйләнеп маташа...

– Бер Гыйлван булмады инде ул, ун Гыйлван булды. Тотасың да шуның белән эләгешәсең.

– Мин эләгешәммени, ул бит. Яшь чакларда сине эләктереп кала алмавы белән һаман килешәсе килми... – Сәфәргали карт эчен тырнап яткан серен ничек Зөләйхасына чишәргә икән дип, юлда ук уйланып кайткан иде. Хәзер эшләргәме моны, аллә соңракка калдырыргамы? Юк, мунча кереп чабынып чыккач, малларны җыеп ябыргач, аш өстәле артында иркенләбрәк сөйләшергә уңай булыр дигән карарга килде карт. Сүзен кайданрак, ничегрәк башларга да чамаламады.

Җәйге көн искиткеч озын бит ул. Районда йөреп кайтты. Кайткач, бергәләп күпме вак-төяк эш башкардылар. Мунча кереп чыктылыр. Ниһаять, өстәлгә тәмле ризыклар чыгарып, бәрәңге белән ит утырттылар. Әле былтыргы тозлы-мозлысы да бетмәгән иде, аларына да урын табылды. Җитеш яшиләр, Аллага шөкер. Кунак чакыру да түгел, өстәл тулы азык. Тик Сәфәргалинең күңелен һаман да шул бер нәрсә игә. Карчыгының да, күрсәтмәскә тырышса да, кәефе юграк тоела.

– Әнисе, – диде карт, утырышкач. – Шкафта бер калган нәрсә бар иде, бугай? Китер әле шуны, әз–мәз тамак чылатасым килеп китте.

Зөләйха картына аптырап карап торды. Гомердә булмаган хәл!..

– Чылатасың килгәч, тор да үзең ал. Намазлыкка баскан мөслимәгә хәмер шешәсенә тотыну гөнаһ була ул.

– Әй, шулай бит әле. Гафу ит инде, сине чак кына хилаф эшкә этәрмәдем. Үземнең дә тамагым кычыту үтте... Бер мәзәк ишетеп кайттым әле.

– Ишетеп кайткач... сөйлә соң.

– Имеш, бер адәм сеңлесе аның туган көненә бүләк иткән лотерейга бик күп акча откан. Әллә ун миллион, әллә инде йөз миллион. Беркөн шул бичә абыйсы белән җиңгәсенең өенә йөгереп килгән. Абыйсы өйдә юк икән, яхшы хәбәрне хуҗабикәгә җиткергән. Эштән кайтуына, хуҗаны ничек шатландыру турында уйлашалар икән. Хуҗабикә хафа белдергән. Иренең йөрәге бик үк сау түгел, капыл әйтеп ташласалар, инфаркт-фәлән булмагае. Йайлап әзерләгәч кенә, иләп кенә әйтергә кирәк, дигән фикергә килгәннәр. Телгә оста булуын күздә тотып, бу вазыйфа сеңлесе кешегә йөкләтелгән. Ир кайтып кергән, ашарга утырганнар. Бик ерактан сүз башлый икән теге: дөньяда булып яткан хәлләр, миллиардерлар өлешенә төшкән көмешләр, зур байлыкның теләсә кем кулына уйламаганда килеп кергән очраклар һәм башка, һәм башкалар... Ахры да абыйсына әлеге отыш турында әйтергә базнат иткән. Абый кеше нишләр икән диеләр, аңын югалтып та егылмаган, сикереп биергә дә төшмәгән. «Алай булгач, сеңлем, отышның тәгәл яртысы сиңа инде» – дигән. Кызның күзләре маңгаена менгән, авызы ачылып киткән, аңын югалтып егылган. Мескенне инфаркт суккан. Чак коткарып калганнар...

– Көләр микән дип, карт карчыгына карады. Анысы чак кына елмайгандай итте дә:



– Чемодан тутырып алып кайткан акчаң турында миңа әйтсәң, егылып җан тәслим кылырымнан курктыңмы әллә? – диде.

Аптыравын да, куркуын да күрсәтми, авызын ерып утыра мәлгунь карчыгы. Сәфәргали картның үз авызы ачылып китте, капкан ите тамагына утыра язды. Менә яшер син аңардан!..

– Соң, мин бит инде куркмасын, саулыгы белән тегә-бу булмасын дип өч көн сиңа әйтергә кыймадым, әнисе. Өч көн берүзем җан атам. Менә әлеге сөйләшүне мәзәктән башлавым да шуңардан. Гафу ит инде, үзең дә белеп алгансың икән. Сөйлим...

– Сөйлә соң. Ырынбурда банк бастыңмы? Юлда кеше таладыңмы? Әллә премия-фәлән бирделәрме үзеңә?

– Премия? Андый зур премия буламыни әле?

– Ник булмасын. Нобель премиясе миллион доллар чамасы торыш итә, ахрысы. Синең кейсыңда да шул чама акча, подоходный налогын тотып алып калганнан соң...

Сәфәргали карт башыннан үткән мажараларны төкми–чәчми карчыгына сөйләп бирде. Карчыгы озак кына дәшми утырды.

– Икс миллионын бүген туздырып кайттым дисең инде, этисе?

– Туздырдым...

– Калган кырык сигез миллионын нишләтергә җыенасың соң? Сиңа ул акча кирәкме?

– Ни пычагыма миңа алар. Сиңа кирәкме соң?

– Минем дә хәрам акчага иманымны сатар чарам юк.Болай да бүген, капларын санап утырып, кулымны пычраттым. Җитмәсә исе сасы...

– Нишлибез соң?

– Син ир кеше, этисе. Син уйла...

– Юлда кайтканда берәз чамалый биреп караган идем инде. Авыл халкына таратып бирергәдер, дим. Колхоз таркалгач, халык бөтенләй кыен хәлдә торып калды бит.

– Ярар, тараттык ди. Син моны ничек күз алдына китерәсең? Йорт башына буламы ул, кеше башынамы? Барысына да тигез бүлергәме, әллә матди хәленә карап өлеш чыгарыргамы? Аннары һәр кеше башында, Сәфәргали картка кайдан килгән бу акчалар, дигән сорау да туачак бит әле...

Ходай хатын-кыз затына матурлык белән акылны тигез бүлми, диләр. Имеш, чибәр бичәнең акыл ягы сәерәк була. Акыллы бичә төсе-кыяфәте белән алдыра алмый. Бу дөрес түгел. Сәфәргали карт гомере буе эченнән генә авылның иң чибәр кызына өйләнүе белән горурланып яшәде. Тормышларында килеп туган четрекле

мәсьәләләрне дә бергәләп хәл итә киделәр. Бер вакытта да тупсыз хәбәр сөйләмәде, кешегә юньсез киңәш бирмәде. Уныччыны гына тәмамлап киңүгә чыгуына карамастан, белемсез, һөнәрсез калмады ул. Читтән торып укып китапханә техникумын тәмамлады, гомере буе авыл китапханәсендә эшләде, җәмәгать эшләреннән дә читләшмәде: колхоз партия оешмасы агитаторы, авыл советы депутаты, хатын-кызлар советы рәисе... Сәфәргали картның мәктәп белеме белән генә чикләнеп калмавы да Зөләйханың эшчәнлегенә бәйле. Гомер буе өйләрендә китап, газит булды.

– Кызык, әнисе... дип куйды Сәфәргали карт, бераз уйлана биреп утыргач.

Зөләйха карчык өстәлдән савыт-саба җыештыру белән мәшгуль иде.

– Нәрсәсе кызык? Бәлки, кызганычтыр...

– Әйе, синеке дөрес, кызганыч та... Кайсы бер адәмнәр гомерләре буе алдапмы, урлапмы, талапмы байлык җыя. Гыйлван кебекләрне әйтүем инде...

Зөләйха карчык көтмәгәндә кычкырып көлеп җибәрде.

– Ташла әле шул Гыйлванныңны, әтисе. Байлыгын әйтим инде: алты почмаклы йорты да, өч сыеры, биш башмагы...

– Банкадагы акчасы да байтактыр әле аның.

– Банктагы?

– Юк ла, өч литрлы банкада, диюем. Банкта тотмый ул, акчасының янарыннан курка.

– Ярар, Гыйлван булмаса, Остап Бендер ди. Хыялына ирешә генә дигәндә, байлыгы юкка чыга...

Зөләйха карчык, өстәл җыештырып бетеп, карты каршысына килеп утырды.

– Моның белән ни әйтергә телисең? Без гомеребез буе зур байлыкка омтылмадык, зур байлык безне үзе килеп тапты, хәзер шуны нишләтергә белми аптырап утырабыз, дипме?..

– Өстенә бастың, әнисе. Мәчет карамагына тапшырып кына куйсак инде? Йә булмаса әллә кайлардан балкып күренеп утырган мәчет төзетсәк. Каранай авылында туып үскән бер адәм газга хуҗа зур түрә булып киткән дә, мәчет төзеткән бит, «Мең дә бер кичә» әкиятләрендә тасвирланган хан сарайларына биргесез...

– Син нәрсә, әтисе? Хәрам акчаны мәчеткә?.. Быелтыр мәчетебезгә газ үткәрергә халыктан акча җыйган идек бит.

– Әйе, йорт башыннан меңәр сум.



Хафиз муллага кемдер: «Гыйлваннан күбрәк алырга кирәк, аның байлыгы мулырак», – дигән икән. Хафиз хәзрәт: «Ул әлеге меңен дә бирмәячәк. Бирсә дә алмыйбыз. Риба белән шөгыльләнеп таба ул байлыгын, ә риба адәм баласы тарафыннан эшләнелә торган иң зур гөнаһларның берсе. Хәрамны кертәсем юк изге йортка». – дигән.

– Әйе, процентка акча биреп тору – мохтаҗ адәмнәрне талау була шул.

– Ярар, әтисе, ятыйк инде, соң бит. Иртә кичтән хәерлерәк, диләр бит халыкта

...Сәфәргали картның башында төне буе саннар кайнашты. Акча–ны авылдашларына бүлеп бирсә, гөнаһы зур булмас, ахрысы. Авылда ике йөз йорт, кырык сигез миллионны йорт башына бүлсә... бүлсә, ике йөз кырыгар мең чыга түгелме? Дөньяларының бер ертыгын ямарга ярап ята. Авылның бу як очыннан төшсә, Сабир белән Хатимә йорты. Әле кырыкка да җитмәсәләр дә, биш балалары бар. Ире клхоздан калган иске «Беларусь» тракторын ямаштырып, кораштырып йөреп ята. Кемгә бәрәңге җире сөрә, кемгә печән чаба, кемгә утын китерә. Авылдашларына да ярдәм, үзенә дә файда. Хатыны мәктәптә җыештыручы булып эшли. Балаларын ач-ялангач тотмыйлар. Дөньяларын да бик бөтәйтеп җибәрә алмыйлар... Үткән атнада гына Сәфәргали карт, алдапрак белешеп куйыйм дип, печәнен чаптырып алу турында сүз кузгалткан иде.

– Иң тәүдә сиңа чапмый, кемгә чабыйм ди инде, Сәфәргали абзый, мине эшкә өйрәткән кеше син бит! – диде Сабир киң елмаеп. – Их, пресс–подборщик алырга хыялланам да соң, җиткереп булмый. Аны алып җибәрсәм, печәнеңне чабып кына ташламас идем, җыеп, тыгызлап бәйләп, йортыңа ук китереп аударыр идем...

– Ярар, энем, чабып бирүең дә зур ярдәм булачак, – диде ул чакта карт. Менә хәзер көтмәгәндә кулына әлеге ике йөз кырык мең килеп керсә, хыялын тормышка ашырмас иде микән Сабир?

Бире килик, дип уйлады Сәфәргали карт. Сәрхүш Вали йорты. Үзе дә эчкече, ирен чыгарыннан чыгармас өчен аңа кушылып эчкән хатыны Вәсимә дә эчкече. Ярый әле Ходай аларга бала бирмәгән. Бирсә, балалары ачлык-ялангачлыкта көн күрерләр иде. Яшьрәк, әле алай ныклап эчмәгән чакларында. Дөньяларын ярыйсы ук бөтәйткәннәр иде, сатып эчеп бетеп баралар. Телевизорларын саттылар, суыткычларын саттылар, хәтта өй түбәсен алыштырырга алган калайларын да сатып эчтеләр...

Йә, шуларга бирде ли Сәфәргали карт ике йөз кырык меңне, билләһи, хәмергә тончыгып үләчәкләр…

Вәлиләр янәшәсендә Габдрәхим карт белән карчыгы Сәлимә яши. Габдрәхим карт, унҗиде яшендә генә фронтка алынып, Ерак Көнчыгышка эләккән, японнарның Квантун армиясен тар-мар итүдә катнашкан. Хәтта «За победу над Японией» дигән медале дә бар. Сугыш тәмамлангач, туган авылына җиде ел хезмәт итеп кайткан. Сугышта, бәлки, әллә ни батырлыклар да кыла алмагандыр, әмма соңгы призывлар җилкәсенә (Сугыш бетте дип, армияне таратып җибәрә алмаганнар бит) әнә шул җиде-сигез ел хезмәт эләккән. Ә хәзер кайсы бер юньсезрәк егетләр бер ел хезмәт итүдән дә качып йөриләр. Сәфәргали карт үзенең Коми якларында тулы өч ел хезмәт итеп кайткан чакларын исенә төшерде. Рядовой булып кайтмады бит ул, ефрейтор да түгел, өлкән сержант булып кайтты. Взвод командиры ярдәмчесе булып хезмәтен тәмамлады. Юкка гынамы ни авылның иң чибәр, иң акыллы кызы Гыйлванны түгел, Сәфәргалине сайлады. Габдрәхим гомере буе колхозның трактор бригадасы хисапчысы булып эшләде. Чыгымчырак булса да, гадел эш итте ул, булганын киметмәде, артыгын язмады. Былтыр, халыкны клубка җыеп, авылда сугыш ветераннарыннан берүзе генә торып калган Габдрәхим Иштугановның туксан еллык юбилеен билгеләделәр. Аны котларга хәтта Сәфәргали картка да сүз биргән иделәр. Ул матур гына сүзләр тапты, булса кирәк. Котлавы азагында хәтта шаяртып та алды: «Габдрәхим абзый, безнең теләкләр, Аллаһы боерыгы белән син әле озак яшәргә тиеш. Йөзенне дә бәйрәм итәрбез, йөз дә унынчыны да, йөз дә егерменне дә… тик җәл анда инде без булмабыздыр»…

Әбисе белән пенсияне яхшы алалар икән. Сәфәргали картның кеше кесәсендәге акчаны санап торган холкы юк. Берчак аның колагына бу хәбәрне Гыйлван тишеп китте: «Беләсеңме, Габдрәхим белән карчыгы аена күпме пенсия ала. Егылып китә күрмә, алтмыш мең!» «Нишләп егылып китим инде мин. Лаек булганнар икән, әйдә алсыннар…» Пенсия күп алалар дип, аларны да урап үтеп булмый бит. Алтмыш янәшәсенә ике йөз кырык та өстәлсә, эчләрен тишмәс. Хәер аларга инде ни генә кирәк? Пенсия алган көннәренә туры китереп Ырынбурдан кайтып йөргән уллары, оныклары шатланыр. Вәли алкашка өлеш чыгару дөрес түгел. Әмма юньләп әти-әнисен тәрбияләмәгән, авылга өч тиенлек тә файдалары тимәгән адәмнәргә өлеш чыгару дөрес булырмы?



Габдрәхимнәрдән бирерәк Сәфәргали картның күршесе, Аллаһ бәндәсе Фәйрүз. Илдә чыпчык үлми, диләр. Фәйрүз дә ач-ялангач йөргәне юк. Хәер, андыйларны хөкүмәт тә рәнҗетми, ай саен пенсиясен биреп бара. Берәү булса, аз бирәләр дип, зарланыр иде, Фәйрүз, аена җиде мең түлиләр дип, мактангалап та куя. Өйләндерәсе иде егетне. Гаиләле булса, ничек тә үз көнен үзе күрер иде әле. Тик аңа нинди кыз килсен? Ничек булса да, аны өлешсез калдырырга ярамый. Кулына тоттырсаң, Вәли кебекләр алдап алып бетерәчәк. Аныкын Сбербанкка урнаштыру дөрес булыр.

Менә шулай, уйланып ятып, Сәфәргали карт ярты авылны үтеп чыкты. Пенсияләре бәләкәй карт-коры, Себердә эшләп йөргән яшь-җилкенчәк, авылда айлык эш хакы алып эшләгәннәр… Барысы белән берләттән Корманаевка да ике йөз кырык меңме? Байтакларның яшәү чыганагы кыенлык белән асраган мал–туарына кайтып кала, Корманаев яхшы эш хакы ала…

Әле бит акча өләшкәндә күпме көнчеллек, күпме үпкә, күпме талаш булачак! Ә шул акча чыганагы турында гайбәтләр!.. Сәфәргали карт тәмам бутылды. Тигезләп бүлеп бирү, шул адымы белән авылдашларын шатландыру уе, иртәнге томандай сыегаеп, юкка чыкты. Төшләре-саташулары да бик буталчык булды…

Зөләйха карчык берни белми йоклаган дисезме? Өегезгә текәтеп салынган алачыкка илле миллион акча алып кайтып куегыз да, халал җефетегезне тыныч кына йоклатып яткырыгыз! Юк, ул акчалар аңа, чынлап та, кирәкми. Балалары, оныклары да имин яши. Әлеге шул авылдашларын шатландыру, авылдашларына ничек тә ярдәм итү уе йоклатмады аны.

Акыллы хатын – акыллы хатын шул. Йорт башына түгел, кеше башына бүлеп бирү фикерен куатладе аның аңы. Авылда алты йөз кеше яши, кырык сигез миллионны шуларга бүлсәң, җан башына сиксәншәр мең туры килә. Авыл очы Вәлинең гаиләсе җиде кешедән тора, димәк, аңа – биш йөз дә алтмыш мең. Пресс-подборщик кына ала әле ул бу акчасына. Пенсиядәге китапханәченең заман техникасы турында хәбәрдарлыгы аптыратмасын укучыбызны. Аның тормыш иптәше кырык ел стажы булган механизатор ич!

Вәли белән Вәсимәгә – йөз алтмыш мең. Алар нинди уңышлары белән лаек бу бүләккә? Эчеп бетерәчәкләр…

Габдрәхим карт белән аның Сәлимәсенә – йөз алтмыш мең. Ничек була инде бу? Алкаш Вәлигә дә, сугыш ветераны Габдрәхим карт-

ка да йөз алтмышар мең?.. Фәйрүз бирүзе, анда – сиксән. Бирсәң куаныр, бирмәсәң – үпкәләмәс.Гыйльванга да йөз алтмыш мең өлеш чыгарырга туры килер микәнни? Чыгармасаң, низагъ куптарыр, шикаять язар, Тукмаклыга чабар, Тукмаклы белән генә чикләнмәс, Уфа юлларын таптар... Авылга әллә нинди тикшерүләр китертер. Әле өлеш чыгарсаң да: «Нигә Вәлигә биш йөз алтмыш мең, миңа йөз алтмыш кына мең?» – дип бәйләнер. Үз көчең белән тапкан хәләл акча житәр-житмәс яшәгәндә генә рәхәт икән ул. Юктан бар булган хәрам байлык, картларны котыртып, яшьләрне аздырып, әлегә чаклы син дә мин яшәп яткан авыл халкын әллә нинди балаларга тарытыр сымак тоелды Зөләйха карчыкка.

Таңгы эшләрен башкаргач, икесе икә бүлмәдә йокысыз төн үткәргән карт белән карчык, тамакларына азык барырлык булмаса да, чәй табынына утырдылар. Ясап куелган чәйгә тотыныр алдыннан бер-берсенә караштылар. Зөләйхага картының йөзе сурылып киткәндәй тоелды. Сәфәргали картка әбисенең йөзендәге җыерчыклар ишәйгән сыман күренде. Бераз эндәшми утыргannан соң, хуҗабикә:

– Шулай... – дип авыр тын алды.

Хуҗа аз булса да җанланып киткәндәй булды:

– Син шулай уйлыйсыңмы, әнисе, мин дә шулайрак уйлыйм, – диде.

Хуҗабикәнең дә караңгы йөзе ачыла төште.

– Ничегрәк уйлыйсың соң?

– Синең кебек уйлыйм инде... Юк итәргә кирәк! Баласыннан баш аяк!

Азга гына тынлык урнашкандай булды. Аннары икесе бергә кычкырып көлеп җибәрделәр. Менә бит бергә, чәкердәшеп, яртыгасырдан артык яшәү гыйльләсе! Катлаулылардан катлаулы мәсьәләне сүзсез-нисез дигәндәй чиштеләр дә куйдылар... Бары ничек юк итү турында гына уртак фикергә киләселәре калды.

– Мунча мичендә яндырам, – диде карты, йөзенә тәвәккәллек хисе чыгарып.

Карчыгы уйланып торасы итте.

– Ул бит синдә эрдәнәләп өелгән, җәй буе киптерелгән каен утын түгел. Кара төтене, сасы исе бар авылга таралыр. Ул мунчабыздa арытабан үзебез ничек чабынырбыз, тазарынырбыз? Әллә җиргә генә күмәсеңме, әтисе? Бүлә буена чыгарып, тирән кабер казып...



– Ягы ташкын актарып китереп чыгарсын да, бездән соң килер әллә кемнәрне акылданмы, юлданмы яздырсын, дипме? Суга батырсак дөресрәк булмасмы?..

«Кояш Җир тирәсендә әйләнми, Җир Кояш тирәсендә әйләнә!» – дип ныкышкан Галилео Галилейны ничек җәзага тарттыру турында киңәшне инквизиторлар озак кордылар микән – анысын тарих кына белә. Сәфәргали белән Зөләйха хәрам акчалардан котылу юлын тиз хәл иттеләр. Айчумган ятуына батырырга! Анда яшәгән тәртә буе шамбыларны моңа чаклы тоту гына түгел, берәү дә күрмәгән икән, акчалы кейсны да берәү дә күрмәс тә, белмәс тә. Бу, билгеле, көпә-көндез башкара торган эш түгел, караңгы төшкәнне, халык көндезге эшләреннән йончып йоклаганны көтәргә кирәк.

...Җәйнең көннәре озын. Шуның өчен, аның бер көне кышны туйдыра, ди халык. Эшле кеше эшен көннәрнең озынлыгына, аязлыгына шатланып башкара. Төннәрен кырын юлда йөрер бәндәләр кич булдыра, караңгы төшерә алмый зарыга. Кулына эш бармагач, Сәфәргали карт та бу көнне изаланып үткәрде. Нићаять, эңер төште, Мәзин тавы артыннан тулы ай калкты, әйләп авылның гадәти кичке авазлары тынды. Сәфәргали карт капчыкка кейс, Николай патша заманыннан калган бер потлы гер, алты миллиметрлы тимер чыбык кисәге урап салып, авыл артындагы сукмактан Айчумган ятуы ягына табан атлады. Җилкәсендәге капчыгы авыр, карт күңелендәге уйлар авыр... Тымызык төннең һиллеге генә әлеге хәлен бераз җиңеләйтә төшә.

Айчумганны халык гадәт буенча гына «яту» дип йөртә. Чынында күл ул, зур һәм тирән күл. «Яту» дип атауның үз сәбәбе бар: Бүлә елгасы аның төньяк читенә коя, көняк читеннән агып чыга да Каспий диңгезенә табан юлын дәвам итә. Килеп житкәч, Сәфәргали карт капчыгын җиргә куеп хәл алды, хозур күренешкә соклана бирер басып торды. Күл читен биек камышлар камалый, эчтәрәк төнбоеклар, керфекләрен йомып, йокыга талган, суда тулы ай битен юа. Ямьле күренешнең тәгаллеге өчен алтын тарагы белән озын чәчен тарап утырган Су анасы гына житмидер кебек.

Карт тимер чыбык белән кейс тоткасына гер ныгытты, ерракка ташларга кирәкми иде, хөкемгә тарттырылган акчалы тартманы күлнең текә яр астындагы иң тирән төшенә чумдырды.

Авылга йөгерә-атлый кайтты ул. Су анасы артыннан төшәр дә «Качма! качма! Тукта! тукта!, и карак!» – дип йортына чаклы куар төсле тоелды.

Тормыш иптәшен шул чаклы хәвефле бурыч башкарырга җибәргән юньле хатын тыныч кына йоклап ята алмы? Зөләйха апа йокламаган иде әле.

– Йә, ничек, әтисе? – дип сынаулы карашын иренә төбәде ул.

– «Чуп» итеп калды, – диде йорт хуҗасы, йөзенә битарафлык хисе чыгарып. – Яхшылык эшлә дә суга сал, халык күрмәсә, балык күрер, диләр бит...

– Нинди яхшылык ди инде анысы?..

## 12

Таң белән Сәфәргали картның кесә телефоны шалтырады.

– Тәмле төшләр күреп йоклыйсыңмы, әллә уяндыңмы?.. – Трубкада аның балалык дусты Әнвәр тавышы иде. Калын, азрак карлыккандай тоелган тавыш, һич кемнеке белән бутый алмассың. Әнвәрнең гел әңгәмәне менә шулай, сәлам биреп тормый, башлый торган гадәте бар.

– Без, авыл кешеләре, иртән торып ярты эшебезне тәмамладык инде. Сез генә анда, шәһәрдә, төшкә чаклы йокы симертәсездер.

– Йокы симертсәм, рульдә булмас идем әле. Төне буе дип әйтерлек борсаланып яттым-яттым да иртән борсалануымның сәбәбен ачыкладым. Баксаң, кичекмәстән Өчкуяныма кайтарга кирәк икән дә, сезнең белән күрешергә, яшьлек сукмакларыма аяк басарга...

Сәфәргали абзый шатлыгыннан чак биергә төшми калды.

– Чынлапмы, Әнвәр дус?

– Минем кайчан буш хәбәр сөйләгәнем бар? Санап карасам, кайтмаганыма да биш ел үтеп киткән... Ярар, «дөл-дөл»ем яшь айгырдай уйнаклап тора, дүрт сәгатьтән кайтып җитәрмен.

Сәфәргали абзый күңелле хәбәрне Зөләйхасына җиткерде.

– Әнисе, син камыр ашларыңны карый тор. Мин, чаганлый дип, ак сарыкны көтүгә җибәрмәгән идем, шуны чалам. Кадерле кунакны суыткычта туңдырылып ярты ел яткан ит белән сыйлап булмый бит. Куллама пешерерсең, шашлык кыздырырбыз. Аның бит әле өстәлгә әчесе дә кирәк... – дип сөйләнде ул.

– Аш-суын карармын әтисе, йөзенә кызыллык китермәм, шашлыгы белән әчесе инде – синең хәстәр, – диде Зөләйхасы.

Бергә, бер кашыктан ашап дигәндәй, үстеләр алар Әнвәр белән. Сугышта әтиләре ятып калган ил балалары нинди нужалар татыса, алар да шуны татыдылар. Алабута икмәге, бәрәңге калҗемәсе ашап, балтырган шулпасы чөмергән чакларын һич кайчан оныта-



сылары юктыр. Ун сыйныфны бергә тәмамладылар. Сәфәргали авылда төпләнде, Әнвәр, Свердловск шәһәрендә юридик институт тәмамлагач – Уфада. Судта да эшләде, прокуратурада да. Укыганда ук өйләнешкән марҗасы белән тату яшәп өч бала үстерделәр. Марҗасы күптән вафат, балалары да төрле якларга таралыштты. Берүзе көн күрә. Авылда туганнары калмагач, нигезе беткәч, бик еш кайтып та йөри алмый.

Йортлары тәңгәленә соры төстәге «Вольво» килеп туктаганда, Сәфәргали абзый, капкасын ачып куеп көтә иде инде. Кунак машинасыннан төште, кочаклаштылар. Сәфәргали озын, чандыр гәүдәле, Әнвәр – тәбәнәк, юан, туп кебек. Сәфәргалинең бәдрә чәче һаман да кепкасына сыеп бетә алмый, Әнвәрнең яшьтән үк пеләшләнгән башы кояшта көзгедәй ялтырый. Сәфәргалинең тырпаебрак торган мыегы бар, Әнвәр түгәрәк итеп сакал үстереп җибәргән. Холыклары да төрле аларның. Сәфәргали җаерак кузгалып, ырамлырак эшли торганнар нәселеннән. Әнвәрне дә ырамсызлыкта гаепләрлек түгел, әмма ул бик тиз кабынып китә торган ир. Тик эш төс-баш, холык охшашлыгындагына мы ни. Уй, фикер, күңел дулкыннары бер ясылыкта тирбәлә аларның. Менә шушы нәрсә гомерләре буена тугры дуслар итеп калдыра да инде.

– Их, Зөләйха! – диде кунак чәй өстәле артына утыргач. – Бигрәк чибәр, бигрәк уңгансың инде. Сәфәргали чосрак булып, сине алдан эләктермәсә, үзем аладыр идем бит сине!..

Әнвәрнең болай әллә чынлап, әллә шаяртып әйткән сүзләренә күнеккән инде алар.

– Син авылдан чыгып киткәндә, мин үсмер кыз гына идем. Ничек алыр идең икән?

– Анысын ничек тә чамалар идем әле...

– Йә, очрашу хөрмәтенәме, синең ирешә алмаган максатың кайгысыннанмы берәрне тотабызмы? – диде Сәфәргали, табын уртасында балкып утырган шешәгә ишарә итеп.

Әнвәре бу сыйдан баш тартты.

– Беләсеңме, Сәфәргали дус, хезмәт юлымда ул шайтан төкергән бушка чөмерергә күпме мөмкинлекләр булды: командировкалары, банкетлары, фуршетлары, шашлык-машлыклары... Барысында да авызымны шапылдатып утырсам, күптән алкашка әйләнер идем, йә булмаса бөтенләй юкка чыгар идем. Яшь чакта ук үземә сүз бирдем. Сәгать кичке алтыга чаклы авызыма да алмаска, кичен дә ике рюмкадан арттырмаска...

– Ярар, кичен, шашлык белән сыйланганда, карарбыз соң.

Төштән соң хуҗа белән кунак йөрергә чыктылар. Тәү авылның теге башына үттеләр, аяк киемнәрен салып, балакларын сызганып Бүлә аша чыктылар, калкулыкка күтәрелеп, зыйрат капкасын ачып керделәр. Мал тапамагач, зыйратны чиләк басып бара. Әниләренең каберләре, берсе астарак, берсе өстәрәк, чиләк арасында торып калган иде инде. Ярый әле Сәфәргали, яз саен килеп, үз әнисенекен дә, Әнвәрнекен дә чүп-чардан тазарта, кирәкмәгән үсентеләрдән арындыра. Быелтыр буявы уңган рәшәткәләрне ачык яшелгә буяп та куйган иде.

– Рәхмәт, дус, – диде Әнвәр, – анасы кабере янында озак кына сүзсез торгач. – Монда сукмакны суытмаганың өчен рәхмәт...

Кайтырга чыккач, мәктәпкә сугылдылар. Типовой проект белән төзелгән ике катлы мәктәп алар укып бетеп байтак еллар узгач кына төзелде әле. Алар укыганы биш алты иске агач биналарда урнашкан иде. Кыш булса суык, яз җитсә түбәләреннән класс идәненә «тып-тып» тамчы тама. Шулай да нинди күңелле булган ул чаклар! Көн кичкә авышып баруга карамастан, директор урынында булып чыкты.

– Әссәламмәгаләйкем, Габит туган!

Яшь булса да, итәгатьлек калыпларын белә ул. «Исәнмесез» дип заманча сәлам бирмиде.

– Вәгаләйкем-әс-сәлам, абзыйлар! – дип урыныннан ишек янына килеп күреште. – Сәфәргали абзый белән еш очрашып торабыз, сезне, Әнвәр Гарифович, күптән күргән юк. Нинди җилләр ташлады?

– Нинди җилләр дип, Габит энем, туган авылны сагыну җилләре инде. Кайтмаганыма биш ел булып китте...

– Ешрак кайтырга да кирәктер, Әнвәр абзый. Менә өч елдан мәктәбебезнең сиксән еллык юбилеен үткәрергә җыенабыз, тантанабызның түрендә булырсыз дип өмет итәбез. РСФСР-ның атказанган юристе бит сез, мәктәбебезнең горурлыгы...

«Мәктәп горурлыгы», хәйләкәр елмаеп, Сәфәргалигә карап ташлады. Директор бу ишарәне яхшы аңлады.

– Сәфәргали абзый турында әйтеп торасы да юк, аның урыны болай да һәрчак түребездә.

– Уку елы тәмамланган, ни шләп әле директор болай соңлап эш бүлмәсе саклап утыра? – диде Сәфәргали, сүзне икенчегә борып.

– Таң белән Сиргалин чакыртты! – дип шат елмайды директор.



– Түрә чакырткангa шатланалар димени, энем, дип, – хәйләкәр елмайды Сәфәргали дә, – Пешерергә, утлы табада бастырырга чакыртадыр?..

– Юк, алай булмастыр. Күрше авыллардан килә торганнарын да исәпкә кертеп, өлкән сыйныф укучыларының исемлеген төзе дә, килеп җит, диде. Тел төбенә карaганда, теге юньсез карарыннан баш тартырга җыена, булса кирәк.

– Бу, Сәфәргали абзый, синең тырышлыгың, булса кирәк?

– Куй әле, энем, мине, пенсиядәге механизаторны, хәзерге заманда кем санга суксын? – дигән булды карт.

Авыл хакимиятенә дә сугылдылар.

Кәгазьләргә күмелеп утырган Корманаев аларга ачык йөз күрсәтергә тырышты. Әмма, кул сәгатенә күз ташлап, вакыты тыгыз икәнлеген белдерүдән дә тартынмады.

– Их, абзыйлар! – диде ул, көчләп елмаеп. – Рәхәтләнеп утырып әңгәмәләшергә... Ә, бәлки, Бүлә буена чыгып кәеф-сафа корып та утырырга иде дә соң, эш бит! Таң белән Чураев чакырткан. Булачак күпернең проект-смета документациясен алсын да, килеп җитсен, дигән. Әле менә шуны барлап утыруым. Бер капчык кәгазь!..

## 13

Почтә ишек алды почмагындагы шомырт агачы янәшәсендә сыйлы өстәл, шул өстәл белән өй арасында йөгереп йөргән йорт хуҗабикәсе, читтәрәк каен күмеренең сыек яктысын һәм кызган сарык итенең тәмле исен тирә-якка тараткан мангал, күктә яңа туна калыккан тулы ай, эскәмиядә мунча кереп чыккан ике дус – дөнья төгәллеге өчен тагы ни кирәк!?. Серләштеләр, сөйләштеләр, көлештеләр, хәтта җырлап та алдылар.

*Ай югары, ай югары,*
*Айга менәсем килә.*
*Айга менеп, түбән карап,*
*Сине күрәсем килә...*

Авылның кичке авазларына колак салып, бераз утыргач, Сәфәргали карт бозды тынлыкны.

– Безнең хәлләрне сораштың да, безнең хәлләрне сораштың, Әнвәр дус. Ике самовар чәй эчкәч, исәнме, кодагый, кебегрәк була инде, үзең ничек яшисең соң? Пенсия акчасы гына ашап ятасыңмы, әллә берәр җирдә эшлисеңдәме? Берүзеңә кыендыр бит, әби тапмадыңмы?

Кунак көлеп җибәрде.

– Сиксәнне куганда өйләнгәннәр дә бардыр дөньяда. Мин, Сәфәргали дус, андыйлар токымыннан түгел. Беренче хатын – Ходадан, икенчесе – шайтаннан, дигән әйтем бар, мин шуңа ышанып яшим. Бергәләп шатлыкта яшә-яшә дә, әкияттәге кебек, икәвең бер көндә үл дә кит икән. Тормышта алай түгел шул ул. Менә син миңа караганда бәхетлерәк...

– Без дә Зөләйха белән бер көндә китмәбез бу дөньядан. Мин алдарак китсәм, дөресрәк булыр, дип телим Аллаһыдан.

– Кыен чаклар булгалый, шуның өчен үземне эш белән юатам.

– Нинди эш?

– Мактанып та алыйм әле. Мин бит отставкадагы өлкән юстиция советнигы гына түгел, юридик фәннәр кандидаты да. Студентларга белем бирәм.

– Син укыдың шул, ә мин... – дип авыр сулады Сәфәргали карт.

– Борыныңны югары тот, дус. Нәрсә генә димик, икмәк үстерүдән дә изге эш бар микән дөньяда. «Русиянең атказанган механизаторы» исемен теләсә кемгә бирмиләр.

– Ярар, Крылов бабай мәсәлендәге Әтәч белән Күке кебек, берберебезне макташып утырмыйк әле, тагы берәрне күтәреп, шашлык ашап алыйк та, мин сиңа бер мәзәк сөйлим.

Әнвәр картның кызыксынучан холкы озак көтәргә ирек бирмәде.

– Йә, сөйлә инде, диде ул, ике-өч кисәк итне кабалан-кабалан чәйнәп йоткач.

– Хикәятемне сораудан башлыйсым килә. Нишләп илебездә, шул хәтле байлыклар була торып, акча җитми ул? Юллар, күперләр төзергә, балаларга бушлай белем бирергә акчалар юк, авылларда юньле хастаханәләр тотарга акча юк, картларга пенсия арттырырга акча юк. Ә Мәскәүдә капчыклап урлаудан КАМАЗга төяп урлауга күчтеләр...

– Теге өч бүлмәле фатирын акча белән шыплап тутырган полковникны әйтәсеңмени? – дип көлеп җибәрде кунак.

– Көлмә. Көлерлек нәрсә түгел бу, утырып еларлык...

– Утырып елап кына төзәтеп булса икән хәлне. Ә син беләсеңме, Сәфәргали дус, ил бюджеты ничегрәк сарыф ителә. Бар средстволарның сиксән проценты Мәскәүдә һәм аның тирәсендә әйләнә, егермесе – илнең калган өлешендә.



– Димәк, безгә акчаның исе генә килеп җитә?..

– Исе генә? Акча исе! Һай өстенә бастың да соң, Сәфәргали! Карале, син миңа мәзәгеңне сөйләмәдең бит әле.

Сәфәргали карт соңгы өч-дүрт көн эчендә башыннан үткәннәрне сөйләп бирде. Кунак авызын ачып тыңлады.

– Суга салдың? Ничек салдың? – дип аңгыра сорау ычкындыруын сизми дә калды Әнвәр карт, хикәят тәмам булгач.

Бу сорауга Сәфәргалие ни әйтсен?

«Чуп» итеп калды..., – диде

– «Чуп» итеп калды? Ха-ха-ха!

Кунагының сыны катып көлүенә Сәфәргали карт та кушылды. Бу кызыкка хәтта өендә табак-савыт юу белән мәшгуль Зөләйха карчык йөгереп килеп чыкты.

– Нигә бар авылны йокыдан уятырлык итеп хихылдыйсыз ул?

– Кызык бит, – диде кунак.

– Нәрсә кызык?

– «Чуп» итеп калган!..

– Дөрес эшләгәнмеңме? – диде Сәфәргали карт, кыенлык белән тынычлангач.

– Дөрес тә, дөрес түгел дә. Үзеңә калдырмавың, авылдашларга таратып бирмәвең, минем карашка да дөрес, юк итүең дөрес түгел. Телевизор карыйсың бит инде? Реклама өлешендә тоталар да ил халкының күзләренә тилмереп карап яткан балаларны күрсәтәләр. Тегесенә чит илдә операция ясату өчен өч миллион акча кирәк, монысына – биш миллион, тагы берсенә – ун миллион! Байлар бик биреп бармый. Хәерче халыктан тиенләп җыябыз. Бу бит ил өчен хурлык!

– Акча сиңа эләксә, ни эшләр идең соң?

– Авыру балаларга ярдәм итәр өчен хәйрия фонды ачар идем. Синең хәрам дип суга батырган акчаң шуның башлангычы булыр иде, аннан спонсорлар таба–таба тулыландыра барыр идем.

– Бик мәслихәт! – диде Сәфәргали карт, ни әйтергә белмәгәннән.

– Мәслихәт! Менә бит исемен дә таптың. «Мәрхәмәт» атлы хәйрия фонды бар, «Мәслихәт» атлысы нишләп булмаска тиеш? Исеме табылды да ул, Сәфәргали дус, акчасы гына юк.

– Нишләп булмасын, бар! – дип кычкырып җибәрүен сизми дә алды хуҗа кеше.

– Айчумган ятуындамы?

– Айчумган ятуы – ул безнең сбербанк икән дип исәплә. Сакларга салдык, кирәге чыккач – тартып чыгардык. Әнә, абзар башында озын багор ята, киттек...

Картларның көлешүеннән Фәйрүз йокысыннан уянып капка төбенә чыгып утырган иде. Күрше абзыйсы белән аның кунагы, аякларына резина итекләр киеп, багор алып, Айчумган ятуы ягына чыгып китүен күреп, егет, минс алмый гына тәртә озынлык шамбы каптырырга киттеләр инде болар дип, уфтанып калды.

...Кунак икенче көн таң белән үк юлга чыгарга җыенды.

– Ай күрде, кояш алды гына булды бит инде бу кайтуың, Әнвәр абый. Ичмасам, өч-дүрт көн генә булса да ял итәр идең. Сәфәргали белән икәүләп, Фәйрүзне дә ияртеп, балыкка барыр идегез...

– Бардык инде, балыкның иң зурын каптырдык... – картлар тагы икәүләшеп көлеп җибәрделәр. – Иртәгә студентларымнан имтихан аласым бар шул. Югыйсә...

Кунак руль артына утырды. Ишеген япмаган иде әле, дустына эндәште:

– Мина ышанасыңдыр бит, Сәфәргали?

– Юк сүз сөйлисең, Әнвәр.

– Шулай да һәр эштә тәртип булырга тиеш. «Мәслихәт» фонды идарәсенә әгъза итеп сине дә кертәм. Күпме кергән, күпме чыккан, ничә тиен кайда һәм ничек тотынылган – квартал саен отчет җибәреп торачакмын... Үзегез мина кунакка килегез!..

Машина кузгалды. Карт белән карчык капка төбендә, берсенә сыена бирсп, торып калдылар...



# Бидрәш илчесе

*Сатирик роман*

*Дөнья исәрләр идарә иткән исәрләр йортын көннән-көн ныграк хәтерләтә бара.*

***А. Алойд Джорджс.***

## Гарәсәт

*Заман ахыры булдырмый торып, без аңа ышанмаячакбыз.*

***Б. Ю. Крутиер***

Күз күреме иңләмәслек дала офыкка хәтле сузылып алсулана башлаган күккә тоташкан бер төштән җәйләп кына Кояш килеп чыкты. Чыгаргамы-чыкмаскамы дип торуының сәбәбе бер нәрсәдер инде: миллион еллар буе шул бер үк күренеш, меңәр еллар буе тамак кайгыртып көн үткәргән шул бер үк кешеләр, аларының шул бер үк холыклары, бер үк гөнаһлары... «Йә, нишлибез? – дип Кояш Җиһан хисапчысы Вакытка өндәште. Ара-тирә, эче пошканда, шулай дусты Вакыт белән гәпләшеп ала торган гадәте бар аның. Вакыт, кайсы бер мыштыр адәмнәр кебек, җилкәсен тырнап, озак уйланып тормады, уйланырга форсаты юк ич аның. Ул Тәңре тарафыннан шушы җаваплы вазыйфасына куелган. Үзган дәверләр, гасырлар, еллар, айларны дөрес итеп санап барырга җаваплы. Шуның өчен кыска гына итеп: «Нишлибез. Алдыбызга куелган бурычларыбызны башкарабыз», – дип җавап бирде. «Соң, Җирдәге бозыклыкларны күреп биздер дә бит инде...» «Ярар, – диде Вакыт, мәгънәле итеп тамак кырып, – «Озак яшисең калмаган. Җирдәге кайсы бер галимнәрнең фаразлавына караганда, алты миллиард кына ел. Аннан сүнәрсең, синең белән бергә Җир шары да, сине биздергән кешелек дөньясы да юкка чыгар. Ә мин – мәңгелек. Минем дә, кайчак Кешелек дөньясының шашып баруын күреп, ачуым килеп китә, бер тетрәтеп аласым килеп куя. Бәлки, шулай итәргә кирәктер дә»...

Шуның белән ике дусның иртәнге әңгәмәсе тәмам булды. Вакыт үзенең исәп-хисап эшен башкаруын дәвам итте, Кояш та күк йөзе буйлап көндәлек сәяхәтенә чыкты.

Әйе, биздерәп тә китәргә мөмкин шул. Тик Кояш бит ул Сакау Бакыйның ялкау бичәсе Сафура түгел, биздерде дип, көннәр буе караватта аунап яталмый, теләсә-теләмәсә дә бурычын башкарырга тиеш.

...Габделбәр карт, урыныннан торып, арык янбашын кашый-кашый, күтәрмәсенә килеп чыкканда, Кояш инде, күтәрелә бирәп, байтактан бирле ябык торган спирт заводы торбасына менеп кунаклаган иде. Тик анда да озак тоткарланмады, торбадан аерылып, юлын дәвам итте. Шунда ук, Җирдә көз башы да, яз азагы да түгел, җәйнең тап уртасы икәнлеген исенә төшереп, күкне, урман кырларны аяусыз кыздырырга да башлады. Габделбәр карт карашын спирт заводының төтен чыкмаган моржасыннан шәһәр үзәгендәге күпкатлы биксәп йортларга күчерде, шәһәрнең бирге читендәге үзе яшәгән Себер урамын барлап алды, бик еракларга сузылган иксез-чиксез далага карап торды, бүгенге эш мәшәкатьләрен исенә төшерде. Күтәрмә эргәсендә килеп, хуҗа ягына муеннарын сузып үз телләрендә кызып-кызып азык таләп иткән казлары иң тәүге бурычы иде аның. Туймас тамакларны бүксәләре ир-ат йодрыгы чаклы булып калкып чыкканчы туендыру, үзенең тамагын ялгап алу, такта гаражыннан «Запарасын» кыздырып чыгару, күршесе Хөршидәгә ачкычны тапшыру, казларына тәгаенләнгән болгауның урынын күрсәтү...

Нияте Тәвеш авылында көн күргән казак дусты Теләкбирдегә барып кайту иде аның. Барып кайту гына түгел, хәтта анда кунып ук калу. Әбие Гашүрә гүр иясе булганнан бирле, бик чыгып йөргәне юк.

Дусты Теләкбирде телефоннан: «Әбәзителне кил, Габделбәр кордаш. Сарык суям, бишбармак белән сыйланырбыз, минем Нурсәиләнең аш-суга осталыгын беләсең! Килмәсәң, үпкәлим», – дип шалтыраткан иде.

Эш бишбармакта гынамыни. Бергә Тоцк якларында солдат хезмәтендә булдылар. Атом бомбасы шартлату гарәсәтен бергә кичерделәр. Күпме еллар үткән, һаман бер-берсен онытканнары юк. Билрәш базарына ит сатарга килгәндә, Теләкбирде Габделбәргә сугылмыйча кайтып китми, Габделбәр карт та мона чаклы Тәвешкә юл суытканы юк иде әле.



Тизлеген илледән арттыра алмаса да, халык «Колаклы» дип исем таккан «Запарай»га утыз чакрым зур арамыни ул... Карт башына тәүге килгән җырны авыз эченнән генә мөңгерәп бара торгач (Яшь гомерне уза диләр, узганын күрсәң иде, узган чакта тотып алып, кирәген бирсәң иде), бик күп мәзәкләрнең героена әйләнгән машинасы аны Тәвешкә китереп тә җиткерде. Теләкбирде дусты Габделбәр служагын капкасын зур ачып, колачын киң җәеп каршы алды.

Укучыбызны ялыктырмас өчен картларның ниләр белән сыйланып, ничек әңгәмә корганнары турында җәйләп-баглап сөйләп тормыйк. Аларын болай да күз алдына китереп була. Тик бер генә нәрсә Габделбәр картның күңелен бераз җилкетеп куйды. Нурсәиләгә аш әзерләшеп йөргән күршеләре Фаягөл. Әле алтмышын күптән түгел тутырган янып торган бичә. Былтыр гына Казахстаннан кайткан да, шушында йорт сатып алган. Фаягөл тегеләй-болай үтеп йөргәндә, йорт хуҗасы телен шартлатып ала да, кунагының кабыргасына төртә, күз кыса. Табында утырганда да шул бичәгә әледән-әле сынаулымы, сокланулымы карашын ташлый да тагы Габделбәрнең кабыргасына төртеп ала. Вәт картайганда тыртайган адәм! Хуҗаның бу кыланышының сере кунакка кич, ятар алдыннан гына мәгълум булды. Менә шулай итеп күрше бичәне дустына димләп маташа икән бу игелекле адәм.

– Син дә ялгыз, ул да ялгыз, кылын тарткалап караганым бар. Риза булырдай. Кордаш, әйдә өйләнешегез дә куегыз. Теләсәң, менә хәзер үк никах укыйм. Безнең яшьтә инде озак киңәшләп йөри торган чак түгел. Ятарсыз да йокларсыз...

– Син? Никах? – дип аптыравын белдерде Габделбәр карт, табында бергаләп төпләгән «ярты»ны исенә төшереп.

– И-и, гаепкә алма инде, кордаш. Урыслар: «Балык булмаганда, кысла да – балык» – диләр бит. Башка кеше булмагач, авылда, ай-васма карамый, муллалык вазыйфасын миңа йөкләттеләр. Дөрес, әле хәмердән бик баш тарта алган юк, аның каравы без синең белән дуңгыз ите ашамыйбыз бит, сарык та каз гына. Ә кайсы бер догаларны кечкенә чагымда миңа әтием Теләкҗан өйрәтеп калдырган иде. Йә, хәзер карар кабул итә алмасаң, төнен уйланырсың да, сине иртән өйләндерербез. Габделбәр карт күңеленә салынган котгы эзсез үтмәде үтүлеккә. Фаягөл, чынлап та, аңа кәләш булырлык бичә. Картның да әле комы бөтенләй коелып бетмәгән. Халык мәзәгендәге гомере буе буйдак яшәгән

мәҗнүн түгел. Мәәктәге карт, сиксәнне үткәч, бер әби ияртеп, ЗАГСка алып барган, имеш. ЗАГС мөдиренең: «Бабай, гомерең буе буйдак йөреп, нишләп хәзер генә өйләнергә булдың?» – дигән соравына: «Мунча кереп чыккач, майкам итәген аркамнан билемә төшерә алмый изаланам, кызым. Тартып төшерергә ярдәмче кирәк», – дип җавап биргән, имеш.

Сиксәнне үтсә дә, Габделбәр карт, Аллага шөкер, күлмәкыштанын да үзе кия ала, башка эшләрен дә башкара, гомумән, мәәктәге карт хәленә калмаган әле. Күршесе Хөршидәнең пар мендәрдәй түшләрен, ястыктай очасын селкетеп тырт-тырт атлауларына игътибар итеп мыегын сыпырып куйган чаклары да булгалый. Хәтта бичәнең тел төбен тарткаласа, нәтиҗәсе нинди булыр иде икән, дип уйлап куйганы да бар. Әмма аңысы яшь шул әле. Яшьләре аермасы бер унбиш-егерме ел гына булса, бер хәл. Утыз биш – күбрәк. Өйләнәм, яшь кәләш алам дип, Мәскәү артисе Әрмән Җигәрхан кебек адәм көлдерерсеңмени... Ә менә Фаягөл булса... Буйсыны, зиннәтләре Хөршидә күршесенекеннән бераз калыша калышулыкка. Аның каравы йөзгә чибәррәк. Яшь аермалары да егерме чамасыннан артмас. Таман гына булыр...

Тик «кияү егетенә», татлы хыялларга чумып, озак ятарга туры килмәде. Йоклап кына киткән иде, таң алдыннан, дертләп уянды. Ниндидер шомлы көч аны тышка алып чыкты. Ул Бидрәш ягына күз салды, калтыранып китте, анда күк йөзе кан төсенә кергән иде. Колагына шомлы гүләү тавышы чалынды. Ни булыр бу?! Җиргә яктылык тарата алмаган кызыллык яшен яшьнәве түгел, көчәя барган гүләү тавышы да күк күкрәвенә охшамаган. Төньякдагы кебек атом бомбасы шартлаттылармы әллә?.. Бомба шартласа, Алтын Урда ханнары заманында ук барлыкка килгән Бидрәш шәһәреннән ни кала да, Габделбәр картның гомере буе бөртекләп җыйган дөньясыннан ни кала? Ә казлары? Ә Хөршидә күршесе? Ә шәһәр халкы?



Ул арада теге гүләү колак тондырырлык шатыр-шотырга әйләнде, күктәге кызыллык тагы да шомлырак шәмәхә төсенә керде. Коточкыч шартлау тавышы яңгырады, Габделбәр карт аңын югалтып егылды.

...Ул аңына килгәндә инде, таң аткан, кояш чыккан иде. Көчхәл белән аягына басуга ишек алдына хуҗа да килеп чыкты. Йөзе айның уңлүртенче кичәсе кебек.



– Бәй, кордаш, – дип елмайды ул кунагына. – Әллә, форсаттан файдаланып, күрше бичәгә кереп чыгарга да өлгердеңме?

Габделбәрнең ачуы килде. Әлек тә менә шундый ваемсыз була торган иде, әле дә шул холкын ташламаган.

– Төнен гарәсәт купты, дөнья җимерелә язды, синең һаман шул бер үк хәсрәт. Тол бичәгә өйләнү кайгысы бармыни әле монда?

– Мин, йокым аша күк күкрәп яңгыр ява дип уйлаган идем Җир коп-коры гуй, кордаш. Нәрсә җимерелә язган? Авылыбызның күптән кыйшаеп утырган су башнясы түгелдер бит.

– Дөнья дим, дөнья, аңгыра! Берни дә сизми йокладыңмыни?

– Куй әле шул саташуыңны! Мин, догалар укып яткач, саташмыйм да, ыштмим дә. Өйдә керик, Нурсәнәнең кулламасы әзер булганчы, тамак чылыта торыйк. Ул арада Фаягөл күрше дә йөгереп кереп җитәр. Җөрәгеңне җон басмагандыр гуй, сиңа гашыйк булганын әллә сизмәдеңмәме?

Тик Габделбәрдә кулламa кайгысы да, Фаягөл кайгысы да калмаган иде. Бидрәш урынындамы, түгелме? Җимерелеп, таркалып ятмыйммы? Ул ике чынаяк кына чәй эчте дә, кордашының ай-ваена карамый, юлга кузгалды. Бүген күңелле көн үткәрәселәрен өмет иткән Теләкбирде үпкәләбрәк торып калды.

Картның куанычына, шәһәр урынында иде. Аны ике генә нәрсә аптыратты. Бидрәшкә якынайгач, биш ел ябулы торган спирт заводы морҗасыннан төтен чыгуы күңеленә әллә шом салды, әллә өмет өстәде. Әлекке заманнарда үзе эшләгән мал симертү комплексының җимерек калдыклары тергезелгәнен күргәч, машинасын юл читендә утырган тирәккә алып барып бәрә язды. Туктады, машинасыннан төште, бер тән эчендәге үзгәрешкә, күзен бер ачып, бер йома биреп карап торды. Биналар, араннар урынында, тик маллар белән мал караучылар гына күренми. Менә конторадан парторгын ияртеп директор Букреев килеп чыкты. Алар комплекс капкасы янына килделәр. Капканың бер баганасына калайдан чүкелгән үгез башы беркетелгән, өстенә: «Малчы иптәшләр! Илебезгә мөмкин хәтле күп ит тапшыру өчен көрәшик!» дигән чакыру эленгән. Бу сүзләргә хәтта кемдер акбур белән «Үзебез ач булсак та...» дип өстәп тә куйган. Нәкъ теге вакыттагы кебек! Букреев парторгы Садрый Сәүбоновичка:

– Син, парторг, нигә аяк өсте йоклап йөрисең? Нигә менә бу антисоветчинага юл куясың? – дип җикерде. Безнең работниклар кайчан ач йөргәне бар? Кибетебездә субпродуктлар сатып торабыз. Малның башыдыр, тоягыдыр, ливерыдыр...

Парторг акланып маташкан булды.

Габделбәр абзыйның авызы ерыла бирде, чигәсендә генә калган чәчләре кыбырдашытырып куйды. Бу ни хәл?!. Әйе, Садрый кайчандыр «Коммунизм юлы» совхозының парторгы булып эшли иде. Ул бит күптәннән, әлеге мәхшәрләрдән соң, парторг түгел, Бидрәш шәһәренең мулласы. Габделбәр карт дини вазыйфаларның мәгънәсен бик белеп бетерми, Садрыйның үз сүзләре белән әйткәндә, «имам-мөхтәсибе». Кайчандыр сәүдәгәр Бәхтияр бай салдырган ике катлы таш мәчет тә советлар чорында клуб булып хезмәт итте, болганышлар башлангач, аны диндар әдәмнәр карамагына калдырып, яңадан мәчет иттеләр. Теге заманда парторг Садрый, клуб сәхнәсендәге имән такталардан кагылган трибуна артына басып, «Коммунизм юлы» совхозы хезмәтчәннәрен шушы изге юлда фидакарь хезмәт батырлыкларына өндәсә, хәзер Садрый мулла мәчет мөнбәреннән совхоз таркалып эшсез калган мөселманнарны Аллаһыга тугрылыкка өнди.

Парторг җилкәсен тырнагандай итте.

– Соң, Антон Харитонович, аилату эшләре алып барабыз бит инде.

– Сезнең аилату эшләрегезгә төкерим мин. Бу похабщинаны ликвидируй немедленно!..

Әйе. Габделбәр карт хәтерли, тап менә шулай була торган иде. Парторг теге язуны сөртеп тора, аны кемдер яңартып тора... Тик илдәге власть тәү Горбачевка, аннары Ельцинга күчкәч, комплекс маллары көтү-көтү булып каядыр очтылар, көннәрдән бер көнне Букреев, парторгын ятим калдырып, үзе дә юкка чыкты. Комплекс капкасын саклап торган үгез башы тутыкты, бер генә сыер малы да анда кызыкмас хәлгә килде. Ә теге лозунг, бик нык уңса да, малчы иптәшләрне хөкүмәткә мөмкин хәтле күп ит тапшырырга чакырып торуын дәвам итте. Әлеге өстәмәнең генә кирәге калмаган иде.

Габделбәр карт үзе дә аңгармастан директорына дәште.

– Нихәл, иптәш Букреев. Үзең кайтуын кайткансың да ул, нишләп урлап алып киткән малларыңны алып кайтмадың?

Директор карт сүзләренә игътибар итмәде, әйтерсең аны күрми дә иде. Хәер, юктан бар булган комплексның, юктан бар булган директоры Габделбәрне күрмәскә дә мөмкин шул. Парторгы да аның бүген парторг Садрый түгел, имам-мөхтәсиб Садрый. Ул да заманында «Коммунистик хезмәт ударнигы» исемен йөрткән гади малчыны әллә күрмәде, әллә күрмәмешкә сабышты.



Гомумән, әле күргәннәре Габделбәр картны аптырашта калдырса да, ул аларны төнге мәхшәр белән бәйләп карарга, ниндидер нәтиҗә чыгарырга әзер түгел иде. Иң мөһиме: үз дөньясы исән, ишек алдын бер итеп йөргән казлары хуҗаны каңгылдашып каршы алдылар. Ул арада күршесе Хөршидә дә йөгереп кереп җитте. Ни гыйльләдер, бер төн эчендә тагы да яшәреп, матураеп киткән кебек. Картның йөзе аптырауллы иде.

– Нихәл, күрше. Исән-имин генә тордыгызмы монда?

– Бер төн эчендә безгә чурт буласыңмыни? Казларың гына, таң атар алдыннан ыгы-зыгы кузгатып, йокымнан калдырдылар. Абзарга төлке-фәләнкерде микән әллә, дип йөгереп чыгарга да туры килде.

– Күк күкрәп, яшен яшьнәп яңгыр коймадымы?

– Дөнья җимерелердәй булып дөбердәде дә ул, яңгыры гына яумады. Бәрәңгеләремнең төбе корыйй, дым кирәк...

Габделбәр карт, аптыравыннан, иңбашларын гына җыерып куйды.

## Бидрәштәге сәер хәлләр

*Кешеләрнең бар теләкләре дә кабул булса,*
*җир шары тамугъка әйләнер иде.*

***Дания мәкале***

Ул гаҗәп хәлләрне тасвирлау алдыннан хөрмәтле укучыларыбызга бу шәһәр турында белешмә дә биреп китәргә кирәктер. Юк-юк, бер кулыгызга Рәсәй картасын алып, икенчесенә лупа тотып, әлеге шәһәрнең кайсы төбәкләрдә икәнен зинһар эзли башламагыз. Картада юк ул. Бидрәш кенә түгел, губерна үзәге дәпелы Кудеяр да, шушы төбәкне төньяктан көньякка урталай ярып үткән Шатуй елгасы да, шушы губернага караган Шатуйск, Степной шәһәрләре дә картада юк. Менә шулай дип күңелегезне төшерсәм дә, дөреслеккә туры карарга кирәк, агай-эне. Әгәр дөреслек дөреслеккә туры килсен дип, фәкыйрь язучыгыз Бәрелә, Балабәйдә, йә булмаса Минзәләдә булган хәлләрне тасвирласа, шушы шәһәрләрдә яшәгән замандашларыбыз, бигрәк тә дәрәҗәле түрәләр, миңа нинди күзләре белән карарлар иде икән? Ә бу төбәкләрнең башлыклары? Аллага шөкер, хәзер инде түрәләргә охшамаган китап

өчен Себер җибәрү юк, төрмәгә ябып кую юк, алар кулында бердәнбер чара – китапны дөньяга чыгартмау. Хәер, анысы да җиңел бит әле. Китапны укып карасалар гына. Әйе, форсат табып, алфавиттагы онытылып беткән бөтен хәрефләрне исләренә төшереп, укып карасалар гына... Екатерина патшабикә укыган, император Александр укыган, Сталин укыган. Укымасалар, Герценнарны, Радищевларны, Пушкиннарны, Чаадаевларны, Достоевскийларны, Ахматоваларны, Ильф белән Петровларны, Хәсән Туфанны, Даут Юлтыйны, тагы әллә кемнәрне, әллә кемнәрне җәзага тарттырмаган булырлар иде. Ай-һай зурдан купты бу адәм, үзен бөекләр сафына куеп маташа, дип уйлый күрмәгез, хөрмәтле укучыларыбыз.

Укып карасалар, дигән шик күңелдә шулай да яши. Укысалар, әйдә укысыннар! дигән чәм дә урын алган күңелнең бер почмагында. Алар өчен Бидрәш нәрсә ул? Кумертау, йә булмаса Мәләвез түгел ич. Бездә угрылар да, ришвәтчеләр дә юк. Ширкәтьләр ябылмый, халык җисемлектән интекми, җитәкчеләренең акыллы сәясәтеннән, табигать хозурлыгыннан ямь табып яши бирәләр.

Ә Кудеяр губернасына караган Бидрәштә... Анда да яши бирәләр.

Ничек яшиләр? Бу сорауга җавапны бидрәшлеләр үзләре генә түгел, хәтта шәһәр мэры Гапсатаров Энгель Заһидуллович та юньләп бирәлмәс иде.

Гаҗәеп шәһәр ул Бидрәш. Хан заманнарында ук Ефәк юлында барлыкка килгән ярым шәһәр, ярым авыл бу төбәкне күңелләре белән хуш иткән татарын, башкортын, казагын, үзбәген, урысын, яһүден, тагы әллә кемнәрен берләштереп, ярым шәһәрчә, ярым авылча яши бирә. Гадәтенчә яши бирә.

«Гадәтенчә»се – ямьле июль аеның якшәмбедән дүшәмбегә караган сәер бер төнендә чаклы. Сәер төнне, капыл кубып, капыл юкка чыккан гарәсәтне, элекке мал караучы, «Коммунистик хезмәт ударнигы» Габделбәр абзый читтән, Тәвеш авылыннан, гына күзәтте. Ә җәй томрасында изрәп йоклаган бидрәшлеләр ни гыйлла беләндер тоташлае белән саташкан шәһәр эчендә торып калган иделәр. Ә иртән торгач...

...Шәһәр мэры Энгель Гапсатаров йокысыннан ничек торып, ничек кырынып-юынып, ничек эшкә килгәнен хәтерләми. Бары кабинетындагы сәер үзгәрешкә генә аптырап калды. Ишегенә «Бидрәш шәһәре мэры» дигән язу урынына «КПССның Бидрәш шәһәр комитеты беренче секретаре Э. З. Гапсатаров» дигән язу эленгән. Көлсәң –



көл, еласаң – ела!.. Кабинетының бер як стенасында Ленин, икенчесендә – Брежнев портреты. Кепкасын кырын салып хәйләкәр елмайган шул ук Ленин, калын кашлары авырлыгыннан күзләре бераз йомыла, авызы бераз ачыла биргән шул ук Брежнев. Түшенә биш орден тагарга да онытмаган. Әйтерсең лә, берсе «мировая революция» куптарырга әзер, икенчесе «гади социализм» төзеп бетеп, «үсешкән социализм» төзүгә күчүе белән горурлана.

Әллә мэр, әллә беренче секретарь булуын үзе дә аңгармаган Гапсатаров эш өстәле артына килеп утырды. Өстәл өстендәге кәгазьләргә күз ташлады. Шулай да әле мин беренче секретарьмендер, дигән уй килде аның башына. Кәгазьләр өстендә Бидрәш мал симертү комплексының хөкүмәткә ит тапшыру планын арттырып үтәве турында рапорт ята иде. Комплекс директоры Букреев кул куйган документ.

Тәү Гапсатаровның күңелен шатлык биләп алды. Ул – беренче секретарь! Озак еллар хыялланып та ирешә алмаган хыялына ирешкән! Ул ит планын арттырып үтәгән... Озакка сузмый КПССның өлкә комитетына рапорт бирергә кирәк! Ул тиз генә секретаре Руфина ханымны чакырып кертеп күрсәтмә бирде, телеграммага кул куйды...

Тик озакламый шатлык хисен шөбһә хисе алмаштырды. Ничек була инде бу? Рәхәтләнеп яша-яшә дә, яңадан партия кысаларына кире кайт! Ә тырышып-тырмашып туплаган байлыгы? Нәрсә, ул элекке кануннар буенча «расхититель социалистической собственности» булып чыгамы? Ә Бидрәштәге, Кудеярдагы сөяркәләре? Нәрсә, ул «моральное разложение»гә дучар булганмы? Аны бу гонаһлары өчен партия сафыннан сөрергә, югары вазыйфасыннан бушатырга мәҗбүр булалармы? Юк, Гапсатаров өчен бүгенге тормыш яхшы! Юк! Тагы бер тапкыр юк!..

Әйтергә кирәк, мэрның бу көне, күз алдында юк-бар күренешләр чагылып, башына әллә нинди уйлар килеп, рәтсез-чиратсыз үтте. Әллә үтте, әллә үтмәде – ярый әле гадәти булмышында ниндидер эз калдырмады.

Хәер, шәһәр башлыгы булмышында гынамыни... Полиция бүлеге түрәсе подполковник Самохваловны, имештер, Кудеярга чакыртып алдылар. Обком секретаре үзе, Бидрәш шәһәрендә җинаятьчелек белән аяусыз көрәшкәне өчен, кулын кысып рәхмәт белдерде. Чираттагы полковник званиесенә лаек булуы белән котлады, хәтта аның погоннарына өченче йолдызларны да үз куллары

белән такты. Йокысыннан уянгач, Самохвалов бик озак тормый нишләп әле ул капыл гына полиция подполковнигыннан милиция полковнигына әйләнүе турында уйлап ятты. Хәтта соңыннан шикләнеп тә куйды ул. Әллә бөтенләй тормады, шулай көн үткәрде инде?. Тик, тагы бер уянгач, торырга, эшкә барырга кирәклеген исенә төшергәч, киенә башлагач, кителе погоннарында һаман да икешәр генә йолдыз күргәч, төнле төшенең ямьсез шаярту булуын аңлады. Хәер, үз-үзен юатырга да урын бар иде. Отставкага милиция полковнигы булып чыкса, зур булмаган пенсиясенә суган суы суырып яшәр идеме? Ә болай «заначка»сы көннән-көн тулыланып тора, Шатуй буендагы дачасы җитүлеккә Гапсатаров дачасына җитмә дә ул, әмма аның, бичәсенең, балаларының уңайлыкларга булган ихтыяҗын артыгы белән канәгатьләндерә. Машинасы да «важный персона»лар алдында йөз кызартырлык түгел. Юк, милиция полковнигы булганчы, полиция подполковнигы булу яхшырак!..

...Гомере буе Бидрәш спирт заводында слесарь булып эшләгән Тимергали абзый күптән пенсиядә булса да, үзенең яратып башкарган эшен һаман оныта алганы юк. Завод ябылды, аның «шифалы» эчемлеге өчен генә кызыгып эшкә йөргәннәр заводны күптән инде онытканнардыр, онытмаган булсалар да, күптән инде әлеге «шифалы» эчемлек аркасында Бидрәш зыйратында соңгы тәякләрен тапканнардыр. Тимергали абзый «шайтан төкереген» бер вакытта да авызына алмады. Шуңа күрә ул исән, беләкләре нык, акылы аек. Тик бу көнне әнә шул аек акылы да чыгымчылый биреп куйды. Тәү ул завод цехлары буйлап, аның корамалларының төгәл эшләвен карап йөрде. Аннары, кирәкле деталь таптырып директор Чубченко белән киңәшеп алды. Бәлки, ул әтрәк-әләм айнык булса, ул хәтле ачуы да килмәс иде. Гадәтенчә, күзләре тонган, теле көрмәлә. Җитмәсә шул теле белән «социалистик ярыш», «КПСС съездын лаеклы каршылау», «күтәренке йөкләмәләр» турында акыл сатып маташа.

Бик тә ачуы килеп уянган иде. Әллә уянды, әллә инде уянмады да, балконына чыкса завод морҗасыннан сыек кына төтен күтәрелгәнен күреп, шатлангандай булды. Завод ябылып, андагы дүрт мең кешенең урамга чыгарып ташланганына җаны көеп йөргән картның эченә җылы кереп киткәндәй булды. Тик төндәге дәбер-шатырның ангыр алып килмәве тагын эчен пошырды. Шәһәр читендәге бакчасындагы өлгереп килгән бәрәңгеләренең төпләре корып утыруы өчен пошыра иде картның.



Әлеге төтен дә озак чыкмады, сыегайганнан сыегая барып таралды, юк булды.

...Бирдәш шәһәренең беренче урта мәктәбендә тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшләгән Сәриянең дә йокысы йокы булмады. Директорлары отпускыда. Вазыйфасын вакытлыча яшь кенә кыз бала кулына калдырды да, Башкортстандагы Красноусол санаториенә ялга сыпыртты. Әйдә, Сәрия Мәхмүтовнасы сыдырылсын монда! Класс бүлмәләрен дә агарттырсын, буятсын, мәктәп яны участогында чәчкәләр дә үстерсен (әйе-әйе үз куллары белән үстерсен, балаларны эшкә кушарга рөхсәт юк). Ярый әле ярдәмгә пенсиядәге рус теле һәм әдәбияты укытучысы әнисе бар.

Төнге дәбер-шатырга бик зур өмет баглаган иде дә, анысы да кысыр күкрәү булып чыкты. Моны Сәрия урамга чыккач, мәктәп ихатасына барып кергәч күрде. Коп-коры! Әмма үзгәреш юк түгел. Мәктәп бинасы ничектер яшәреп, матураеп киткән кебек. Әллә төнге сәер төшләреннән соң директор урынбасары Сәрия Мәхмүтовнаның күзенә генә шулай күренәме? Колагына хәтта балалар чыр-чуы да кагылып киткәндәй булды.

...Ул төнне Зәмзәмбикә кортканың төше барысыныкыннан да сәерерәк булгандыр. Тавык кетәгендә шау-шу башланды. Кыткылдый-кыткылдый, хуҗабикә чыгарып салган кичке сыйны чукыштырганнан соң, Баш әтәч, кирәк өчен түгел, ә үзенең чынлап та баш икәнен белдерү өчен генә, «Ки-крик-кү-ү-үк!» дип сөрән салган булды да, бераз канатларын селкеп торып, кунагача сикерде. Сикерде, әмма кунып өлгерә алмады. Әллә хәле җитмәде, әллә башы әйләнеп китте, – җилпелдәп егылып килеп төште. Как идәнгә төшсә – эш харап, йә башын тишәр, йә берәр кабыргасын сындырыр иде. Ярый әле Карт тавык өстенә килеп кунаклады. Үзенең озын гомерендә сыртында бик күп тапкыр әтәч авырлыгын татып караган тавыкка, билгеле, чыртым да булмады. Ләкин, картайгач, адәм баласы гына түгел, кош-корт та мыжыкка әйләнә икән шул.

– Күзең чыктымы әллә, карт тәре?! Тавыкларың өстенә генә түгел, кунагача да сикерә алмый башладың! Кыт-кыт-кыт! Кыт-кыт-кыт! – дип битәрләде ирен тавык.

– Телеңне тый, кортка! Сикерәлгәнем-сикерәлмәгәнемне күрсәтермен мин сиңа!..

Кызып барган талашка Баш әтәчнең куштаны Чуар тавык та кушылды.

– Күрсәт, күрсәт күрмәгәнен син аңа! Югыйсә, гел сиңа каршы сөйләп, яшь тавыкларны котырта…

Бу җәнҗалны читтән күзәтеп торган язгы чебешләр дә кызык тамашадан читтә калырга теләмәделәр.

– Кот-кот-кот, котырта! Кот-кот-кот, котырта! – дип шаулаштылар алар.

Баш әтәч каршында Чуар тавыкның абруе күтәрелә баруына эче пошкан Ак тавык та, уңайлы мәлдән файдаланмый, коры каласы килмәде.

– Үзебезнең иребездән гаеп табып маташа. Гомер буе күрше Әүхадинең Кызыл әтәче белән чуалганын белмиләр дип уйлый, ахрысы, карт себерке! – дип ягган утка бензин бөркеде.

Карт тавык, мин карт дип тормады, Ак тавык өстенә очып кунды.

– Ах, җир бит! Кем-кем, син авыз ачарга оялыр идең! Яз буе йомырканы читкә качып салдың. Ике атна җәһәннәм тишегендә качып утырып, эшкә ашмаган йолкыш чебешләр ияртеп кайттың. Бер оя тутырып чыгарсаң тагы бер хәл. Өч бөртек бит уйнаштан туганнарың! – дип Ак тавыкның каурыйларын пыр-туздыра башлады.

– Безме уйнаштан туганнар? Безме уйнаштан туганнар? – дип чепелдәштеләр яшьләр. – Яшьләр дигәнебезнең икесе тавык затыннан булса, берсе Зәмзәмбикә кортка Баш әтәчкә алмашка калдырырга уйлаган Яшь әтәч иде.

Тавыкбикәләр Карт тавыкның кайсысы түшен, кайсысы битен чукырга тотынды. Кызып киткән Яшь әтәч хәтта кортка коерыгының ике каурыен умырып йолкып алды.



Баш әтәч тәү тавыкларының, аны бар дип тә белми, әрсез кылануыннан югалып калган иде. Ләкин ыгы-зыгыга, сөмсезләнеп, Яшь әтәчнең килеп кысылуы аны тиз айнытты.

– Туктатыгыз немедленно бу безобразиене! Миңа каршы бунт күтәрергә уйлыйсызмы?! – дип хатыннарын йолыккалап аерды. Көндәшен томшыгы белән кикригеннән эләктереп алды да, арт сапына тибеп очырды. – Мине тәхеттән төшерергә чамалыйсыңмы, панимаш. Синең кебекләрне теге вакыт ничек акылга утыртканны онытма! Үзләрен генә түгел, кетәкләрен дә кара көйдердем!

Катнашазык тутырылган тартма артына очып барып төшкән Яшь әтәч тә җавапсыз калмады.



– Син – әтәч түгел!, эшкә ашмаган йолкыш сасыкан! Алкаш! Булдыксызлыгың аркасында хәзер тавыкларыбыз йомырканы да аз сала. Шуңа күрә хуҗабикәбез безне ачлы-туклы тота. Болай булса, безне суеп ашап та бетәр әле. Ә син үзең дә булдыра алмыйсың, властьне миңа да бирмисең. Агай-эне, болай булмый! Безгә досрочно яңа Баш әтәч сайларга кирәк. Мин үземнең кандидатураны тәкъдим итәм. Кем риза, канатларыгызны күтәрегез!

– Шта? Досрочный сайлау? Сайлатырмын мин сине, панимаш! – дип җикерде Баш әтәч. – Срогым тулганчы утырачакмын әле мин!

– Утыр, утыр! Син законный, – дип кыткылдадылар өлкән тавыклар.

– Долой, долой! Син – булдыксыз, – дип чепелдәштеләр яшьләре.

Кетәктәге ыгы-зыгы бар шәһәргә дип әйтерлек янгырап торды.

Әллә төлке-фәлән кереп тавыкларымны кыра микән дип ут йотып, Зәмзәмбикә йокысыннан уянып килеп чыкмаса, бу шау-шу күпмегә кадәр дәвам итәр иде икән дә, ни белән бетәр иде икән?

– Нигә шаулашасың, мур кыргыры нәмәстәкәйләр? Куначагызга куныгыз да шымыгыз! – дип җикерде хуҗабикә җәнҗалчыларга. – Югыйсә…

Югыйсә ни булачагын тавык халкы ишетмәде, чөнки Зәмзәмбикә кортка, кетәк ишеген «шап» итеп ябып, сөйләнә-сөйләнә, өенә кереп бара иде.

– Баш әтәчем картайды, рәте китеп бара. Бер генә дә кетәккә хуҗа була алмый башлады. Иртәгә мунчама утын китерергә тиешләр, казанга шунысын төшерергә туры килер, ахры…

Хуҗабикә янавыннан айнып киткән тавыклар, берәм-берәм куначага сикереп менеп, йокыга талдылар.

Әтәч-тавыклар сөйләшә белми бит, уйлап куяр кайсы бер укучыларыбыз. Кош-корт кына түгел, без, адәм балалары да бит, төшереп алсак, ни сөйләгәнебезне, ни кыланганыбызны белмибез. Ә әлеге тавыкларыбыз, билдәһи дип әйтим, җәнҗалны айнык баштан түгел, салмыш баштан куптарды. Кәмешкә үткәргәннән калган бал түпрәсен, Зәмзәмбикә карчык, әрәм булмасын дип, тавыклары тагарагына салган иде.

Аннары, шәһәр өстеннән үткән гарәсәт кешеләрне ништәтмәс тә, хайваннарны ништәтмәс. Зәмзәмбикә карчык башында туган ярыйсы ук төшем китерердәй план да кетәктәге тамашага бәйле иде.

…Әкрен генә көнгә тоташкан бу төн, соерлеге, галәмәт төшләре, саташулары белән бик күп бидрәшләрне гаҗәпкә калдырып шулай

үтеп китте, аны календарьдан сызып ташладылар да, пәнҗешәмбе көнен гадәттәгечә яши башладылар. Кеше – сәер җан иясе бит ул. Үзенең татлы төшен дә сөйгәнә иң якынына гына сөйли, ә ямьсез төшләрен, саташуларын, нишләп кеше көлдереп башкаларга сөйләп йөрсен. Исәргә чыгарачаклар ич!.. Бу төнне тоташ Бирләш саташса да, аны һәркем үзенең саташуы гына дип кабул итте.

...Йорт эшләрен бераз караштыргач, Габделбәр карт капка төбенә чыгып утырган иде. Төнге гарәсәттән соң шәһәр нинди хәлдә, кешеләр үзләрен ничек тота? Юк, үзгәреш юк дип әйтерлек. Үткән-сүткәне кайсысы елмаеп, кайсысы ыржаеп дигәндәй сәлам биреп үтә. Хәер, кешеләрдә ниндидер аңлашылмас үзгәреш бар да кебек. Күзләре үтә күренмәле пәрдә белән капланган дип әйтергәме, йөрешләре дә лунатик чиренә дучар хасталарныкы кебегрәк...

Озакламый каршы йорттан, аның кыйшая биргән капкасын ачып, Бакый күршесе килеп чыкты. Гадәтенчә, сакал-мыегы кырылмаган, чәче тузган, авызында газит кәгазенә төрелгән самосады борхый. Ябылып бетмәгән капка артыннан бичәсе Сафураның чәрелдек тавышы яңгырады.

– Кайтып күземә күренәсе булма, адәм актыгы!

Һай, бер дә гене дөнья көтүләренең рәте-чираты юк шул Сакау Бакый белән Ялкау Сафураның!

Ир, капка төбендә утырган күршесен күргәч, куанып киткәндәй булды, алпан-тилпәнрәк атлап килеп Габделбәр карт янәшәсенә кунаклады.

– Әссәламмәгаләйкем, күлше.

Габделбәр карт сасы самогон белән сасы тәмәке исеннән читкәрәк күчеп утырды.

– Вәгаләйкемәссәлам, Бакый. Нәрсә, ни бәйрәм юк, ни шимбә, якшәмбе түгел, син – салмыш.

– Отгулым минем, Габделбәл абзый, якшәмбе эшләгәнем өчен законный отгулым...

– Отгулың булса ни. Дөньяңны карар идең, бичәңә әзрәк кенә булса да илтифатлык күрсәтер идең

Бу сүзләрдән Бакыйның йөзе, нәрсәнедер озак эзләп тапкан кешенеке кебек яктырып китте.

– Әйе, әйе Габделбәл абзый, үзем дә шулай уйлыйм шул. Хатын дөлес әйтә, мин – чыннап та адәм актыгы. Шулай булмасам, өченче көн эчеп кайтып аның чәченнән сөйләп йөлтеп идемме? Юк, адәм актыгы гына түгел, ишәк мин. Фәлештәй бичәмнең кадлелен белми



ямьсез сүзләл белән сүгеп идемме. Ул бит гөнаһсызларның гөнаһсызы! Үзе чибәл, үзе акыллы, күңеле таза. Аккошым бит ул минем!

Габделбәр карт быел Камышлы күлдә оя корып бәбкәләр чыгарган пар аккошны күз алдына китереп, Ялкау Сафураның иләмсез юан сыны белән чагыштырып, елмайды.

– Шулай шул, күрше. Һәр бичә үз ире өчен аккоштан да матур җан иясе булып тоеладыр инде.

– Мин дә шулай дим шул, күрше. Минем Сафуламнан да изге җан иясе юк дөньяда. Ә мин, юньсез, кичә беләсеңме нишләдем? Күлмәкләлен җыеп мунча миченә яктым. Юк, болай яламый! Мина да сөеклем Сафулам белән юньле толмыш башлалга вакыттыл!

Бу сүзләреннән соң Бакый нинди гыйлләлә беләндер ике күзеннән ике бөртек яшь тә чыгара алды. Габделбәр картның да күңеле йомшарып китте.

– Ә беләсеңме, күлше, – дип трагик монологын дәвам итте Бакый, – Мин хәзел чәчкә кибетенә йөгелеп балам да, үземнең күбәләгемә бел букет чәчкә алам. Юк, букет кына түгел, бел кочак чәчкә алам. Иң матуллалын сайлап алам. Кайтып сандугачым кулына тоттылам да, аягына егылып гафу үтенәм. Шулай дөлес булыл бит, күлше.

Бу күренешне күз алдына китереп, инде Габделбәр картның да күзләреннән яшьләре чыкты.

– Бик мәслихәт, Бакый улым, бик мәслихәт! Шулай дөрес булыр.

Тату яшәп китәрсез...

– Әйе, хәзел китәм чәчкә кибетенә! – Бакый уйланып калгандай булды. Тишек кесәсенә тыгылды Аннары күзләрен мөлдерәтеп картка карады. – Ни бит әле, Габделбал абзый. Кесәдә бел тиен дә акча юк бит әле. Ике йөз илле биш сум сиксән дүлт тиен генә акча билеп толалмассың микән?

«Шатуйская» атлы хәмернең бер шешәсе нәкъ шул чаклы торганын Габделбәр карт белми түгел, белә иде. Тик ул моны онытты.

– Ул чаклы гына акча бер кочак чәчкәгә җитмәс бит күрше. Булгач, биш йөз булсын инде. Мә!..

Мондый игелек өмет итмәгән ирнең күзләре маңгаена менде. Ул, рәхмәт әйтергә дә онытып, Себер урамы буйлап йөгерә-атлап китеп барды. Сулга, чәчкә кибете урнашкан чатка, борылмады, чатны үтеп китеп, Әлим бай кибетенә кереп күздән югалды.

Габделбәр карт шулай буласын тоемлый иде инде.

## ГУБЕРНАТОР ШӨБҺӘЛӘРЕ

*Тарих кабатлана, бу – аның җитешсезлекләренең берсе.*

*К. Дарроу*

Буйновский әле Кудеяр өлкәсенең губернаторы булып өч кенә ай эшли. Дөресрәге, губернатор вазыйфасын башкаручы гына. Аңа хәтле өлкәнең налог идарәсын җитәкләде. Бердән-бер көнне, губернатор Монастырев бичкә җитәкләгән «Лафа-банк»ның бар байлыгын учына йомып, хәләл җефетен, аңа ярдәмгә сөяркәсен дә ияртеп, юкка чыкты. Аны эзләп караган булдылар. Испаниянең Атлантик океан ярындагы иң гүзәл төбәкләренең берсендә үз вилласында исән-имин яшәп ятуы, кальвадос атлы хәмер чөмереп тик ятуы ялкытып китсә, үз яхтасында диңгездә җилләнеп кайту гадәтен белгәч, аңа кул селтәделәр дә, бөтен Рәсәй розыскысы игълан итеп, тынычландылар. Тап Хуҗа Насретдин турындагы мәзәк кебек. Хуҗа көп-көндез урамда иелеп-бөгелеп нидер эзләп йөри икән. «Хуҗа, ни эзлисең?» «Бер тиен акчамны төшереп җибәрдем, шуны эзлим». «Кайда төшереп җибәрдең соң аны?» «Өйдә инде». «Нишләп аны урамнан эзлисең соң?» «Өйдә караңгы ич!» Англиядә, Франциядә, Италиядә, Яңа Зеландиядә, ниһаять, АКШта менә шулай, Кудеяр губернаторы кебек, таланган, урланган Рәсәй байлыгына кәеф-сафа корып яшәүчеләр әзмени. Аларны һаман да Рәсәйдә эзләп бер булалар.

Кыскасы, Мәскәүгә Буйновскийны чакырттылар.

– Сез, Буйновский әфәнде, Кудеяр өлкәсендә налогны оста җыйдыгыз. Җыелган налог күләмен арттыра барып, алдынгылар рәтенә чыктыгыз. Менә сезгә җаваплырак вазыйфа тәкъдим итәбез. Сезгә – сынау срогы. Әгәр дә шул вакыт эчендә өлкәнең какшаган икътисадын иякә кертеп, угрылык, коррупциянс тамыры белән йолкып алсагыз, губернатор итәрбез...



«Налогны оста җыючы» тамагына тыгылган иkeләнүен кеч-хәл белән йотып җибәреп:

– Тырышырмын... – диде.

Ничек икеләнмәсен инде? Байтак губернаторлар тырышып – тырышып карыйлар да, үзләре сазлыкка баталар. Ярый да Монастырев акыллы булды, эләкмәде. Ә башка губернаторлар, министрлар, генераллар?..



...Киров өлкәсенең элекке губернаторы Никита Белых атлы адәм, утыргач, җылы урында, төрмә китапханәсендә, эшләгән-эшләгән дә, төрмә режимын бозган өчен тегү цехына сөрелгән. Хәзер үзе белән бергә утырган зәкларга ыштан-күлмәкләр тегә, имеш.

Мари иленең элекке башлыгы Леонид Маркелов, камерада утыра-утыра икән дә, эче пошып китсә, шигырь язарга тотына икән.

...Ә удмуртлар түрәсе Александр Соловьев һаман 139 миллион күләмендә ришвәт алмадым дип, ныкышып маташа, ди. Бәлки, ришвәте, чынлап та, йөз дә утыз тугыз миллион түгелдер, йөз дә утыз сигез генәдер?

...Коми төбәген моңа хәтле җитәкләгән Вячеслав Гайзер, судлаша торгач, кайсы бер гаепләүләрдән – җинаятчел банда оештыру, дәүләт вазыйфасы белән ришвәт алулардан – азат ителгән дә, аның өстендә мошенниклык һәм акча юу гына торып калган. Утырасы срогын-да 20 елдан 11-гә генә калдыртуга ирешкән. 160 миллион штрафы инде аның миллиардлар белән эш иткән бурга чүп кенә!..

...Ә Сахалин губернаторы Хорошавин, министрлар Абызов белән Улюкаев, сенатор Арашуков. Хорошавин дигән адәм акча юу кигазьләренә да кулын бер миллион доллар торышлы ручка белән куйган, имеш.

...Ә акчаны миллионлап, миллиардлап түгел, КАМАЗ белән урлаган полковник Захарченко?..

«Комсомольская правда» гәзите укучыларына тәкъдим иткән шушы белешмәләрне караштырып чыккач, Буйновский тагы да уйга калды. Әйе, заманында бер акыллысы: «Рәсәйнең төп бәласы – кәрләр белән начар юллар» – дип әйткән дә ул. Исәрләр әле дә күп, хәтта түрәләр арасында да... Начар юллар да әз түгел. Әмма төп бәлалар арасында угрылык беренче урынга чыкмады микән? Ирексездән икенче акыллы әйткән сүзләр белән килешергә туры килә: «Рәсәйдә угры угрыга атланып угры белән куа.

Туктале, мескен губернатор урламый, ришвәт алмый коры зарплатага ничек яшәргә тиеш? Хәтта ул зарплата аена ярты миллион тәшкил итсә дә. Сирәкләп шулай яшәгәннәр дә бардыр да ул! Күрше Татарстан белән Башкортстанны гына ал. Аларның башлыкларын тотмыйлар да, утыртмыйлар да ич! Бәлки, алар бөтенләй урламыйлардыр? Урламыйча ничек яшиләр икән? Бәлки, аларга барып,

тәҗрибә өйрәнеп кайтыргадыр? Бу фикер яшь губернаторның үзенә дә кызык тоелды. Ул, әлеге тәҗрибә уртаклашу барышын күз алдына китереп, елмаеп куйды.

Икенче нәрсәне исенә төшереп, тагы җитдиләнде. Төбәк башлыкларын ришвәт, коррупция өчен генә эштән алмыйлар да инде. Башка сәбәпләре дә табылып тора. Чувашстан башлыгы МЧС хезмәткәрләренә фатир ачкычы тапшыргандагы шартгуы өчен эштән китмәдеме? Имеш, бер подполковник ачкычны түрәнең өскә күтәргән кулыннан сикереп алырга мәҗбүр булган. Имеш, төбәк түбәсе шушы кылыгы белән погонлыны мыскыл иткән. Шул да булдымы җинаять! Подполковниклар буа буарлык, ә губернатор – берәү. Аннары, фатирсыз калдырмаган бит, биргән... Уе шушы тәңгәлгә җиткәч, Буйновский дертләп китте. Исенә губернасының көньяк читендә урнашкан Бедряшево шәһәрендә булып яткан аңлашылмаслык сәер вакыйгалар төште. Губернатор колагына килеп чалынганнары гына да аны бер мәртәбә түгел, биш мәртәбә эштән алырлык. Ярый әле бу турыда өстәгеләр белеп өлгермәгәннәр. Буйновский эчке телефоннан секретарен чакырып кертте, әмерен җиткерде.

– Запеканкинны тап, тиз генә миңа килеп җитсен!..

## ГУБЕРНАТОР ҺӘМ ПОЛКОВНИК

*Кем боерса – шул солтан, кем йөгерсә – шул кушкан.*

***Татар халкы мәкале***

Губернаның иминлек хезмәте түрәсе полковник Запеканкин хәле-тыны бетеп губернатор кабинетына килеп кергәндә, кабинет хуҗасы һаман да уйларын бер ноктага туплый алмый утыра иде. Ярый әле иминлек офицерлары хәрби киемдә йөрми. Төбәнәк кенә гәүдәсенә – китель, кабактай йомры башына биек фуражка киеп җибәргән булса, колгадай озын буйлы түрәсе янында бик кызык күренер иде. Хәер, алар бу «кызыкка» игътибар итәрлек хәлдә түгел иделәр.

– Здравия желаю, Аристарх Федорович!

Губернатор салкын гына:

– Саумы, Запеканкин, – дип өндәште. Утырырга урын тәкъдим иткәч, сүзен ерактан башлап тормады. – Безнең КГБ нәрсә карый? Күккә карап йолдыз санныймы? Бер кичкенә Бедряшевода государ-



ственный переворот ясап яталар, па-аниммаеш. Ә сез, кургаш солдатлар, моңа ноль внимания! – дип битәрен белдерде.

Запеканкин кызарынып-бүртенеп китте. КГБның күптән юкка чыгуы, аның урынын ФСБ атлы бик җитди оешма алуы турында губернатор сүзләренә төзәтү кертүне артык санады. Төзәтсә дә, түрәсе: «КГБни, ФСБни – один черт. Одни бездельники...» – дип хилаф сүз ычкындыруыннан курыкты. Кызганда, уйламый сөйли торган гадәте бар аның. Бу сүзләр Запеканкинның Мәскәүдәге түрәләренә барып җитсә, ни әйтерләр? «КГБ профукал СССР, а ФСБ держит Россию», – дип кенә сүгенеп куйсалар, бер хәл. «Губернаторыңны тәрбияли белмисең», – дип бөтен булган-булмаган бәлаләрне Запеканкин өстенә аударсалар?..

– «Государственный переворот» дип бәһаларлык җинаять юк та инде, Аристарх Федорович. Әгәр, чынлап та, шулай булса, спецназ җибәрер идек тә, андагы власть структураларын пыран-заран китерер идек!.. – Иминлек саклау түрәсе хәтта кечкенә йодрыгы белән өстәлгә сугып куйды.

Бу ишарәгә губерна түрәсе дә битараф калмады. Көрәктәй учы белән ул да өстәлне шапылдатты. Пистолеттан аттыланмыни, хәтта Запеканкин, дертләп китеп, йомры башын күн курткасы эченәрәк яшерә дә бирде. Буйновский да нигәдер озын кылыч борынын сыйпап алды.

– Җинаять булмагач, нәрсә бар, полковник? Менә бу документ нәрсә турында сөйли, анда ни язылган? Укы! Өстәлендә яткан кәгазьне губернатор Запеканкинның борынына ук китереп терәтте. Иминлек түрәсе аны кулына алды, бер күзенә якын китереп, бер читкәрәк этәреп укырга маташты.

– КПСС-ның Кудеяр өлкә комитеты беренче секретаре иптәш Буйновскийга... – Шушы сүзләрне укыгач, Запеканкин аптырап хуҗасына күз ташлады.

– Әйе, әйе, «беренче секретарь», дигәннәр, «иптәш Буйновский», дигәннәр... Бу нәрсә? Издевательствомы?..

– Аңысын миңа син аңлатырга тиеш инде, полковник ФСБ. Издевательствомы, әллә провакациеме? Бедряшеводан килгән кәгазь кисәге. Гади кәгазь түгел, фирменный бланкка КПССның Бердряшево шәһәр комитеты беренче секретаре Гапсатаров кул куйган «документ». Миңа гына аталганмы, әллә копиясе Мәскәүгә дә юллатылганмы? Юллатылган булса, синең белән миңа ни яный?

Запеканкин үзе дә аңгармастан «Кердык!» дип ычкындырды.

– Соң, әйттем бит инде, Аристарх Федорович, спецназ җибәрик тә, бу болага нокта куйыйк. Болачыларның аякларын җиргә дә тигезмичә, безнең эчке төрмәгә алып кайтып тыгыйк. – Полковник хәтта ике кулының бармаклары ярдәмендә рәшәткә дә ясап күрсәтте. – Ул сатлыкҗаннар монда тиз айнырлар…

– Буйновский мыскыллы елмайды.

– Шуннан? Синең спецназыңның дуракланувы Мәскәүгә барып җитмәс, дисеңме? Икенче көнне үк Америка бар дөньяны шаулатмас, дисеңме?

Акылын көчәндерүдән Запеканкинның маңгаена тир бәреп чыкты.

– Алай булса, Аристарх Федорович, Бедряшевога комиссия җибәрик. Әйтик, ышаныч белдерсәгез, җитәкчесе – мин, комиссия составына хакимиятнең хокук бүлеге җитәкчесен, полиция түрәсен, җәмәгатьчелектән өч-дүрт кеше кертсәк…

– Әйе, комиссия, җәмәгатьчелек, тегесе-монысы… – дип үз алдына сөйләнгәндәй булды өлкә түрәсе. – Уйлап кеше белгән нәрсә, бар өлкә белмәсме да, ул Мәскәү өчен сер булып калырмы? – Ул озак кына уйланып утырды. Аннары нәрсәнедер исенә төшереп маңгаена шапылдатып сугып алды. – Тукталс, полковник, безнең теге Әюпов атлы гениебыз кайда әле, ни эш бетереп ята?

– Бу фамилияне ишетү белән Запеканкинның йөзе бозылды.

– Полковник Әюповмыни? – «Полковник» сүзенә басым ясавы «гений» сүзеннән көнләшүе икәнлеген укучыга аңлатып тору артыктыр. Янәсе, гений булса да, әллә кая китә алмаган әле. Запеканкин да полковник, Әюпов та полковник.

– Нәрсә, отставка ләззәтен кичереп ятамы?

– Отставкада ук түгел түгеллеккә, запаста гына. Аңа нәрсә, дачасында крыжовник үстерә дә, Шатуйда балык тота. Шушы көннәрдә генә туган көне белән котлаган идем, атым юк урамда, кайгым юк буранда, ди. Нинди ат турында сөйлидер магометанин, бик аңлашылып бетми? Әмма, до Бога высоко, до начальства далеко, дигәненнән дөньяга карашы, кәефе яхшы аңлашыла инде. Без монда Кудеяр губернасының иминлеге сагында торып, көне-төне сыдырылабыз. Ә ул?..

– Менә нәрсә, полковник, миңа тиз генә шул Әюповыңны чакыртып китер әле.

– Кызганычка каршы, чакыртып китерә алмыйм. Ул бит безнең штатта тормый, служба внешней разведки штатында.



Буйновскийның калын кашлары җыерылды.

Алай булса, минем исемнән попроси. Машина җибәр…

– Монысы була…

– Килгәнче, аның турында миңа белешмә дә әзерләп керт.

## АКЧА ЮЛДА АУНАП ЯТА…

*Кешенең акчасын тартып алуның чагыштырмача намуслы дүрт йөз ысулы бар.*

***Остап Бендер***

Запеканкинны чыгарып җибәргәч, Буйновский нишләптер кабинетының сул як почмагында кукраеп торган зур көзге каршына килде. Көзге чагылдырган йөзенә, сынына карап озак кына басып торды. Озын буйлы булса да, зифа гәүдәле түгел. Бигрәк какча. Апетиты юк, аз ашый дисәң, инде? Юк, тәмледән тәмлене сайлап умыра гына. Тик, кем әйтмешли, ашаганы арт ягына гына китеп тора. Арык йөз, шардай зур яшел күзләре, кәкре кылыч борыны, зур авызы, ияк астында йолрыктай калкып торган бизе… Кыскасы, тан-кыйфәт күзлегеннән караганда, йөзе-сыны бер дә күңелен юатырлык түгел шул. Тарихка күз ташласаң, зур дәрәҗәләргә ирешкән адәмнәр бер дә моңдый кыяфәтле булмаганнар ич. Шул ук Наполеон, шул ук Черчилл, шул ук Рузвельт, шул ук Ленин, шул ук Сталиннарны гына ал. Хәер, Рәсәйнең хәзерге җитәкчесе дә. Һич тә колгадай озын түгел. Кайсыдыр замандагы кайсыдыр илнең хакиме тигезләр өчен үзеннән озын вәзирләренең, башларын кистерә торган булган, имеш.

Хәзер ул заманнар үткән, әмма мәскәүлеләрнең ышанычын акламаса, һаман шул дотационный төбәкләр арасында йөрсә, башын ук кистермәсәләр дә, нишләтерләр?.. Буйновскийның уйлары үзләреннән-үзләре өлкә бюджетының нәкыслыгы, предприятиеләрнең бер төрлесе ябылуы, икенче төрлесенең налог базасы кыскарганнан-кыскару мәсьәләләре тирәсендә чуала башлады. Инвестицияләр, имеш! Америка байлары Кудеярга килеп заводлар, фабрикалар төзергә ашкынып тора ди. Хәтта кытайлылар да бу төбәкне урап үтә. Өлкә бюджетын тулыландыруның бердән-бер юлы әлеге авызларын ачса, үпкәләре күренергә торган халык булып чыга шул. Тупасрак итеп әйтсәң быдло… Аларны җәлләп утырып булмый. Ил төкерсә, күл була принцибын алга сөрергә кирәк…

Бу көнелсез уйлары губернатор аның озак билэр иде микән, ярый әле секретаре кереп, чираттагы киңәшмәгә чакырылганнарның приемныйда җыелып бетүен хәбәр итте.

– Чакырыгыз! – диде Буйновский, йөзенә эшлекле төс чыгарып.

Керделәр, утырыштылар.

– Йә, губернаның бюджетын тулыландыру, планны үтәү, үтәү генә түгел арттырып үтәү турында кемнәрдә нинди тәкъдимнәр бар? Ул сынаулы карашын берәм-берәм ярдәмчеләренә йөгертеп чыкты. Алары утырган урыннарына сеңә биргәндәй булдылар.

– Нәрсә, налог җыю идарәсеннән башлыйкмы?

Бу вазыйфаны күптән түгел биләгән купшы бичә урыныннан сикереп торды.

– Халыктан налогны эффектлырак, күбрәк сыдыру... җыю өстендә көне-төне эшлибез инде, Аристарх Федорович.

Буйновскийның кашлары җимерелде.

– Көне-төне эшләвегез турында әкият кирәкми миңа, Сарматова, конкрет тәкъдимнәр кирәк. Түрә тагы бер мәртәбә киңәшмәдә утыручыларны кырыс карашы белән барлап алды.

– Бу башкаларга да кагыла. Конкрет тәкъдимнәр!

Сарматованың ап-ак йөзе бурлат төсенә керде.

Конкрет тәкъдим дә бар, Аристарх Федорович. Безнең Кудеяр губернасының табигате искиткеч бай, матур. Ул елгалары, ул күлләре, ул урманнары, ул саф һавасы!..

– Син нәрсә, Сарматова, шул саф һаваны сулаган өчен налог кертергә чамалыйсыңмы?

– Саф һава өчен генә түгел, Аристарх Федорович. Табигать байлыкларын файдаланган өчен. Һавасын да суласыннар, суын да керсеннәр, җиләк-җимешен, гөмбәсен дә җыйсыннар, тик бөтенләй бушка түгел...

– Ярар, – диде губернатор, йөзенә елмаю чыгарып. – Налогның кеше башына күләме, җыю тәртибе, халык арасында аңлату эшләре алып бару турында бар фикерләрегезне туплап миңа керерсез. Бу эштән гәзит, радио, телевидение хезмәткәрләре дә читтә калмасын. Югыйсә, алар тырнак астыннан чүп эзләүдән бушамыйлар. Төп упор табигатьне пычранудан саклау, җыелган акчаларны аны чүпчардан азат итүгә тотыну булырга тиеш. Җәмәгатьчелек башлангычын да онытырга ярамый. Зарланып-сыкранып түләмәсеннәр, бу башлангычны хуплап-шатланып каршы алсыннар...



– Ә сез? – дип губернатор ГИБДД түрәсе Бүдәнәев ягына күз ташлады. Казнадан күпме акча чыгарып камералар алдык, уңайлы урыннарга урнаштырдык. Штрафларыгызның ни саны, ни күләме...

Кара тут йөзле Бүдәнәев урыныннан яй гына кузгалды.

– Штрафларның саны да, күләме дә артып бара да ул.

– Миңа артып баруы турында әкиятегез кирәкми, Бүдәнәев. Бермә-бер арттырырга кирәк. Югыйсә, правила дорожного движения-ларегезне кругом нарушают. Раз нарушают, пусть платят! Губернабызда күпме шахси машина бар әле?

– Миллионга якын инде, Аристарх Федорович.

– Иң бәләкәй штрафыгыз ничә тәңкә?

– Биш йөз сум, за превышение скорости.

– Һәр бер автолюбителегез берәр генә мәртәбә түләсә дә, биш йөз миллион. Штрафын бер меңгә чаклы күтәрсәң – миллиард! Ә башка төр штрафлар?.. Деньги валяются на дороге, полковник Бүдәнәев, надо научиться только их подбирать.

– Штрафларын түләргә ашыкмаучылар байтак, Аристарх Федорович. Почта квитанция җибәрә, ә нарушительләргә до лампочки.

– А зачем колготиться с почтой, квитанциями? У вас ведь есть право содрать штрафы прямо с помощью судебных приставов. Из сберкнижек, из пенсии, наконец.

– Сберкнижкаларда бит, Аристарх Федорович, в основном, шул үк пенсионерларның «гробовой» дип аталган акчалары..

– «Гробовой»мы, «похоронный»мы – какое наше дело. Полковнику полиции таким сердобольным нельзя быть.

– Безнең тагы бер тәкъдимебез бар, Аристарх Федорович. Җәяүлеләргә дә штраф салырга кирәк. Нарушают ПДД сволочи! Они такие же участники дорожного движения. Урам аркылы теләсә кайдан чыгалар, тротуарга сыймый, урам буйлап йөриләр... Һәр нарушение өчен бишәр йөз сум! Шәһәребездә ярты миллион кеше яши, башка шәһәрләребездә күпме... Әйдә, нарушать итсеннәр дә түләсеннәр, нарушать итсеннәр дә түләсеннәр!

– Имчәк балалар белән, туксанга җиткән картлар дамыни? – дип сүз кыстырды Сарматова.

– Алары түләмәсә, башкалары да җитәрлек... Бюджетка керем моңа чаклы күз күрмәгән, колак ишетмәгән биеклекләргә күтәрелечәк, Аристарх Федорович.

– Туктале, Бүдәнәев, камераларың машиналарның номерларын төшереп ала, а как нарушения пешеходов фиксировать?

– Йөзләрен төшерәчәкбез.

– Шул чаклы кешеләрне ул камералар ничек танып бетәр соң, Бүдәнәев?

– Создадим банк данных на всех жителей области, Аристарх Федорович. Современные цифровые технологии...

– Тәкъдимең азагына хәтле уйлап бетелмәгән, Бүдәнәев. Поработай.

Өлкәнең торак-коммуналь министры Сатаняев губернатор дәшүен көтеп утырмады, үзе сикереп торды.

Без инде, Аристарх Федорович, коммуналь түләүләрне югары чигенә чаклы җиткердек. Башка ресурс калмады. Тик барыбер оригиналь тәкъдимебез юк түгел. Бер төрле халык, аларны «бомжлар» дип атарга күнеккәнбез, чүп-чар контейнерларын даими куллана. Ягъни дә мәсәлән шуларда чокынып, яшәү чыганагы таба. Ә нишләп әле алар контейнерларда бушка чокыналар? Түләп файдалансыннар. Өлкәдә ун меңнән артык контейнер, предприятиеләр ябыла, бомжлар саны артканнан-артып бара...

Сатаняев артыгын әйтеп ташлаганын аңлап, телен тешләде. Губернаторның тагы кашлары җимерелде.

– Бомжлар бу «налог»ны кесәләрендәге бетләре белән түләсеннәрме? Ә менә чүп чыгарган өчен түләүнең хакын бераз үстерергә мөмкин. Аңа предел юк. Өлкәдә җиде йөз меңләп гаилә, йөзәр тәңкә өстәсәң дә, күпме килеп чыга? Җитмеш миллионмы! Шуны уникегә тапкырласаң күпме була, великий математик?

Сатаняев уң кулының имән бармагын тешләгәндәй итте, бу сорауга җавап эзләп, карашын түшәмгә юнәлтте.

– Тәк, сигез... сигез йөз кырык миллион була, Аристарх Федорович.

– Вот! Өлкә бюджетын тулыландыра торган акча чүп-чар савытында да ята. Уйлагыз, әфәнделәр! Уйлагыз!.

## ШАТУЙ БУЕНДА

*Тормыш – тау, җәй күтәреләсең, тиз төшәсең.*

***Г. Монассан***

Фарук Йосыфовичның запаска чыкканына да ике ел тулып өченче ел китте. Кайсы берәүләр\ кебек Мәскәү Рублевкасында төпләнмәде, туган ягына кайтты. Кудеярда фатиры бар иде аның,



шәһәр читенең ямьлеләрдән ямьле бер урынында, Шатуй елгасы буенда, дача салып алды. Дача дигәне Монастыревның урта гасыр феодаллары замогы кебек эшләнгән сараеннан байтак калыша, налог идарәсе түрәсе Буйновскийның өч катлы мәһабәт вилласына да тиңләшә алмый, гади генә бер катлы агач йорт. Халал җефете Фәридә белән икесенә шул җитмимени? Мәскәүдәге улы белән Санкт-Петербургтагы кызы, гаиләләре белән кунакка кайтсалар, аларга да урын җитәрлек. Чит кыйтгалар, илләр буйлап йөрү туйдырган гаиләгә тагы нәрсә кирәк?!.

Менә әле, иртән күзләрен тырнап кына ачты да, иске трико элэктереп, кармагын тотып елга буена ашыкты. Фәридәсе коймагын пешереп, чәй табыны әзерләгәнче, ярты чиләк балык тотып та кайтыр. Менә сиңа төшкелеккә каен утын тәтене исе килеп торган уха. Төштән соң бераз йокы симертеп алыр да, кич җиткәч, помидорлары кызарып, кыярлары тәгәрәшеп яткан түтәлләрен сугарыр... Урыс бу халәтне «идиллия» дип атар иде, Фарук Йосыфович өчен, чыннан та, «Аты юк урамда, кайгы юк буранда» булып чыга шул. Уйлары шушы тәңгәлгә җиткән генә иде, кармакка инде кабам-кабам гына дигән чабакны куркытып (белек буе булыр, биллаһи!), телефоны шалтырады. Балыкчы хәтта сүгенә биреп куйды.

– Тыңлыйм...

– Фарук Йосыфович, сезне полковник Запеканкин борчый.

– Ә-ә-ә, исәнме, Антон Харитонович. Таң белән запастагы полковник кемгә кирәк булды? Берәр банан республикасы иминлегенә куркыныч янаймы әллә?

– Банан республикасы булса, төкереп тә бирмәс идек, иптәш полковник. Монда... икенче нәрсә. Кыскасы, сезне губернатор Буйновский чакырта... әй юк ла, килеп китүегезне үтенә.

Фарук Йосыфович бу төзәтүне ишетеп елмайды.

– Үтенгәч ни... – диде.

– Бер ун минуттан машинабыз барып җитәр.

– Минем үземнең дә машина бар да ул...

– Безнеке бит мигалкалы, «бөке»ләрдә зарыгып утырмас өчен.

– Әнисе,.– диде ир, кармагые чолан стенасына сөяп куеп. – Тиз генә киемемне алыштырыйм әле, хәзер миңа машина килеп җитә.

– Нинди машина инде ул таң белән. Коймагым өлгергән, чәй утыртам. Теге вакытларда тынгы белмәдең, хет хәзер покойда калдырсыннар иде.

– Ашыгыч шул, чәйне, кайткач, иркенләп, тәмләп эчәрбез.

Фәридә ханым иренә әллә көлеп, әллә мыскыллабрак карап торды. Хәер, ярым ялангач иренең төсе-кыяфәте карарлык та, сокланырлык та иде әле. Уртача буй, күкрәк, беләкләре тирәсендә мускуллары сәлпермәгән. Йөзгә чибәр дип әйтеп булмый, шулай да акыллы карашымы, тагы әллә нинди сыйфаты беләнме теләсә нинди хатынның игътибарын җәлеп итәрлек. Фәридәсе көнләшеп киткән чагында аның бу сыйфатларына төрттергәләгәне бар иде. Бигрәк тә яшьрәк чакларында.

– Әллә ни кызыгырлык җирең юк инде. Әнә кинодагы шпионнар... Җиденче санлы агент, Джеймс Бунд…

– И, әнисе, джеймс бундлар алар кинода гына бит. Мин – шпион, мин – шпион дип әллә кайдан кычкырып торалар. Чын разведчик тирә-ягындагы кешеләрдән бер нәрсә белән дә аерылырга тиеш түгел. Минем тамырларымда татар каны ага. Меңәр еллар буе Азия күчмә кабиләләренең дә, Европа илбасарларының да каның берләштергән татар каны. Европа илләренә барсам, мин европалы, Азия илләренә барсам, мин азият, хәтта гарәп илләрендә дә минe үз итәләр. Аңладыңмы?

Ничек аңламасын инде Фәридәсе? Бу төрттерешү дә бит яратышып кына тел чарлашу...

## «Секретная миссия»

*Кешенең бите бер, әмма битлекләре күп.*

***М. Н. Шевелев***

Буйновский Әюповны урыныннан торып, өстәлe артыннан чыгып, каршы алды, кул бирештеләр. Буйновский – озын, Әюпов аңардан бераз калыша. Буйновскийның борыны озын һәм кәкре. Әюповныкы төз, кыска. Күзләр бер-берсенә караштылар: төсләре уңа биргән яшел күзләр борчылыпмы, әллә хәвефләнепме, төсләрен югалтмаган каралары – аптырабрак, булса кирәк.

Ике полковник токәтмә өстәл артында урын алды. Губернатор Запеканкин кертеп бирелгән белешмәгә тагы бер мәртәбә күз ташлагандай итте. Әһә, …19…нче елда Бедряшево шәһәрендә туган, Ленинград университетының филология факультетын, Ленинград КГБ мәктәбен тәмамлаган. Әлеге ил башлыгы белән бер елларда тәмамлаган!!! Запеканкин бу җөмлә астына кызыл сызык сызган, ахырына өч өндәү билгесе чәпәгән. Бу нәрсә: хәвефләнүме, әллә, кирәк була калса, кем аша эш итәргә мөмкинлеге барлыгын белеп, шатлануымы?.. Төркия, Йемен, Египет, Венесуэла, Никарагуа илләрендә эшләгән. Төрек, татар, башкорт, казак һәм башка төрки телләрдән тыш, гарәп, испан, немец, инглиз, француз телләрен яхшы үзләштергән. Русиянең һәм башка байтак илләрнең дәүләт наградаларына лаек булган. Гаиләле, хатыны Фәридә Касыймовна белән ул һәм кыз үстергәннәр…

Шулай да Запеканкин молодец, дигән уй килде түрә башына. Болар бит барысы да әлегә сер булган белешмә. Тапкан, чокып чыгарган.

– Йә, Фарук Йосыфович, эшләр ничек? – дип башлады губернатор сүзне.

– Эшләр сездә ул, Аристарх Федорович, – дип елмайды кунак, ә безнеке – тогаш ял да ял.

– Батырга да ял кирәк, Фарук Йосыфович. Разведка эше, нелегаль тормыш, секрет информация туплау, качышлар, атышлар… туйдыргандыр да инде.

Әюпов кычкырып көлеп җибәрде.

– Күп белешмә туплагансыз минем хакта, Аристарх Федорович, ләкин хаталы белешмә. Чит илләрдә мин беркайчан да нелегаль халдә эшләмәдем, һәрвакыт Русия илчелекләре сафларында гына. Берәүдән дә качмадым, берәүгә дә атмадым. Гомумән, пистолеттан, автоматтан ату тәҗрибәм дә бары стрельбищеда гына…

– Качмаган, тотылып төрмәдә утырмаган, атмаган, шартлатмаган разведчик та буламыни ул?

– Шпионский киноларда булмый, ә тормышта була. Мин бит разведчик-аналитик. Вакыйгалар куера башлаган илгә җибәрәләр дә, анә шул куера башлаган вакыйгалар кайсы якка борылырын, ул борылыш кайда алып барып чыгарырын, безнең ил белән мөнәсәбәтләргә аның ничегрәк йогынты ясарын чамалап йөрим-йөрим дә, үзебезнең идарәга аналитик белешмә язам. Калганы башка службалар эше. Минем нәтиҗәләр чиккә тисә, данының бер өлеше миңа да эләгә…

– Шәп! – диде губернатор, нишләптер озын борынын сыпыра-сыпыра. – Сез әлеге моментта, Фарук Йосыфович, безгә иң кирәк кеше! Разведчик-аналитик!

– Туплаган тәҗрибәмнән файдаланып, якташларыма ниндидер файда китерә алсам, шат булачакмын. Югыйсә, гел чит илләр дә, чит илләр…

– Күпмедер дәрәҗәдә бер фикергә килдек, дип уйлыйм, Әюпов әфәнде. Сез бит әле тумышыгыз белән Бедряшеводан. Соңгы елларда анда булганыгыз бармы?

Моңа чаклы сүзгә кушылмый утырган Запеканкин да:

– Точно! Бедряшеводан, – дип хуҗа сүзен җөпләп куюны урынлы санады.

– Әйе, Бидрәш, яшьлегем шәһәре! – дип хисләргә бирелә бирел куйды губернатор кунагы. – Анкарада яшәдем, Каирда булдым, Багдадта булдым, Латин Америкасы илләрен аркылы-буй йөреп чыктым, кызганычка каршы әнием вафат булганнан бирле бик күп еллар Бидрәштә була алганым юк. Алтын Урда заманнарыннан калган уникаль шәһәр. Урысы, татары, башкорты, казагы, нугае бергә укмашып яшәгән кала…

Хәзер инде Буйновский җилкәсен тырнауга күчте.

– Менә шул уникаль шәһәргә барып, яшьлегегез хатирәләренә бирелеп, безнең өчен дә кайсы бер эшләр башкарып кайту мөмкинлеге бар, Әюпов әфәнде. Бурыч итеп йөкләтергә хакыбыз юк, однако,попросить, наверное, можем. Тем более сез җирле халыкның яшәешен, аның телен, гореф-гадәтләрен яхшы беләсез…

– Нинди эш?

– Аналитик эш инде, үзегезгә якын булган аналитик эш, иптәш полковник. Соңгы көннәрдә шәһәрнең уникальлеге, аның борынгылыгы, күп милләтлелеге белән генә түгел, башка нәрсәләр белән дә аерылып тора, дисәм инде… Ачыктан-ачык әйтәм, әгәр бу «уникальлелек» Мәскәүгә барып ирешсә, полковник Запеканкин белән безгә монда несдобровать!

Губернатор сузган кәгазьне Фарук Йосыфович кызыксынып кулына алды. «КПСС-ның Кудеяр өлкә комитеты беренче секретаре иптәш Буйновскийга…» Аннары аптырап өлкә түрәсенә карады.

– Укыгыз, укыгыз..

– «КПСС-ның 26-нчы съезды карарларын үти барып, КПСС Генеральный секретаре, халык-ара коммунистик хәрәкәтнең җитәкчесе, тынычлык өчен арымый-талмый көрәшүче Леонид Ильич Брежневның күрсәтмәләренә таянып, Бидрәш районы малчылары хөкүмәткә ит сату планын…

Әюпов бу юлы аптыраулы карашын коллегасына юнәлтте.

– Бу нинди тарихи документ? Кайсы музейдан таптыгыз аны? Укуы кызык һәм күңелле, әлбәттә,.



– Тарихи документ кына булса икән? – Бу сүзләр губернатор белән ФСБ түрәсе авызыннан бер юлы яңгырады. – Сез аның кул-тамгасына һәм язылу датасына игътибар итегез.

– «КПССның Бидрәш шәһәре комитетының беренче секретаре Гапсатаров. 20 июль 2019 ел». – Бу нәрсә, иптәш әфәнделәр?

Губернатор авыр көрсенде.

– Без дә «нәрсә?» дибез дә ул. Бу гына да түгел, анда тагы да нинди анлаешсыз вакыйгалар булып ятуы колагыбызга килеп чалына. Мәскәүдәге кайсы берәүләрнең дә колагына барып чалынса, ни эшләрбез? Шуңа күрә шау-шу күтәрәсебез килми. Шым гына анда барырга, обстановканы өйрәнергә, бу кризистан… – Губернатор уйланып торасы-итте. – Әйе, әйе кризистан чыгу юлларын билгеләргә. Сез, Фарук Йосыфович, разведчик-аналитик, моны, тагы бер мәртәбә кабатлыйм, шау-шу күтәрми генә моны булдыра аласыз. Ягъни дә, сез безнең илче,-бу – сезнең секретный миссиягыз булыр.

– Илче?.. Никарагуада илчелектә эшләдем, Гваделупада илче булдым, туган шәһәрем Бидрәшкә губернатор илчесе булып кайтырым төшемә генә дә кереп чыкканы юк иде, ләбаса!

– Ничего, ничего, Фарук Йосыфович, бу бит вакытлыча гына. Сезнең телдә «Временно поверенный» дип атала, булса кирәк.

Запеканкин түрәсенә сокланып карады. Акыллы!

– Ә миссияны оештыру вәкаләтләрен мин үз өстемә алам, Аристарх Федорович.

– Миңа ышаныч күрсәтүегез өчен рәхмәт, Аристарх Федорович.

Запеканкин хәйләкәр елмайды.

– Минем әзер легендам, хәтта документларым да бар. Бүгеннән сез, Фарук Йосыфович тышкы разведка полковнигы түгел, фольклор җыючы галим…

– Бәй, теге кинодагы Шурик кебекмени? – дип аның сүзен бүлдерде Фарук Йосыфович – Тостлар, әкиятләр, анекдотлар…

– Шурик ул недоучка-студент кына, ә сез – кандидат филологических наук!.. – дип көлеп җибәрде Запеканкин. – Безнең бурыч – сезнең иминлегезне тәэмин итү!

– Үз гомеремдә коралланып, сак астында йөрмәдем. Бидрәшкә барып җитәргә, Аллага шөкер, машинам бар.

Запеканкин Әюповка мыскыллабрак карады.

– Нинди машина? Роллс-Ройсмыни?

–Андый ук түгел, «Мерседес» кына.

– Менә монысы бернигә дә ярамый инде, полковник. Кандидат науклар «Мерседес»тә фарсит итми.

– Ә нәрсәдә йөри?

– «Жигули»-копейкада.

– Әюповка ирексездән коллегасы белән килешергә туры килде.

– Беләсеңме, безнең гаражда андый машина бар. Шуңа утырып китәрсез.

– Адым саен ватылып изаланыргамы?

– Ватылмас. И мы не лыком шиты, коллега. Аның тышы гына «Копейка», эчендә капоттан сикереп чыгардай двигатель.

– Сезгә зур ышаныч белдерәбез, Фарук Йосыфович. Ышанычыбызны акларсыз дип уйлыйбыз, – дип елмайды губернатор, озын борынының очын кашый-кашый. – Ситуацияны өйрәнеп, медиклар сүзе белән әйткәндә, диагноз куеп, дәвалау чарасын билгеләргә күпме вакыт кирәк булыр, дип уйлыйсыз?

Фарук Йосыфович уйланып торгандай итте. Туган шәһәренә кайту форсаты тигән икән, «өч көн» дип кенә әйтә алмый бит инде ул.

– Бер атна вакыт тамам гына булып калыр, Аристарх Федорович, – диде ул, йөзенә җитди төс чыгарып. Хәер, аның киләсе килә иде. Кызык, «ситуация өйрәнергә», «анализ ясарга», «нәтиҗә чыгарырга» ул бит дөнья буйлап йөзде. Ә бүген туган шәһәре Бидрош... Килделе-киттеле, тик күкеленә һичшиксез якын шәһәре. Интернет сүзләре белән әйткәндә: «Город областного подчинения на юге Кудеярской области, центр одноименного района, население – 60 тыс. жителей, промышленность – спиртзавод, сахарный завод, кирпичный завод, мукомольный комбинат.., сельское хозяйство – зерновые культуры, подсолнечник, сахарная свекла, животноводство. Город известен с раннего средневековья, как один из пунктов торговли на караванном пути. Родина поэта-просветителя средневековья Башира Бидряши».

Әйе, шагыйрь-мәгърифәтче Бәшир Бидрәши турында да хәбәрдар иде ул. Тик хәбәрдар гына... Чөнки аның иҗатын заманында, дини шагыйрь, суфый шагыйрь дип, санга сугу булмады, мәктәптә өйрәнмәделәр. Хәер, өйрәнүчесе дә, өйрәтүче дә булмагандыр да инде. Көнчыгыш халыкларына билгеле булган бер төрле шигырьләрен борынгы татар телендә иҗат иткән булса, икенчеләрен гарәп яки фарсы телендә язган бит ул. Бу телләрне яхшы



үзләштергән Фарук Йосыфович менә хәзер аларны укыр да, хәзерге татар теленә тәрҗемә итә дә алыр иде. Бу турыда уйланганы бар аның. Үзе, Фәридәсе, якыннары өчен генә булса да шигырь язу тәҗрибәсе дә юк түгел.

Моңа чаклы байтак еллар туган шәһәрен кайтып күрә алмаганы өчен Фарук Йосыфовичның үзенә дә оят. Анда туганнары калмады да ул калмаулыкка, тик бергә үскән иптәшләре барысы да таралышып бетмәгәннәрдер әле. Сыйныфташы, күзе төшкән тәүге кызы Зөбәйдә анда яши. Аерылмас дусты Сәлим, аның әтисе Габделбәр, тагы әллә кемнәр...

–Тәк, бүген – вторник, киләсе понедельникта мин сезне көтәм. Аңа чаклы... аңа чаклы көн дә минем белән бәйләнешкә чыгып торуыгызны үтенәм. Антон Харитонович, – Губернатор әңгәмәгә ничек кысылырга белми утырган иминлек сакчысына кырыс карашын ташлады, – Сезнең бурыч – миңа илче белән туры бәйләнеш тәэмин итү.

Анысы, әзерлеген белдереп, урыныннан калкып куйды.

Губернатордан чыккач, Запеканкин Әюповка әлеге гаҗәеп машинаның серен дә ачты.

Элекке губернатор Монастырев халык күзенә гади булып күренер өчен эшләтеп алган икән дә, кайчагында шәһәр буйлап йөреп килә икән. Имеш, күрегез губернатор була торып, «Копейка»да йөри.

– Хәтерлисездер, Фарук Йосыфович, заманында Ельцин шулай кыланып маташа иде. Завод эшчеләре белән очрашуга «Чайка»сында бара да, бер тукталыш калгач, трамвайга күчеп утыра. Имеш, вәт Мәскәү горкомының беренче секретаре, Политбюро әгъзалыгына кандидат трамвайда йөри. Әйтерсең, халык монастыревлар белән ельциннарның нинди виллаларда, дачаларда ничек көн иткәннәрен күрми?!. – ФСБ полковнигы хилаф сүз сөйләп ташлаганын капыл гына аңлап алды да, авызын йомды.

Фарук Йосыфович көлеп җибәрде.

– Нигә, Монастыревыгыз ул машинасын Испаниягә алып китмәде мени?

– Анда кем күзенә төтен очырырга? Киресенчә, бар халыкка үзен олигарх-миллиардер итеп танытырга кирәк иң... Хәзер мин сезне өегезгә аткарам. Кичкә табан анда «Копейка»гызны да алып барып тапшырырлар. Сезнең исемгә эшләнгән бар кирәкле документлар, губернатор белән бәйләнешкә чыгар өчен телефон да бардачогында булыр. Корал кирәкми, дисез инде?

– Юк, именной пистолетымны да сейфтан чыгарганым булмады.

– Бурыч шул инде: анда пыскып яткан утны зур янгынга әйләндермәү, Кудеяр губернасы эчендәге чүпне тышка чыгармау. Мин сезгә боерык бирә дип уйлый күрмәгез, зинһар, бу губернаторның үтенече генә.

## Кудеяр – Бидрәш юлы

*Юл газабы – гүр газабы.*

***Татар халкы мәкале***

Әйе, юл газабы – гүр газабы, дип юкка гына әйтеп калдырмаган борынгы бабаларыбыз. Хәзерге юлда, «текә» машинада нинди газап булырга мөмкин, дип көләр укучыбыз. Әгәр дә ул, ягъни дә мәгәлән, Башкортстан, йә булмаса Татарстан чикләрендә генә йөреп яткан бөндә булса. Кудеярдан Бирдәшкә чаклы өч йөз чакрым, әлеге икс җөмһүрият юлларыннан байтак борынгырак юл. Меңәр еллар буе дөя карваннары таптаган атаклы «Ефәк юлы»ның бер тармагы. Таңнан торып сәфәргә чыккан мосафирны бер нәрсә аптыратты. Әллә, чынлап та, һаман дөя эзләрен саклап калганмы ул. Йөз метр ара үтә дә – түмгәк, тагы шул чаклы ара үткәч – тирән чокыр. Каршылыкларны урый торгач, куллары арый, уяусызлыгын югалтса, машинасы йә очып китәрдәй булып сикерә, йә чокырга тап булып, борыны белән җирне «сөзә». Юлы шулай булса да, хәрәкәт зур. Ил халкы ярлы яши, диләр. Ярлы яшәсә берсеннән-берсе «текә» машиналарда йөрмәс иделәр әле. Алар бу юлда йөреп өйрәнгән, Фарук Йосыфовичны «вжжт»лап узалар да китәләр, узалар да китәләр. Аңа игътибар итми узып китсәләр бер хәл, юк, машинасына да, аның хуҗасына да мыскыллы карап ташлап узып китәләр. Кара джипта утырган берсе хәтта аңа карап чигәсенә бармагын төртеп мыскыллы ишарә ясады. Икенчесе, шук малайдай, телен чыгарып ыржайды. Шулай инде, кара джипта түгел, төсе кызылдан җирәнгә торып калган «Жигули»да юлга чыксаң, үзеңә карата нинди хөрмәт өмет итәргә мөмкин? Хәтта син полковник булсаң да... Полковник булмагаен, генерал бул, эшкә ашкан адәм «Копейка»да йөрми ул. Мәскәүнең бер полковник кияве Захарченко кебек, долларларын КАМАЗга төяп йөртә...



Степной атлы шәһәргә житәрәк юл шомарды. Монда күптән түгел ремонт ясап үткәннәр икән. Үтүен үткәннәр дә ул, кояш кызуында суынып өлгермәгән асфальтта машиналар ярылып яткан эз сала да башлаган. Шулай да Фарук Йосыфович тизлеген шәбәйтте, әлеге аңа тел күрсәтеп киткән джип хуҗасын куып житте. Тегеләр моңа тагы тел күрсәтте. Житди полковникның шаян малайлыгы өскә калкып чыкты. Ул үз чиратында әлеге сөмсезгә тел күрсәтте, аннары җиңел генә итеп аны узып киткән иде, анысы чәмләнеп җирән «Копейка» артыннан куа башлады. Менә «Копейка» тизлеге йөз иллегә күтәрелде, йөз алтмыш, йөз җитмеш... Спидометр угы икс йөзне күрсәткән мәлдә, джип артта торып калды. Бу хәл, мөгаен, сөмсез юлчыга әлеге сәер мажара турында баш ватарга, аптырап иптәшләренә сөйләргә зур сәбәп булгандыр.

Запеканкин алдамаган, дигән фикергә килде, Фарук Йосыфович. Тизлеген кимәтә төште, «молодец дәл-дәл!» дип учларын уып алды. Хәзер инде карашын юл чокыр – чакырыннан аерып, тирәякка күз ташларга да форсат таба алды. Көн эсселәнеп бара. Күз күреме басуларда көнбагыш чәчкә ата. Матур! Җир кешесенә бу матурлык,чынлап та, матурлык кына булып күренә микән? Әллә аның күңелендә шомлы уйлар да уятамы? Фарук Йосыфович җир кешесе түгел. Ләкин ул да бит мәктәп дәреслекләреннән трехпольная система, семипольная системаларны исендә яхшы калдырган. Хәтта дача яны бакчасында кыяр-помидорларын, чөгендер-кишерләрен елдан-ел җир алмаштырып үстерергә тырыша. Ә бу басуларда? Билгеле кагыйдәне бозуның сәбәбе – крестьянның наданлыгында түгел, ашлык белән көнбагыш хакы арасындагы зур аермада. Бодай чәчсәң, аны хөкүмәткә арзанга сатып, орлык, ягулык хакын да каплый алмыйсың, көнбагыш бераз булса да төшем китерә. Ә еллар буе бер генә культура үстерелгән басу нинди хәлгә киләчәк?..

Бер, җәй көненең матурлыгына сокланып, бер, күңелсезрәк уйларга бирелеп бара торгач, Фарук Йосыфович уяулыгын югалтып ташлаган икән. Алда, машинасын юл читендәге ялгыз тирәк ышыгына яшереп куеп, бер кулына тизлек үлчәү приборы тоткан, икенчесе белән бертуктаусыз аклы-каралы таягын болгап торган ГИБДД хезмәткәре күренде. Фарук Йосыфович хәтта тизлеген туксанга төшерергә дә өлгерә алмады, юл сакчысы таягы аңа туктарга кушты.

– Юл-патруль службасы өлкән лейтенанты Степанкин, – дип ачык машина тәрәзәсенә үрелде офицер. – Документларыгыз, водитель әфәнде.

Әйе, полковник, тизлеген арттырып, юл йөрү кагыйдәсен бозды. Тик юлда чебен урынына кайнашкан башкалар да, туксан белән җилмитәр ич. Тик ГИБДДшниклар текә машина хуҗасына бәйләнүнең булырдай нәтиҗәсе турында яхшы беләләр. Андый машинада берәр зур түрә китеп барса? Шуның өчен андыйларга игътибар да итми өлкән лейтенант та, машина эчендә утырган сержанты да. Өлкәне водительгә мыскыллы карап, аның бардачоктан документларын чыгаруын көтә. Кайсы бер иптәшләренең киңәше белән правасы эченә алдан ук меңлек салып куйган иде инде Фарук Йосыфович. Протоколлар төзеп, өлкән лейтенантның вәгазьләрен тыңлап утырырга вакыты юк аның.

Өлкән лейтенант җентекләп техпаспортны, страховка кәгазен өйрәнгән булды. Праваны ачты.Фарук Йосыфович теге меңлекнең ничек юл сакчысы кесәсенә төшеп ятуын аңгармый да калды. Оста фокусчы!

– Нишләп юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозасыз, Әюпов әфәнде? Тизлегегезне тиешенннән алтмыш километрга арттырдыгыз бит. Сезгә зур штраф яный. Кайда юл тотасыз?

– Бидрәшкә, командировкага, – диде Фарук Йосыфович, каушабрак. Нишләптер, – Мин – телче галим, фольклор җыярга… – дип тә өстәде.

– Олигарх-миллиардер түгел икәнсезне күрәбез, – дип елмайды юл сакчысы. Мыскыллы карашы белән «Жигули»ны барлап чыккандай булды. – Бер юлга протокол төзеп тормыйбыз, кисәтәбез генә..

Көн кызганнан кызды, юлчының тамагы кипте, ашказаны да үзенең барлыгын сиздерә башлады. Тамак ялгап алырга кирәк иде. «Кафе «Версаль» дип язылган иде юл читендә урын алган тыйнак кына бина башына. Аскарак «Веелком!» дип тә өстәп куйганнар. Франциянең Версалендә булгаларга туры килде Фарук Йосыфовичка. Искиткеч матур шәһәр! Тик Франция корольләре төзегәнен Рәсәйдә җәһәннәм тишегендә урнашкан забегаловкага ни катнашы бар икән? Нишләп чакыруны француз телендә түгел, инглизчәләп язмаганнар. Бәлки, ул яклардан килеп чыккан чит ил адәмнәре ачкандыр бу туклану йортын? Алай дисәң, бинадан читтәрәк, бер зур мыскылы тау кешесе шашлык өтеп маташа.

Юл читендә ике фура, бер «Газель». Тамак ялгарга туктаган юлчылар. Фарук Йосыфович эчкә үтте, түрдәрәк торган бер өстәл артында урын алды, бина эченә күз йөгертеп чыкты. Капыл гына



Ильф белән Петров герое Остап Бендерның: «Нет, это не Рио-Жанейро», – дигән сүзләре исенә төште. Ул елмайды: «Юк, бу Версаль түгел!»

Ул арада аның янына официантка, яшь кенә кыз бала, йөгереп килеп житте. Бер дә чит ил мадмуазеленә охшамаган, күренеп тора, күрше авыл кызы.

– Безнең «Версаль»гә веелком, юлчы әфәнде.

Җиңелчә акцентына караганда, татар кызы. Юлчы аңа үзебезгә дәшүне хуп күрде.

– Мине ни белән сыйларга җыенасыз, туташ?

«Әфәнде», «туташ»ларга кыз да бик күнегеп бетмәгән булып чыкты.

– Минем исемем Энисә, абый кеше.

– Минеке – Фарук, Фарук бабай, дисәң дә була.

– Нинди бабай буласыз ди инде? Абый дип әйтсәм дә таман гына булыр…

– Ярар танышлык сезнең белән, сылу кыз. Нәрсәләр тәкъдим итәсез соң?

– Барысы да менюда инде, абый.

– Әһә. Салат по-французски, котлеты версальские, картошка-фри, суши «Нагасаки», шашлык «Д'Артаньян», вак беляш по-татарски, чай по-китайски… О-ho-ho!.. Ярар, мин роспотребнадзор вәкиле түгел, хуҗагызга штраф чәпәргә җыенмыйм, алдамый гына әйт әле, Энисә, менә бу версаль котлетын пешекчегез нәрсәдән кыздырды?

– И, абый, әйтсәм, әйткәнемне хуҗам белеп калса, мине эштән куачак бит ул!

– Мин бит хуҗагызга бәйләнмәячәкмен.

– Әйтсәм әйтим инде, кичә бездә бер адәм туган көн мәҗлесе үткәрде. Өстәлдә яртылаш ашалмый калган котлетлардан әвеләргә кушты аны хуҗабыз. Котлеты гына шундый булса икән, аның бит башка блюдолары да кичәге калдык-постык. Үтеп-сүтеп торган шоферларга ярый ул, ди хуҗабыз.

– Шашлыгы да калдык-постыктанмыни? Әллә теге грузиныгыз эт-песиләрнең дә башына җитәме?

– Аныкы калдык-постык түгел дә ул, күрше фермерның үләргә җыенган дуңгызларын арзанга сатып алабыз… Абый, сез миңа ошадыгыз, безнең «иностранный» блюдоларны ашый күрмәгез, эчегез китеп интеганырсыз.

– Моннан ач чыгып китиммени соң?

Төмле итеп, сөтләп, чәй ясап китерәм, вак бәлеш. Анысын сыйфатлы итеп әнием пешерә...

Фарук Йосыфовичның тамагы ялганды, кәефе яхшыра бирде: машинасын кузгалткач, хәтта жырлап та жибәрде.

Юллар, юллар! Авыр булса булсын,
Тик соңгысы гына булмасын...

Әлеге гаҗәп кафегә сугылырга туры килүсәә юлын кәефсез дәвам итәдми ич инде ул. Әгәр дә иксез-чиксез Рәсәй киңлекләрендә ул бердән-бер шундый туклану пункты булса икән?

Юлчылар эшләп йөргән участокка килеп җиткәч, күпләр мисалында, Фарук Йосыфовичка да машинасын туктатырга туры килде. Сакка куелган юлчы ишарәсенә буйсынып эшләп йөргән техниканы уратып тар гына калдырылган юлдан каршыга килгән машиналар агыла иде. Күз күреме чаклы тезелгән колонна үтәчәк тә үтәчәк әле. Ул арада уң якта да шул чаклы карван хасил булды. Озак кына торырга туры киләчәген чамалап, Фарук Йосыфович төннәрен язып алырга машинасыннан чыкты, әлеге регулировщик эргәсенә килде.

– Йә, туган, эшләр ничек бара? – дип сүз дәште әлеге кызыл әләмчек тотып торган юл эшчесенә.

Аны да болай тору ялкыткан иде, булса кирәк. Хәтта сүз кушканга шатланып та киткәндәй булды.

– Этсәң бара, этмәсәң – юк инде ул, абый кеше.

– Даими вазыйфаң шушы буламыни инде?

– Юк ла, башкалар белән бергә асфальт җәям. Монда алмашлап торабыз. – Ул сары жилетының ычкынган төймәсен эләктереп куйды, машиналар агымына күз салды. Кирәккәнгә түгел, тәртип өчен генә таягын болгап алды.

– Эшегез җиңел түгел инде?

Ир авыр сулады.

– Эссе асфальт... Кояш утыз – утыз биш градуска җиткереп кыздырганда...

– Хет түлиләрме соң?

– Чамалап кына инде, абый кеше. Безгә җитәрлек түләсәләр, үзләренә аз кала ич! Ә алар, – Юл эшчесе билгесез бер юнәлешкә ишарә ясады. – Зарплатасын да җимереп алалар, болай да...

Фарук Йосыфович ни турыда сүз барганын аңгарса да:

– Нәрсәсе «болай да», дип сорап куйды.



– Соң, үзегез белмәгән ни эш бар? Асфальт егерме биш сантиметр калынлыкта җәелергә тиеш, аны ун-унбишкә хәтле киметәләр. Юлның киңлеге илле метр, ул нишләптер утызга гына торып кала. Бу «экономия»дән, башка мутлыклардан тупланган бар байлык кемнәр кесәсенә тама, дисез. Без бит барысын да күреп, белеп торабыз. Язын юл төзү идарәсе түрәсе хатыны, балалары белән Яңа Зеландиягә ялга киткән иде, үзләре юкта өен талап чыкканнар. Бер нәрсәсенә дә тимәгәннәр дип әйтерлек, сейфындагы акчасын гына сыпырганнар. Илле мең доллар һәм тагы безнең акча белән биш миллион ярым, диләр. Полициягә гариза язып тормады... Анысы аңлашыла инде.

Аңлашыла... Фарук Йосыфович гади юл эшчесенең хәбәрдарлыгына аптырады. Барысын да белә, барысына да түзә. Хәер, түзми нишләсен. Эшсез калып, гаиләсен ач утыртасы килми бит аның.

Ул әлеге юл эшчесенә теләктәшлек белдергәндәй булды. Тугыз миллион акчасын югалтып, «ыһ»та итмәгән түрәне жәлләүне артык санады. Ул арада уң як колоннага да кузгалыр чират җиткән иде. Тагын әлегә яңа асфальт җәелмәгән чокырлы-чакырлы юл башланды. Бу юлда кайсы берүләр өчен күпме хәзинә ятканлыгын чамаларга гына кала, дип уйлады ул.

Күңелсез уйларыннан аны юлының соңгы ноктасына килеп җитүе коткарды. Юл читендәге күрсәткечкә «Бедряшево – 2 км» дип язылган иде. Бихисап машиналар, бу күрсәткечне санга сукмый, юлларын дәвам иттеләр, Фарук Йосыфович «дөл-дөл»ен шәһәргә таба борды.

## БИДРӘШ КАПКАСЫ ТӨБЕНДӘ

*Этлеккә тәһарәт кирәкми.*

***Татар халкы мәкале***

Урта гасыр шәһәрләренең каравыл каланчасыдай биек бина. Тик ул таштан төзелмәгән, беренче каты кирпечтән, икенчесе – тотап пыяладан, әйтерсең гаҗәеп зур аквариум. Кит балыгы сыяр «аквариум»ның эчендә суы юк та, балыгы юк, аның каравы камуфляж кигән хәрбиеме, әллә полицейскийымы бар, кыска автоматын аркасына табарак шылдырган да, зур бинокльны ике кулы белән тотып, тирә-юньне күзәтә. Капкага килеп җиткән җирән «Копей-

каһны күрү белән, ул аста, ябык шлагбаум эргәсендә торган иптәшенә ниндидер ишарә ясады. Аньсы да шундый ук камуфляждан, бронебойный жилеттан, кулында автомат… Әлеге бина янында бетон блоклардан өелгән дот сыманрак корылма да бар, ике амбразурасы ниндидер гыйфритнең ике күзедәй, үтеп баручыга акаеп карый.

Фарук Йосыфович бу галәмәткә аптырап өлгерәлмәде, үзеннән-үзе өркеп туктаган машинасы алдына теге икәү килеп басты. Автомат көбәкләрен машина эчендәге адәмгә юналттеләр. Фарук Йосыфович ирексездән кулларын күтәреп машинасыннан чыкты.

– Стоп, гражданин! Куда прешь? – дип кырыс тавышы белән җикерде ана хезмәткәрләрнең кыска буйлы, сипкелле йөзлесе.

Какча озыны иптәшенең соравын куатләгәндәй:

– Бидрәштә ни йомышыгыз бар? – дигән соравын куйды. – Колымагагызның багажнигән ачыгыз әле, корал, наркотиклар, тыелган әдәбият юкмы?

– Хөрмәтле ГИБДД хезмәткәрләре!.. – дип башлаган иде сүзен Фарук Йосыфович, аны тупас итеп Сипкелле бүлдерде.

– Какой-такой «ГИБДД»? Придумывают черт его знает что…

Ана Озыны кушылды.

– Гражданин башыңны күтәреп әнә тегендә өскә кара әле.

Чыннан та, теге биек бинаның өстендә ат башыдай хәрефләр белән ГАИ дип язылган иде. Бу бит кайчаннандыр торып калган ГАИ посты булып чыкты, дигән уй килде Фарук Йосыфович башына. Әйе, үткән гасырның туксанынчы елларында, Рәсәйдә бандитлык котырып чәчкә атканда, һәр шәһәр читендә барлыкка килгән иде шушындый каравыл каланчалары, дотлар, амбразуралар... Тормыш бераз рәтләнә төшкәч, әлеге пост биналарын, дошманга коралды каршылык күрсәтү корылмаларын йә сүтеп алдылар, йә өлгеррәк малтабарлар аларны кафегәме, кибеткәме әйләндерделәр. Ә монда ниндидер гыйльлә белән сакланып калган.

– Хөрмәтле, ГАИ хезмәткәрләре, Рәсәй полициясе офицерлары, сездән гафу үтенәм… – дип янадан башлаган иде ул сүзен, Сипкелле кычкырып ук җибәрде.

– Смотри, Альтаф, этот гражданин оскорбляет же нас. Советских милиционеров называет полицейскими. С Вас штраф, гражданин! Пятьсот… нет, нет, тысяча рублей.

Фарук Йосыфовичка кесәсеннән меңлек чыгарып Сипкелле кулына тоттырырга туры килде.



Кырыс милиционерларның күңелләре йомшарды, йөзләренә елмаю билгесе чыкты. Әлтәф дигәне инде юлчыга кешечә мөрәҗәгать итте.

– Документларыгызны күрсәтегез инде, абзый. Кем буласыз? Безнең шәһәргә нинди максат белән килдегез?

– Документлар тәртиптә, туганнар. Мин галим – филолог, кандидат филологических наук. Командировкам сезнең уникаль шәһәрдә фольклор җыю белән бәйле.

– Что такое фольклор? – дип аптырап сорады Сипкелле. Собирать фольклор – это что, искать, собирать какой-то клад что ли?..

Фарук Йосыфович елмайды, Әлтәф кычкырып көлеп җибәрде.

– Фольклор – народное устное творчество, надан. Анекдоты, тосты, частушки, сказки… Теге «Кавказская пленница»дагы Шурик сымак. Шурик әлеге шәһәргә ишәккә атланып килә, хәзер абзый кешенең «Копейка»сы да шуңардан әллә ни ары китмәгән инде. Шулай бит абзый?

– Аньсы шулай инде, – дигән булды Фарук Йосыфович, – юаш кына тавышы белән.

– Про нас, гаишников-взяточников, сколько анекдотов придумано. Телисезме, берсен сөйләп тә күрсәтәм, абзый. Язып алыгыз…

– Минем кесәмдә диктофон кабызылган, диде Фарук Йосыфович. Үзе шунда ук хата җибәрүен аңлады

– Диктофон?! – Сипкелленең сипкелләре бүртенә бирде. – Слушай Альтаф, этот чудак, кажется хочет продать нас начальству!

– Юк, юк, дускайлар, дөрес аңламадыгыз. Мин – шпион түгел, гади кандидат наук кына…

Әлтәф иптәшенең хафалануына каршы төшге.

– Юк. Абзый шпионга охшамаган, үзебезнең кебек простой кеше. Ярар, сөйләп күрсәтим, булмаса. Бер яшь гаишник түрәсенә кергән ди. «Иптәш майор, хәлем мактанырлык түгел бит әле. Өйләндем, балабыз туды, йорт та салырга җыенам. Бераз гына булса да матди ярдәм күрсәтә алмассыз микән?» «Матди ярдәм күрсәтәлмыйм, лейтенант, – дигән ул. Иелеп өстәл астыннан «40 км» дигән язулы юл знагы чыгарган да, – Мә, юлның кайсы участогы уңайлы, шунда кагып куй да…» – дип яшь гаишникның кулына тоттырган, имеш.

Күңелле әңгәмәне Сипкелле дәвам итәргә уйлады.

– Беләсезме, безнең бер коллега ришвәтне ничек алган. Кагыйдә бозмаган юлчыны туктаткан, двигателен, багажнигын ачтырып ка-

раган. Анда тәртип, ди. Правасын, техпаспортын, страховка кәгазен тикшергән, Бәйләнер нәрсә юк. Машина таза, номерлары ачык күренә, сигнализация эшли. Бу мескен уйланып торган да, машина тирәли биеп киткән. Лезгинканы. Өч мәртәбә урап чыккач, юлчыга: «Түлә?» дигән.

«Ни өчен түлим, иптәш кече лейтенант? Минем барысы да тәртиптә бит». «Мин сиңа бушка биедеммени, концерт өчен түлә», - дигән, имеш.

Хәзер инде көлү өч авыздан чыгып яңгырады. Көлү тынгач, Фарук Йосыфович тегеләргә берәм-берәм карап чыкты. Бронижилетлар киеп, автоматлар белән коралланган булсалар да, болай апару егетләр икән дә.

– Алай үз житешсезлекләрегездән үзегез көлә белгәч, бик бозылып өлгермәгәнсез икән әле, егетләр.

– Абзый, безнең эш ул көлсәң дә, еласаң да, дигәндәй... Ришвәткә килгәндә. Күп водительләр бит протокол төзетеп, штрафны рәсми оформлять итүдән үзләре баш тарта. Бердән, вакыты, икенчедән – кәнителе. Аннары, үзегез белмәгән ни эш бар? ГАИбыз түрәсенең дә бит әле учы кычытып кына тора. Майорныкы кычыткач, өстәге полковникныкының да кычытмый булмыйдыр? Алар, сезнең кебек, «Копейка» да йөрмиләр. Берсенекеннән берсенең машинасы «текә»рәк, өйләре биегрәк. Без сезнең мәрхәмәткә ышанып утырмыйбыз, алар – безнекенә. Көндәлек задание бирергә дә тартынмыйлар...

– Ә хөкүмәт бюджетына керми калган, тиеннәр, сумнар? – дип елмайды Фарук Йосыфович ирексездән.

– Ул турыда безне менә шушында, һич кирәкмәгән постка, куйганнар, безне тиеннәргә эшләргә мәҗбүр иткәннәр уйласын инде, абзый. Әйткәндәй, акиятләр, мәзәкләр ишетәсегез килсә, минем әнинең күршесендә генә Габделбәр атлы бабай яши. Ул сөйли инде... Имеш, атом бомбасы шартлаткан җирдә дә булган, шушы көннәрдә генә әллә нинди гарәсәт тә күргән... Себер урамы, 27-нче йорт.

– Габделбәр бабай?! – Фарук Йосыфовичның күз алдыннан бер генә секунд эчендә әллә кайда еракта калган балачагы йөгереп узды.

Бу нинди көн булды соң әле, дип үз алдына сөйләнде Фарук Йосыфович, кузгалып китеп шәһәр урамына барып кергәч. Официантка кыз бала да, юл төзүче дә, ГАИ егетләре дә тартынып та тормадылар, аңа үзләренең эч серләрен, түрәләре белән мөнәсәбәтләрен чиштеләр дә куйдылар. Күрәсең, утырып китеп



барган машинасы иске, кыяфәте, киеменең гадилеге сәбәп булгандыр монда... Разведчик – разведчик инде!.. Аларны бит укыганда ук бер нәрсәгә инандырдылар. Күзләре очкын чәчеп торган мәһәбәт сынлы разведчиклар – алар шпионский киноларда гына. Чын разведчик кыяфәте, үзен-үзе тотышы белән урамдагы меңмең кешеләр арасында берни белән дә аерылып торырга тиеш түгел. Җир шарының әллә кайсы кыйтгаларында, әллә нинди илләрендә йөргәндә дә ул шушы хакыйкатькә тугры булып калды. Менә хәзер туган шәһәрендә дә үзен талантлы разведчик-аналитик итеп түгел, урта кул галим-филолог итеп таныта алса, алдына куелган бурычын үтәренә өмете бар.

Җәй уртасының озын бу көне кичкелеккә авышты...

## Габделбәр йортында

*Яшьләр алга карый, картлар артын барлый.*

***Татар халкы мәкале***

Карт ишек алдында иде. Дөресрәге, мунча түбәсендә. Баскыч куеп менгән дә, мунчасының кыйшайган морҗасын урынына утыртып маташа. Әһә, шушы эше белән мавыгып, капкасы төбенә килеп туктаган машина тавышын ишетмәде дә. Янкапкасын ачып йортка килеп кергән ят ирне дә күрмәде. Фарук Йосыфович хуҗага сәлам бирер алдыннан ишек алдына күз йөгертеп чыкты. Күпме еллар үткән, күпме сулар аккан, ә монда бер нәрсә дә үзгәрмәгәндәй тоелды аңа. Бәлкем, ул чакларда ук иске тоелган йортын хуҗа кечерәйтелмәгән дә, зурайтылмаганмыйдыр. Ләкин ул кечерәйтелмәгән дә, зурайтылмаганмый булмагандыр. Түбәсе генә кызылга буялган калайга да, шул кәлеш яңартылган. Түбәсе генә кызылга буялган калайгын түгел, хәзерге заманның яшел профиле. Мал-туар абзары урынында, келәте урынында, мунчасы урынында... Сыйныфташы Сәлим белән абзар чормасындагы печән өстендә аунаганнарын исенә төшерде Фарук Йосыфович. Габделбәр абзый, ике малайны атына утыртып, печән чабып алып кайтырга алып барганын да онытмаган иде әле...

Дөнья кысырык, кешеләр бер очрашмаса, көтмәгәндә бер очраша. Ә кечкенә Бидрәш шәһәре тоташ дөньядан күпкә кысрыграк. Фарук Йосыфович әллә ничәмә еллар кайтып күрмәгән балачагы шәһәренә кайтсын да, ничек инде сыйныфташының әтисе Габделбәрне очратмасын? Җитмәсә, аны бит монда шәһәр капкасы сак-

чысы Әлтәф атлы егет өйрәтеп җибәрде. Имеш, әкиятләрне, бәетләрне, мәкальләрне Бидрәштә Габделбәрдән дә күп белгән кеше юк.

Карт мунча морҗасын турайтып утырткан иде инде. Төшәргә җыенды, капкасы ягына күз ташлады.

– Әссәламмәгаләйкем, Габделбәр абзый, – дип сәлам бирде аңа төпкәрәк үтәргә кыймый торган ир.

Карт баскычтан төште, мангаена кулын куеп әлеге ирне танырга чамалады. Капыл гына танымаса да, аның янына килеп ике кулын сузды.

– Вәгаләйкем әссәлам, туган, кем дип әйтим үзеңне…

– Фарук булам мин, абзый. Улың Сәлимнең сыйныфташы. Хәтерлисеңме, кечкенә малайлар чагыбызда шушы ишек алдын бер итеп уйный торган идек. Гашүрә әби пешергән коймакларның тәме һаман авызымнан киткәне юк.

Карт кунакка аптырап карап торды.

– Бәй, укытучы Нәсимә Хәлләфовнаның улы буласыңмыни инде син?

– Әйе, әнием шәһәребезнең беренче мәктәбендә башлангыч сыйныфлар укытучысы иде.

– Бик тә яхшы укытучы иде шул әниең. Кызганыч, бу дөньяны иртә калдырып китте. Әтиеңне дә хәтерлим, Фарук улым.

– Аны мин хәтерләмим дә инде, Габделбәр абзый. Ул фаҗигале һәлак булганда, миңа ике генә яшь булган.

– Шулай шул, бик тә җегәрле шофер иде. Эше белән кабаланып китеп барганда, машинасының тормозы сафтан чыгып, яр астына тәгәрәде бит. Алай техникасын карамый йөри торган егет түгел иде дә соң. Алдынгы водительнең бер көнчел дошманы, тормоз шлангысын кисеп куйган икән дип сөйләнүчеләр дә булды. Тик бу фаразны тикшереп тормадылар, үлемне «несчастный случай»га ябыштырдылар.

Карт бер генә минутка тынып калды. Икесенең дә йөзеннән кара шәүлә йөгереп үткәндәй булды.

– Без яшәгән барак моннан ерак түгел иде бит, Габделбәр абзый?

– Ерак түгел. Себер урамы Карл Маркс урамы белән кисешкән чатта иде. Хәзер юк инде ул, аның урынына биш катлы йорт салып куйдылар.

– Ә Сәлим?.. – дип икеләнә биреп кенә сорады Фарук Йосыфович балалык дустына бер-бер хәл булган булса, уңайсыз хәлдә калырын чамалап.



– Сәлим исән-сау, гаиләсе белән Камчаткада яши. Еш кайтып йөри алмый, дүрт-биш елга бер генә. Менә Гашүрә әбиегезнең вафат булуы гына бәкалгә сукты. Дөньяны берүзәмә күтәргә туры килә. Нишлисең, үлгән артыннан үлеп булмый, туган… – Габделбәр карт капыл гына хәтерләүләреннән арынгандай булды. – Туктале, Фарук улым, без нәрсәгә монда басып торабыз? Өйгә керик, мин хәзер аш салып җибәрәм. Иркенләп утырып сөйләшик. Кирәк икән, мунча да өлгертермен.

– Габделбәр абзый, әле мин сиңа үтеп барышлай гына сугылдым. Монда командировкага килгән идем. Кунакханәгә барып урнашыйм, ял итим. Иртәгә күрешеп иркенләп сөйләшербез…

Картның йөзе бозыла бирде.

– Син нәрсә, Фарук улым? Туган шәһәреңә, сине балачагыңда үз улы кебек яраткан Габделбәр абзыеңа кайттыңмы, әллә Герман илендә йөрисеңме? Өйгә керик, бер йокы бүлмәм буш тора, ошатсаң шунда урнашырсың да, иртәгәдән йомышларыңны үти башларсың. Капканы ачам, керт «дел-дел»еңне монда.

Фарук Йосыфович уйланып торасы итте. Дөресен әйткәндә, Габделбәр өе әлеге «секретный миссия»сен үтәр өчен бик уңайлы вариант иде. Кунакханәдә губерна үзәгеннән килгән сәяхәтчегә шунда ук игътибар итәчәкләр. Аның турында мәгълумат шунда ук шәһәр җитәкчелегенә дә, полиция бүлегенә дә билгеле булачак. Ә монда ул – яшьлек эзләрен сагынып кайткан гади кунак. Кайчандыр «Коммунизм юлы» исеме йөрткән совхозның пенсиядәге малчысы Габделбәр Шәмигулла улы Сәйфелмөлековның кунагы.

– Уңайсыз бит әле, Габделбәр абзый. Сине кысрыклау булмасмы?

– Бер өйдә мин берүзем, Фарук улым. Акылдан язар чакларым була. Ярый әле Хөршидә күрше бар, ике арадагы сукмакны суытмый. Әйткәндәй, әнә үзе дә кереп килә. Капка төбендә машинаңны күргәндер дә, кызыксынуы кабарып чыккандыр. – Әйдүк, әйдүк, Хөршидә күрше. Бәхетләнең кунагы ишле була ди. Бик вакытлы кердең. Тиз генә чормага мен дә, бер каклаган казны алып төшеп казанга сал. Менә бу кунак шәһәребездән күп еллар элек китеп юкка чыккан Фарук абзаң булыр. Хәер, юкка чыкмаган икән дә…

Илле яшьләр чамасындагы тулы гәүдәле сөйкемле бичә Фарук Йосыфовичка ике кулын сузды, тыйнак кына итеп сәлам бирде. Ир аңа сынаулы итеп карады, танығандай да булды.

– Фарук абзыйны мин хәтерлим. Нәсимә апаның улы, бе башлангыч мәктәпне тәмамлаганда, унынчыны бетеп, Ленинградка укырга китте.

– Ә мин сезнең улыгыз Әлтәф белән таныштым, – дип елмайды Фарук Йосыфович. – Шәһәр капкасы сагында постта. Погонлы булса да, кырыс түгел, итагатьле егет...

– Ярар инде, тик аллә кайчан онытылып беткән каравыл каланчалары да, куркыныч киемнәре, автоматлары... Әйтерсең, сугыш башланып тора.

Кунак машинасын йортка кертеп урнаштырды. Алмаш киемен, бичәсе юлга салып җибәргән колбаса-консерва фәләнен, үзе пешергән вак бәлеш пирожкиларын өйгә кертте. «Виски» дә Габделбәр абзый табынында артык булмас әле, дип, анысын да әләктерде. Ул арада уңган күрше казны пешереп алды, ботарлады, шулпасына токмач салып, аны яшел суган, укроп белән тәмләтеп, тәлинкәләргә бүлде. Өстәлгә корт утыртырга да онытмады. Ә Габделбар карт мунчасына су тутырып, ут төртеп кергән иде инде. Һай! Безнең халыкның кунакчыллыгы!..

– Йә, Фарук энем, очрашу хөрмәтенә берне күтәрәбезме? – диде карт, өстәл янына утырышкач. – Хөршидә кызым, син моңа каршы килмәссеңме?

– Анау хәтле еллар очрашмый яшә-яшә дә, бер көн очраш. Билгеле, каршы килмим, үзем дә бер генә булса да уртлыйм әле, – дип көлеп җибәрде күрше хатын.

– Йәле, минем төнен куганнан авыз итеп карыйк...

Кунак үзе чыгарган эчемлеккә ишарә ясады.

– Бәлки, менә бу шотланд вискиеннән авыз итәрбез?

– Анысына да чират җитәр, Фарук улым, ә хәзергә әйдә күтәрик. Мине карт дигәч тә, сиксән яшь ул нишләп карт булсын. – Ул кечкенә рюмкасын кунаклары белән чәкештереп, күтәреп куйды. – Әле мин!.. Әнә Теләкбирде служак мине өйләндерергә маташа. Ачуга тисәгез, өйләндем куйдым!..

Кунаклар да сыйдан баш тартмады. Рюмкаларын күтәрделәр дә кычкырып көлеп җибәрделәр.

Хөршидә кулларын чәбәкләп алды.

– Болай булса, гөрләтеп туй да ясыйсы бар икән әле! Анда Гашүрә түти дә риза булмый ятмас... Әйдә, хәзер каклаган каздан авыз итик инде.



...Хуҗа белән кунак мунча кереп чыкканда, караңгы төшкән иде инде. Күк йөзендә тулы ай, шәһәр өстендә тынлык хакимлек итә. Мунча алдындагы эскәмиягә утырып хәл алдылар, җәйге кичнең хозурлыгына сокланып, бер генә минутка тын калдылар. Тынлыкны Габделбәр карт бозды.

– Син дә чабынырга яратасың икән, Фарук улым...

– Ничек яратмыйсың инде үзебезнең «урыс мунчасын».

Габделбәр карт көлеп җибәрде.

– Бар нәрсәне урыска кайтарып калдыру бар шул бездә: «урыс кышы», «урыс каены», «урыс мунчасы»... Әле бит мин дә хәтерлим, мич эченә кереп юыналар иде. Ә безнең халык гомер-гомергә мунчалы булды.

Аның бу фикерен Фарук Йосыфович та әләктереп алды. Безгә ул мең еллар элек ислам дине белән көнчыгыштан килгән. Бетләп йөргән Европа дворяннары да, тәре походлары башлангач, төрекләрдән, гарәпләрдән күреп, мунча керергә өйрәнгәннәр.

– Бер кызык хәл искә төшеп китте әле, Фарук улым.

– Сөйлә соң, Габделбәр абзый. Кызык хәлләр – ул минем бүгенге шөгылем.

– Безнең түрәләр дә бит, бик баегач, берсеннән-берсе уздырып мунчалар сала башладылар. Ул юкә такта белән тышланган чабыну бүлмәсе, бассейны, ул сузылып ятыплап итү бүлмәсе, ул рәхәтләнеп утырып сыра чөмерү бүлмәсе, ул бильярд бүлмәсе... Азгынракларының хәтта фәхишәләр белән кети-мети уйнау өчен урын-җире дә була торган иде. Безнең директор Букреев та зур комплекс иҗатасының куаклар белән капланган бер почмагында шундый мунча төзетеп куйды. Әлеге мин санаган «уңайлыклар»ының барысы ук булмаса да, мунчасы шәп иде. Еш кына шәһәр түрәләренең йә берсен, йә икенчесен чакырып күңел ачалар иде.

Беркөн шулай мине чакырып ала бу.

– Габделбәр Шәмигуллович (йомышы төшкәч, исем-шәрифләремне дә менә шулай тулысы белән атый) ты, говорят, большой мастер по банным делам.

Мин әйтәм:

– Да, кое-что знаю, кое-что умею.

– Бүген мунчага зур кунаклар килә, – ди бу, – Икәү бергәләп шуларның күңелен күрергә иде бит. Рәхәтләндереп чабырга иде. Ризалаштым.

Түрә сорагач, аның үтенечен ничек кире кагасың.

– Алдан ук әйтеп куям, Кудеярдан килгән ике куйнак слабаклар булып чыктылар. Әссегә дә, имән себеркегә дә юньләп чыдый алмыйлар. Эштер-пештер генә чапкалап аларын ял бүлмәсенә аткардым да, үземнең түрәне чабырга җыендым. Миндекләремнең төрле сортлысы әзер. Аның күңелен түгел, рәхәтләнеп үземнең күңелне күрим әле! Башымда кун бүрек, кулларымда брезент бияләйләр, ал ягымда клеенка алъяпкыч. Миндекләрне эскәмиягә тезеп салдым. Атылган йолдызлардай шартлап күккә очып китәргә әзер ташларга ярты чүмеч су ташладым, аларның котырынып чәжләвы әзрәк кимегәч, тешкәч, сыра сирпедем. Колакларны куырырлык эсселеккә кушылып, мунча эченә мичтән яңа чыккан икмәк исе таралды. Ләүкәгә менеп кунаклаган Букреевның әле быел кояш күреп өлгермәгән ап-ак тәне яңа туган баланыкыдай алсуланды. Тәнендәге җирән сипкелләре кызарынып бүртенгәндәй булды.

Мин мунчаны яңгыратып тамагымны кырдым.

– Ну что, Антон Харитонович, начнем?

– Начнем, Габделбәр Шамигуллович, с богом, не торопясь.

– Изге эш башкарганда, кабаланырга ярамый инде ул, иптәш Букреев.

Тәү түрә тәнен юкә миндекне җиңелчә җилпелдәтеп барлап чыктым. Кыштыр-кыштыр, кыштыр-кыштыр. Аннары карлыган миндеге белән сыйпадым. Әйләп авыр артиллерияне эшкә куштым, каен себеркегә дә чират җитте. Шап-шап, шап-шап. Ләззәттән һушы китеп барган түрәм авызыннан өзек-өзек өннәр яңгырый башлады.

– Ай, ай, ай! Уй, уй, уй! Ах, ух! Их-х-х...

– Ә мин кызганнан кызам. Йөземнең кырысланауын, күзләремнең ачудан аларуын хәтта үзем дә сизәм. «Мәртәт! «Ах» та «ух» килеп яткан була бит әле! Әнә эшеңдә «ах» та «ух» килергә, халык алдындагы бурычларыңны үтәргә кирәк! Шап-шап, шап-шап...

– Әнә шулай, дядя Габделбәр, әнә шулай! Хәзер инде «дядя»га да әйләндем.

«Әнә шулай шул. Гел кәеф-сафа корып кына йөргәч, саз бакасы кебек симереп алдың, капкорсак! Ашаганың – бал да май. Бирән! Гуж! Ә эшчеләреңне юньләп хезмәт хакы түләми интектерәсең, ачлы-туклы яшәтәсең. Хәчтерүш! Иксплататор!»

– Мене бу төшне ныграк каезла!

«Каезлармын да! Каен себерке белән түгел, дуңгыз тиресеннән үрелгән, тозлы суда чылатылган чыбыркы белән ярырга кирәк синең ул төшеңне. Ул төшеңне дә, менә монысын да! Иллегә



җиткән, акыл кермәгән Күпме бичә-чәчәне бәхетсез иттең, уйнашчы! Мир үгезе! Сине шул эгъзаңнан асып куйсаң да жәл түгел...»

Аннары кулыма имән себерке алдым. Шап-шап. Гөп-гөп!

– Уй-уй-уй! Шәп, дядя Габделбәр, шәп!

«Шәп булыр шул, шәп булмый ни. Кесәң тулы акчаң. Хан сарайдай өең, дачаң, иномаркаң... Угры! Ришвәтче! Болай китәкләсәң, озаклама комплексыбызның каккан казыгы да калмас. Юк, сиңа дуңгыз тиресеннән үрелгән чыбыркы гына аз. Ришвәт акчасы санаган бармакларыңны ассыборын белән изгәләргә, гел тәнә сулга каерган аякларыңны тимер коршау белән богауларга, ашап туймас тамагыңа эрегән кургаш агызырга, йомшак кәнәфигә генә күнеккән арт саныңны 1891 елда чыккан винтовканың тутыккан шомполы белән каезларга кирәк!»

Түрә арт санына тутыккан шомпол ничегрәк тәэсир иде икән, әзер анда, дөп-дөп итеп, чыршы себерке төшә башлады. Бу – түрәне чабуның иң югары ноктасына җитүен аңлата иде. Ташка – су. Чаж! Очага – ялыс. Дөп-дөп! Чаж. Дөп-дөп!

– Ай-ай-ай! Уй-уй-уй! Ах-ух!.. Җитәр булмаса, Габделбәр дядя.

«Җитәр, имеш. Бу юлы, бәлки, җитәр. Киләчәктә «Тәмуг» атлы мунчада янасың, көясең бар әле, бәдбәхет!»

Түрәнең бар төшләрен тагы да йомшак кына юкә миндегем барлап үтте. Чөгендердәй кызарган тәненең әле һаман да әчетеп кычытып торган төшләренә талгын су сирпедем.

– Иллә дә чаба беләсең, дядя Габделбәр. Кайдан мондый осталык та, кайдан мондый чыдамлык?!.

– Чыдыйсың инде, башыңа төшкәч, – дигән булдым мин. – Кычынып йөргән башка түрәләрне дә алып килгәлә, иптәш Букреев. Чабармын мин аларны! Шундый итеп чабармын!..

Бу хикәят Фарук Йосыфовичка бик ошады. Әйе, ачулы халыкның ямсез түрәләрдән үч алуының, бәлки, йөзләп ысулы бардыр. Габделбәр карт ныкы шул ысулларның йөз дә беренчесе түгел микән?

Көлеп туйгач, ул картка сынап карап куйды. Тагы елмайды.

Ә карт кунагының елмаюына хәйләкәр елмаеп җавап бирде.

– Карале улым, Бидрәшкә хәлебезне белергә кайтуың бик мәслихәт эш. Тик кайтуыңның башка бер сәбәбе дә бардыр бит инде?

– Әйттем ич инде, Габделбәр абзый, командировка дип.

– Соң, командировканың да төрлесе була ич... Әллә димостагелар безнең шәһәр хуҗасыннан риза түгелләрме? Шуны иченнән алырга җибәрделәрме?

Фарук Йосыфович кычкырып көлеп җиберде.

– Габделбәр абзый, мин бит Кремльдә дә, губерна хакимиятендә дә эшләмим. Пенсиядә, телче галим. Халыкның авыз тел иҗаты белән кызыксынам, бәетләр, әкиятләр, мәзәкләр, табышмаклар җыям... Мена әлеге хикәятең дә миңа бик ошады. Көндәлемә салып куйдым. Күреп торасың ич, зур түрә булсам, хан заманында чыккан машинада йөрмәс идем әле...

Карт мәгънәле итеп тамагын кырды.

– Әкиятләр, дисең инде? Әйе, безнең дә әкиятләргә ышанган чаклар булды. Аларны Йосыф белән Нәсимә улы Фарук түгел, коммунистлар партиясе, аның башлыгы Никита Сергеевич Хрущев үзе сөйләгәч ни... Ышанмый нишлисең?.. 1980 елда, имеш, коммунизм төзеп бетәбез... Һәркемнән – хәленчә, һәркемгә – кирәгенчә, имеш... Кибеткә кердең дә, әнә шул кирәгенчәне бушлай алып чыктың... Йозаклар, бикләр юкка чыга... Милиция кирәкми... Судья, прокурорлар кирәкми...

Син, егет, әкият җыеп йөрим дип, бераз шыттырасың булса кирәк. Фарукның заманында әлеге ил башлыгы белән бергә укуы, аның зур кеше булып китүе турындагы имеш-мимешләр әледән-әле Бидрәшкә дә килеп җитеп тора иде. Карт икеләнми ни эшләсен?

– Ярый, Габделбәр абзый, кич бар, иртә бар, кереп йоклыйк, булмаса, – диде кунак җитди әңгәмәдән читләшеп.

## Төнге уйлар

*Йокысызлык – иҗат бишеге.*

***И. Н. Шевелев***

Юлда ничек кенә йончыган булмасын, Фарук Йосыфович бик озак йоклап китәлми ятты. Әйе, Фарукның, Фарук Әюповның Бидрәштән чыгып китүенә күпме еллар үтте. Ленинградта укыганда әнисен күмәргә кайткан иде. Оят, шуннан бирле кайтып, әтисе, әнисе каберендә булырга да туры килмәде. Әлеге «секретный миссиясе» чукынып китмимә, иртәгә үк зыяратка барырга, каберләрне тәртипкә китерергә, алар алдында баш иеп торырга...

Әлеге бурычын ничек үтәр? Мондагы гаҗәеп хәлләренең ничек очына чыгар? Аның бәетләр, әкиятләр җыеп йөрүенә теге искелек калдыклары ГАИшниклар ышанды да ул, Габделбар карт ышануын-ышанмавын белдермәде, җилкәсен тыфнап хәйләкәр елмайды гына. Күрәсең, запаска чыкканчы югары даирәләр арасында кайнавын монда ишетми булмаганнардыр? Габделбәр карт ышанмагач, урындагы власть вәкилләре аңа ничек ышанырга тиеш?

Югары даирәләргә килгәндә... Әйе, Ленинград университетендә әлеге ил башлыгы белән бер заманда укыдылар алар. Ил башлыгы – юрфакта, Фарук Йосыфович – филология факультетында. Дус булдылар дип әйтергә, Фарук Йосыфовичның теле әйләнмәс, әмма яхшы таныш лар иде. Дзюдо секциясенә дә бергә йөрделәр. Соңрак аларның юллары КГБ мәктәбендә укыганда кисеште. Аны тәмамлагач, төрле структурада хезмәт итсәләр дә, бер-берсенең җилкәсенә төшкән сынаулар, уңышлары турында хәбәрдәр булдылар.

Урыста бит: «...оказаться в нужное время, на нужном месте, с нужными людьми», – дигән әйтем бар. Булачак ил башлыгы, ул вакытларда КГБ подполковнигы, кирәкле кешеләр йогынтысына электе. Ә полковник Әюпов әллә кайдагы банан республика-ларының мәнфәгатьләрен кайгыртып читтә йөреп калды. Юк, ул бер вакытта да карьерист булмады, ил кимәлендәге вазыйфа турында хыялланып яшәмәде. Кайчандыр ил башлыгы белән бергә укыган, хезмәт иткән байтаклар хәзер аның тирәсен сырып алдылар, зур-зур вазыйфаларга ирештеләр. Теләсә, бәлки, Фарук Йосыфович та татлы ләвештән өлешсез калмаган булыр иде. Ләкин андый уй аның башына кереп кенә дә чыкмады. Ул әлеге көндәге тормышыннан, җәмгыятьтә үзе тоткан урыныннан риза. Полковник! Отставкадагы түгел, запастагы полковник, бик кирәк булып китсә, чакырып алырларына ышанып яши.

Әлеге миссиясе – губернатор үтенече генә. Тик аны да җиренә җиткереп башкарырга кирәклегенә иманы камил. Тоң – фактлар, аннары – анализ, нәтиҗә. Ясалган анализдан чыгып – тәкъдимнәр... Фактларның төүгесе – Бидрәш шәһәрено «милиция», «ГАИ» тәшенчәләренең, әлеге каравыл каланчасының, баштан-аяк коралланган милиционерларның әйләнеп кайтуы. Боларны ни белән аңлатырга? Иң кызыгы – алар үзгәрешләргә аптырамыйлар, үзләрен берни булмагандай тоталар...

## Бидрәш иртәсе

*Ишәк башы булган дәләдә атның токымы корый.*

***Билгесез автор***

Ул байка-бик күп шәһәрләренең иртәләреннән берние белән дә аерылмый. Дәүләт учреждениеләрендә ыгы-зыгы башлана. Өлкән

хезмәткәрләр кабинетларына кереп урыннарына утыралар. Кичә килгән гәзитне алып, караштырып чыккан булалар, дөньядагы хәлләргә «Вәт бит!», «Кара син аны!», «Эш рәте белмәгән наданнар!» кебегрәк бәһалар биргән булалар. Аннары җилкәләрен тырнапмы, эчләрен сыйпапмы бераз уйланып утыралар. Соңыннанрак, әле бит эшләргә дә кирәклеген исләренә төшереп, теләр-теләмәс кенә өстәлләрендә җыелып киткән кәгазьләргә тотыналар. Ә яшьрәк хезмәткәрләр, зур эш башкарган кыяфәт белән, кул куелмаган, кул куеласы, кул куелган кәгазьләрне бер кабинеттан икенчесенә ташыйлар.

Фарук Йосыфович та Габделбәр өендә кунак булып кына ятмады, эшлисе «эшләре» барлыгын исенә төшерде. Аңа ФСБ түрәсе биргән «туры элемтә» телефонын алып сынап карарга булды. Чынлап та туры элемтә микәнни? Хәзер бит мэрлар, губернаторлар, министрлар үзләрен бик эре тоталар. Аларга берәү дә турыдан-туры шалтырата алмый. Әле секретарьләре аша бәйләнешкә керә алсаң да бик хуш. Чынлап та, шалтыратуы белән, Буйновский аңа җавап бирерме?

Бирде! Трубкада губернаторның торбадан чыккандай калын тавышы яңгырады.

– Хәерле иртә, Фарук Йосыфович. Тыңлыйм.

– Хәерле иртә, Аристарх Федорович. Килдем. Күрдем…

– Нәрсә? Александр Македонский кебек, «җиңдем» дип тә әйтергә чамалыйсыңмы?

– Юк. Бидрәш урынында, дип кенә әйтергә телим. Җир дә тетрәмәгән, вулкан да атмаган, дәүләт перевороты да булмаган. Ләкин кайсы бер сәерлекләр юк түгел.Мондагы хәлләр турында соңрак, бераз өйрәнә биргәч, шалтыратырмын әле.

– Ярар, Фарук Йосыфович, рәхмәт. Мин сезгә ышанам…

…Бидрәш шәһәренең милиция бүлеге начальнигы подполковник Самохваловның да әллә нинди бөек эшләр башкарырга нияте юк иде. Күңелен бер генә нәрсә борчый. Полковник чинына торышлы дәрәҗәне инде өч ел бит, һаман погонына тагы бер йолдыз өстәгәннәре юк. Шулай ук отставкага подполковник кына булып китәрмикәнни? Кәефе булмагач, ул бүген хезмәткәрләрен җыеп оперативка үткәрмәде. Тик аны тынычлыкта калдыра булаларлармы соң?!

Кабинет хуҗасын «дерт»ләтеп ишек шаку тавышы ишетелде. Ул арада ачыла биргән ишектә ГАИ начальнигы майор Клептомановның тузган чәчле башы күренде.



– Керергә мөмкинме, иптәш подполковник?

– Кер, утыр, – диде Самохвалов коры гына. – Йә, сөйләп җибәр, Захар Миронович, безнең бандитизмга каршы көрәш өлкәсендә күргән чараларыбыз юл хәрәкәте чә чикләрендә үзләрен аклыймы?

– Акламаганы кая ул, Илья Максимович! Кичә, мәсәлән, шәһәрдән илле машина чыккан. Багажниклары буш ди, наркотик кебек зелье табылмаган. Утыз биш машина кергән, кәефле груз алып кермәгәннәр. Тик…

– Нәрсә «тик»? – Түрә майорга сөзеп карады.

– Сезгә килүемнең сәбәбе дә шул иде, Илья Максимович. Шәһәребезгә керүчеләрнең берсе минем егетләр күңеленә шик уяткан. Документлары тәртиптә ди: Әюпов Фарук Йосыфович, 19… года рождения, житель города Кудеяр… Оружие, наркотики, запрещенная литература в машине не обнаружено.

– Нәрсәсе тәртиптә түгел диләр соң?

– Цель приезда в наш город. Имеш, кандидат филологических наук. Бидрәшкә приехал собирать какое-то устное народное творчество: анекдоты, сказки, частушки. На вид человек серьезный, машина несерьезная – «Копейка», но и цель приезда настораживает. Анекдотлар, частушкилар гына булса, бер хәл… Губернатор – яңа себерке. Ә новая метла, үзегез беләсез, по-новому метет. Эшкә керешкәненең икенче көнендә үк: «Будем беспощадно бороться с казнокрадством, взяточничеством, коррупцией!..» – дип лаф орды бит. Әйтерсең аңа хәтле урламаганнар да, аннан соң урламаячаклар. Әйтерсең аңа башка эшләр беткән? Әнә, шәһәрнең тәзеклэндер, агачлар утыртсыннар, фонтаннар ясаттыр, юллар төзеттер, күпкатлы йортларның подъездларын тәртипкә китертсен… «Казнокрадство», имеш! Беләсеңме, Илья Максимович, Иван Грозный заманында түбәкләргә хакимнәр куйганда, аларга беринидә эш хакы да билгеләмәгәннәр. Үз көннәрен үзләре күрергә тиеш булганнар. Урыс илендә ул шулай булган, хәзер дә шулай булачак. Әнә, Монастырев нишләде? Урлады-урлады да чыгып тайды. Ә без монда… за копейки сыдырылабыз…



Самохвалов хезмәттәшенең бу ялкынлы монологын көлемсерәп тыңлады.

– Йә, «за копейки сыдырылучы», темага якынрак кил.

– Соң, әлеге Әюпов атлы адәм өстән җибәрелгән шымчы түгел микән? «Әкиятләр» җыяр-җыяр да тегендә алып кайтып доложит. Аннан шәһәр мэры Гапсатаров – тю-тю. Эшеннән алып кына тынычлансалар бер хәл, утыртып ук куйсалар?.. – Майор уң кулының имән бармагын түшәмгә төбәде. Подполковникның карашы әлеге бармак ишарәсе артыннан иярде. – Аннары синең белән минем нишләтерләр?..

– Гостиницаның кайсы бүлмәсендә урнашты, белдегезме соң? Уяулыгыбызны югалтып, теге «Ревизор»дагы халгә калмыйк, иптәш майор.

– Нинди «Ревизор» ул тагын?

– Әллә Пушкин, әллә Лермонтов язган кәмит инде. Безне Кудәярда җыйганда театрга культпоход оештырган иделәр.

– Гостиницага урнашмаган шул ул сомнительный бәндә. Заманында простой малчы булса да, үзенең вольный карашлары белән тендкүбезгә тигән Габделбәр атлы картка төшкән. Габделбәр Сәйфелмөлеков. Әйткәндәй, сөер кунак безнең шәһәрдә туып үскән икән дә, картны балачагыннан ук белә икән…

Самохвалов уйланып утырасы итте.

– Әюпов Фарук Йосыфович, дисең инде? Минем губерна эчке эшләр идарәсендә дуслар бар, ул адәмнең чынында кем булуы турында срочно белешмә кирәк булыр... Аннары Гапсатаровны кисәтергә... Ә син, майор, алдыңны артыңны җыештыр. Урман төбәгеннән кайтарткан йөз кубометр агачны оформить иттеңме әле?

– Юк.

– Немедленно берәр чит кешегә оформить ит. Малайларыңны кисәт, бу көннәрдә водительләрне стригать итми торсыннар. Теге адәмнән алып өлгермәгәннәрме?

– Кызганычка каршы, Коновал дигәне мең тәңкәсен сыпырып өлгергән шул.

– Немедленно , гафу үтенеп, ул меңлекне кире кайтарсын.

Майор аптырап подполковнигына карады:

– Ничек, Илья Максимович, бездә ришвәтне добровольно кире кайтару практикасы юк та инде.

– Булмаса… булыр, – диде түрә кырыс итеп. – Икс ышанычлы егетеңне куй, бер генә минутка да караусыз калдырмасыннар. Карале аны, бронижилетлар киеп, автоматлар тагып йөри күрмәсеннәр! Синекеләрдән булыр!.. Пусть попроще одеваются. Как городские



бездельники-шалопаи. Через каждые два часа будешь докладывать мне. Понял?

– Понял, товарищ подполковник!..

## ГАБДЕЛБӘР КАРТ ӘКИЯТЛӘРЕ

*Тормыш китабын графоманнар яза.*

***Г. Е. Малкин***

Иртәнге чәйне эчкәч, Фарук Йосыфович белән Габделбәр карт утырып гәпләшеп алдылар.

– Йә, Габделбәр абзый, – диде Фарук Йосыфович көлемсерәп – Сине Бидрәшнең иң оста әкиятчесе, дип атадылар. Берәр әкиятеңне сөйли башлыйсыңмы инде?

Картның йөзенә ризасызлык билгесе чыкты.

– Кем атады, кайчан атады?

– Кичә инде, күршең Хәршидә улы Әлтәф атлы егет.

– Һи, хәерсез! Ул малка малайларга үткән тормышны ничек кенә искә алсаң да – әкият. Сталин чоры – әкият, немецләр белән сугышта әллә без җиңгәнбез, әллә америкалылар – аңысын да юньләп белмиләр, әкият итеп карыйлар. Сугыш чорында без мескеннәр күргән нужалар, алабута, балтырган, черек бәрәңге белән тукылануларыбыз, колхозда бригадир дәфтәренә сызылыр таяк исәбенә эшләвебез – әкият. Солдат хезмәтендә булуымны әлек сөйләргә мөмкин түгел иде, хәзер инде, дәүләт серләрен барысын сатып бетергәч, атом бомбасын шартлаткан төбәктә хезмәт итүемне сөйләгән идем, ышанырсыңмы-юкмы: «Нигә, японнар илендә, Хиросима атлы шәһәрдә, хезмәт иттеңмени, бабай?» – дип аптырый теге Коновал атлы урыс. Югыйсә, бөтенләй надан да түгел ич, милиция мәктәбен тәмамлаган сержант… Нәрсәгә укыталардыр ул яшьләрне?..

Габделбәр карт башлаган сүзен очлый алмый калды, тормозын сызгыртып килеп туктаган машина тавышы ишетелде, янкапка ачылып китте, анда әлеге «яшьләр» үзләре күренде. Дересрәге, Фарук Йосыфовичның кичәге танышлары: лейтенант Әлтәф Сәфәров белән сержант Максим Коновал.

– Хәерле иртә, Габделбәр бабай, Фарук абзый! – дип сәламләды утырган икәүне лейтенант. Аңа әкиямидә тыныч кына сөйләшеп утырган икәүне лейтенант. Аңа иптәше кушылды.

– Здоровенько булы, товарищи ветераны!

Габделбәр карт урыныннан торды, мәгънәле итеп тамагын кырды. – Таң тишеге белән өеңә полиция килсә, хәерле булыр микән бу иртә, әллә хәерсезме?

Әлтәфе кычкырып көлеп җибәрде, Максимының йөзе җыерылгандай булды.

– Бабай, сиңа ничә мәртәбә кабатларга мөмкин, полицейскийлар түгел без, милиционерлар…

– Әллә инде, диде Габделбәрт, җилкәсен тырпый биреп, – кичә генә полицай идегез, бүген янә милиция… Берәр йомышыгыз бардыр бит!

– Йомыш дип, йомыш та түгел инде… – Әлтәфе тотлыкты.

Аның сүзен Максимы дәвам итте.

– Мы хотели извиниться перед дорогим гостем нашего города товарищем Аюповым. Его тысяча рублей чисто случайно оказались в моем кармане.

– Әйе, әйе, очраклы рәвештә, – дип хуплады сержантның сүзләрен лейтенанты. – Без бит крохобор-взяточниклар түгел, совет милиционерлары. Акчагызны кире кайтарабыз, Фарук Йосыфович. Безгә үпкәли күрмәгез. Бидрәш милициясе турында начар уйлый күрмәгез. Безнең ГАИ түрәсе майор Клептоманов та, шәһәр милиция бүлеге начальнигы подполковник Самохвалов та намуслылардан намуслы офицерлар.



Фарук Йосыфович та, Габделбәр карт та берни әйтәлми калдылар, тегеләр чыгып та китте. Ә бу икәү тәү бер-берсенә караштылар, аннары кычкырып көлеп җибәрделәр.

– Бу ни булды, Габделбәр абзый?

– Әллә инде, Фарук энем? Мин дә аңламадым. Ни булса, шул булгандыр. Менә шушы хәл, мөгаен, беренче әкиятебез булыр инде. Башлар буталды: әллә полицайлар, әллә милицияләр – ахрысы, хәзер үзләре дә белмиләр.

– И, Габделбәр абзый, Габделбәр абзый, чынлап та әкият шул. Бер меңлек кәгазь минем кесәдән очып чыккан да, «чисто случайно» Максим атлы гаишник кесәсенә очып кергән. Ул, гафу үтенеп, шуны кайтарырга килгән. Ришвәтченең, гафу үтенеп, ришвәтен кире кайтаруы – әле моңа чаклы Русия тарихында булмаган нәрсә. Әгәр бөтен бурлар урлаган байлыкларын, бөтен ришвәтчеләр алган мил-



лионнарын, халыктан гафу үтенеп, кире кайтарсалар, илебез ничек баеп китәр иде…

– Адәм ышанмас хәбәрне чын булса да сөйләмә, диләр, Фарук энем. Бу хыял – тормышка ашмас нәрсә. Минем чираттагы әкиятемә ышанырсыңмы-юкмы, шулай да сөйләргә телем кычытып тора.

– Минем дә шуны тыңларга ике колагым тырпаеп тора.

– Ярый алайса… Бу хәл борын-борын заманда түгел, безнең көннәрдә, өч көн элек булды. Шәһәрдән утыз чакрымнар ераклыкта Төвеш атлы авыл бар. Халкы шул безнең Бидрәшнеке кебегрәк инде: тутарлары, башкорты, урысы, казагы бер-берсе белән аралашып, туганлашып яшиләр. Шунда торган казак дустым Теләкбирде белән заманында Ырынбур якларында бергә хезмәт иткән идек. Тоцкида-гы атом бомбасы мәхшәрен дә бергә татыдык. Шул чакырды мине кунакка, сарык суеп, бишбармак ашатырга. Тик максаты бишбармак белән сыйлау гына булмаган мәртәтнең, миңа күрше хатыны Фаягөлне димләү дә булган. Имеш, әбием үлгәнгә байтак булып киткән дә, миңа берүзем яшәве бик авыр икән, имеш, миңа аның күргәнеменнән дә кулайлы пар юк икән.

Фарук Йосыфович түземсезләнеп картны бүлдерде.

– Шуннан, димләдеме инде, казак дустың сиңа яшь кәләш? Аны син ошаттыңмы?

– Туктале, Фарук энем. Кәләш ничава да ул. Тик сүзем бит нәсиче гаҗәеп һәм куркыныч нәрсә турында… – Габделбәр карт, күзләрен бер ноктага төбәп, бераз дәшми утырды. Күрәсең, Төвеш авылында төнен-башыннан үткән хәлләрне тагы бер мәртәбә күз алдына китереп утыргандыр.

Аның сөйләвен Фарук Йосыфович бирелеп тыңлады. Хикәят тәмам булгач:

– Ул гарәсәт чынлап та Бидрәш өстендә котырдымы? – дип сорады.

– Шәһәрнең нәкъ өстендә инде, Фарук энем, үз күзләрем белән күрмәсәм, ышанмас идем. Билләһи, вулкан аткандыр да, шәһәребезне пыран-заран китереп юкка чыгаргандыр, дип уйладым. Заманында Куркуымнан хәтта аңымны да югалтып егылганмын. Заманында совхоз алдынгыларын Мәскәүгә алып барган иделәр. Третьяков картиналар музеена да алып керделәр. Әнә шунда Иванов атлы рәссамның «Пампийның соңгы көне» атлы картинасы һушымны алган иде. Вулкан атып, тоташ шәһәрне халкы белән бергә көл-күмер

астында калдырган. Бидрәш өстендәге күк йөзе тач әнә шул юкка чыккан Пампий өстендәге шомлы күк йөзенә охшаган иде.

– Бигрәк куркыныч булган икән! Монда аңынны югалту гына түгел…

– Әйе, әйе, куркудан җан тәслим кыларлык күренеш! Ярый әле теге дөньяга олакмаганмын. Кояш чыкканда, аңыма килдем.

– Хуҗаларыңның коты очкандыр инде?..

– Гаҗәбе шунда шул. Алар өчен, әйтерсең, берни булмаган. Йокы симерткәннәр, саташулы төшләр күргәннәр… Җитмәсә, Теләкбирде кордаш, хәзер Фаягөл күршене чакырып кертәм дә, сезгә никах укыйм, дип авызын ера. Никах кайгысы идемени әле анда? Тиз генә җыендым да кайтып киттем. Икенче гаҗәбе: кайтсам, шәһәр урынында. Халык әллә төш күргән, әллә саташкан, әмма берни белми йоклаган. Хәрширдә күршегә генә минем казлар тынгы бирмәгән.

Фарук Йосыфович көлемсерәде.

– Борын-борын заманда казлар Римне коткарган, диләр. Әллә безнең Бидрәшнедәме?..

Габделбәр карт куркыныч хәтирәләреннән арына бирде, булса кирәк. Горурланып, мыегын сыпырып куйды.

– Булса да булыр, минем казлар бит алар! Һәр әйткән сүземне аңлап торалар, каршы җавап бирәләр…

Шәһәрдәге ниндидер сәер үзгәрешләргә дә минем белән казларымнан башка игътибар иткән зат юк.

Иртән йорт хуҗасы тагарак тутырып салган болгауны сосып беткән казлар, картның шушы сүзләрен хуплагандай, каңгылдашып алдылар.

– Нинди үзгәрешләрне әйтәсең, Габделбәр абзый?

– Соң, үзең белмәгән ни бар, Фарук энем. Әлеге каравыл каланчасын чәйханәгә әйләндергәннәрене дә биш былтыр бит инде. Ә ул яңадан каравыл каланчасы булып утыра. Милицияне полиция дип атый башлаганнарына да күпме вакыт үткән. Ә бу кургаш солдатлар һаман милиция булып кыланалар. Ичмасам, тәртипләре бераз үзгәрсә икән?! Шул синең кулыңа китереп тапшырган ришвәтне искә алмаганда. Ә спиртзавод торбасы? Эшсез кукраеп торган манара яңадан төтен чыгара башлаган…

Фарук Йосыфович әлеге мәзәк хәлнең күңелсенең ерак почмагын кытыклап ятуының сәбәбен аңлады. «Келт» итеп килеп төште аның башына «Провал!» дигән уй. Күпме чит илләрдә эшләде, мондый



мәхшәргә калмады. Монда, Рәсәй башкаласыннан гына түгел, губернаң үзегеннән дә җәһәннәм тишегендә яткан Бидрәштә, төн чыкканчы аның берниндиг дә әкият җыючы түгеллеген фашлап өлгергәннәр… Кечкенә деталь – галәти ришвәт һәм аны меккен бер сержантның гафу үтенеп китереп тапшыруы. Көлсәң көл, еласаң ела!..

– Әйе, гаҗәп хәл шул, – дип картның сүзен куәтләп куйган булды Фарук Йосыфович.

– Гаҗәп хәл… Тик тагы да гаҗәбрәкләре дә бар бит әле аның. Әлеге Горбачев белән Ельцинның «реформа» атлы галәмәтләре башлангач, безнең мал симертү комплексы биш мең малы белән юкка чыгып, комплексның түрәсе Букреев та әллә кайда китеп олаккан иде. Карасам, мал абзарлары да урынында, бур Букреев та, берни булмагандай парторгына күрсәтмәләр биреп йөри.

– Әйе, – диде Фарук Йосыфович уйлана биреп, – Бу әкиятең, чыннап та, бик тә кызыклы шул.

– Әкият кенә булса икән, Фарук энем, – дип авыр сулады карт. Теләсәң, әйдә алып барып күрсәтәм ферманы да, теге җенме-пәриме Букреевны да...

– Барырбыз, күрербез, Габделбәр абзый. Тәнеш авылына, казак дустыңа да барып житәрбез. Төштән соң. Хәзер мин күптәнге хыялымны тормышка ашырыйм инде: каберстанга барып, әтием, әнием каберләренә зыярат кылыйм.

– Соң, нишләп берүзең барасыңдыр инде анда, Фарук энем, минем Гашүрәм дә синең әтиең, әниең янәшәсендә ята ич.

## ЗЫЙРАТТА

*Без үлгәч, кабербезне җирдән эзләмәгез,*
*аны кеше йөрәгендә табарсыз.*

***Д. Руми***

Тирә якта инде күптән корып юкка чыккан үсемлекләр зыйратта үсә, чөнки монда аларны мал-туар таптамый. Башка куакларны ауга үзләренең ияләре... — Зыйрат – аерым үз итмәгән кошлар зыираттагы куакларда оя кора. Зыйрат – аерым дөнья, бу дөньядан мәңгелеккә киткәннәр дөньясы. Үлем бераүне дә урап үтми, әле гөрләтеп яшәп ятканнарның да барыр дөньясы. Шәһәр зур булмаса да, аның борынгы шәһәр булуына ишарә. Шәһәр зур булмаса да, аның борынгы шәһәр булуына ишарә. Бик борынгы бер мөселман зыйраты байтак зур җирне билэп ята.

өлешендә инде күп каберләр исемсез калганнар, җиргә сеңеп югалганнар. Осталар тарафыннан гарәп нагышлары белән бизәкләп эшләнгән ташлар хәлләрәк, җәмгыятьтә тоткан урыннары югарырак бабаларның каберләре өстенә куелган һәйкәлләрдер. Унҗиденче, унсигезенче, унтугызынчы гасырларга караганнары күп. Егерменче гасырда, халык алласыз чорда, күмелгән әрвахларның каберләре тимер рәшәткәләр белән уратылган, алар эчендә тимердән ябыштырып эшләнгән тумбалар утыра, ул тумбаларны күпчелектә йолдыз очлый, ярым айлылары да юк түгел. Алары инде күптән түгел вафат булган мөселманнар, дәресрәге, үзләренең мөселман икәнлеген исенә төшергәннәр каберендә.

Фарук Йосыфович белән Габделбәр карт зыярат капкасын ачып керделәр, эчкәрәк үттеләр. Йорттан чыкканда Фарук Йосыфович эш коралларын да алырга уйлаган иде, хуҗа алдырмады.

– Мин теге гарәсәттән соң зыяратка барган идем инде, – диде ул. – Янәсе, каберләр исәнме, әрвахлар урыннарыннан купмаганмы? Барысы да урынында. Без тереләр генә бит ул ыгы-зыгылы тормышта яшибез. Өч каберне дә чүп-үләннәреннән тазарттым, чәчкәләренә су сиптем.

– Рәхмәт сиңа, Габделбар абзый.

Әйе, каберләр урынында. Әтисе кабере: «Әюпов Йосыф Низам улы, (1928 – 1954)». Әнисе кабере: «Әюпова Нәсимә Хәләф кызы (1930 – 1971)». Янәшәләрендә Габделбәр картның хәләл җефетенең кабере: «Сәйфелмөлекова Гашүрә Хилалетдин кызы. (1934 – 2016)». Фарук Йосыфовичның әтисе белән әнисе каберен йолдыз бизи, Гашүрәттәенекен – ярым ай. Рәшәткә тимерләре дә, тумбалар да байтак тутыккан.

Габделбәр карт авыз эченнән генә белгән догасын укыды: «Әгүзе билләһи минәшшәйтан иражим. Бисмилләһир-рәхманир-рәхим. Әлхәмдүлилләһи раббил галәмин. Рахманир-рәхим... Гайрел мәгдүби галәйһим да-а-ал-л-и-и-н». Ярар, – диде ул, догасын тәмамлап бит сыпырышкач, – Хаталы укысам, Аллаһ гафу итәр әле. Без бит мәдрәсәләрдә белем алмадык, совет мәктәбендә укыдык.

Фарук Йосыфович әтисе белән әнисе язмышы турындагы уйларыннан бераз арына бирде.

– Чын күңелдән теләгән теләкләр кирәк җиренә барып җитә ул, Габделбәр абзый. Риза булып ятсыннар инде әрвахлар. Мин, Аллаһы боерса, кайту белән мәрмәр ташларга заказ бирочәкмен.



Бүгенге көнгә калерле кешеләребез кабере өстендә тутыккан тимер торуы миңа оят.

– Хәерлегә булсын, Фарук энем.

– Ә сиңа, Габделбәр абзый, минем әтием белән әниемнең каберләрен тәртиптә тотканың өчен зур рәхмәт.

Кайту юлына кузгалдылар. Картның кәефе күтәренке иде. Бара торгач, ул хәтта авыз эченнән генә ниндидер җыр көйли башлады.

*Шатуй буйләры эрәмә,*
*Әрәмәдә сандугач.*
*Бөекмыйча яшим әле,*
*Күңелемдә син булгач.*

Фарук Йосыфович, рульне ваемсыз гына боргалап барган җиреннән, картка борылып карады.

– Әбиең белән күрешкәч, күңелең күтәрелеп китте, булса кирәк, Габделбәр абзый?..

– Әйе, күтәрелде. Риза булмас дигән идем, ул бит миңа рөхсәтен бирде.

– Тагы нинди рөхсәт?

– Соң, өйләнергә инде... Берүзем яшәве кыен бит.

Фарук Йосыфович кычкырып көлеп җибәрде.

– Ничек сөйләштең аның белән Гашүрә түтәй белән.

– Кошлар сайравы белән җавап бирде миңа Гашүрәттәең, Фарук энем...

– Аңысы яхшы, Габделбәр абзый. Димәк, теге Фәнзәл атлы апайга өйләнергә ниятең бар инде?

– Сиңа нишләп апай булсын ул? Алтмыш биштә генә бит әле. Янып торган бичә!..

– Ярар, бу планыңны Гашүрәттәй хуплагач, мин дә хуплыйм. Ни өчен өйләнгәнеңне үзең чамалыйсыңдыр инде? Югыйсә, теге мәзәктәге карт кебек булма.

– Әйе, – диде Габделбәр карт. – Рәхәтләнеп мунча керергә дә әби кирәк. Тик мин әле дөньяның башка ләззәтләреннән дә ваз кичкәнем юк.

– Молодец абзый!.. Тик икенче юрсә минем эчемне пошыра бит әле. Безнең арттан йөргән әнә теге «тугызлы»ны күрәсеңме?

– Күрәм, ни булган?

– Барганда да безнең арттан бардылар. Шул ике этрәк-әләм бездән ерак түгел гарәпчә язулы кабер ташларын караштырып йөргән булдылар.

Аларның булмышы, акыл кимәле йөзләренә чыккан. Гарипчәне түгел, үзебезнең хәрефләренең дә яртысын онытып бетүләрне токымыннан икәннәре күренеп тора.

– Мин дә шулай дим шул. Синең артыңнан моңа чаклы шымчылар йөргәне булмадымы?

– Син дә сөйләдең сүз, мин кемгә хаҗәт.

– Димәк, мин кемгәләр хаҗәт булганмын. Ярар, пошынырлык нәрсә юк, начар юлда йөрмибез…

## Контрразведка эшен башлый

*Котучы исәр булса, эшләре дә исәр була.*

***И. А. Крылов***

...Полиция түрәсе Самохвалов кабинетына ике ярдәмчесе килеп кергәндә, ул телефоннан кул астындагыларга күрсәтмәләр биреп утыра иде. Тугры хезмәтчеләренә әллә ни якты йөз күрсәтмәде, утырырга урын тәкъдим итмәде.

– Йә, сержант, Куроед, докладывай.

Сержант, аның артыннан рядовой Максименко кулларын чигәләренә тигезделәр. Самохваловның йөзе бозылып китүен күреп, капыл гына кире төшерделәр. Ярый әле «К пустой голове руку не прикладывают», – дип битәрләп өлгермәде.

– Иптәш подполковник, таң белән объект туалетка барып килде…

Самохвалов җикереп үк җибәрде.

– Ты что, издеваешься что ли надо мной, сержант?!. Докладывай по существу!

– По существу, иптәш подполковник, аның янына лейтенант Сәфәров белән сержант Коновал килде. Сержант Коновал, гафу үтенеп, кичә алган взяткасын… – Түрәсенең йөзе тагы бүртенгәнен күреп ул хатасын төзәтте, – Бүләген кире тапшырды.

– Объект не возмущался? – дип сорады түрә.

– Юк, иптәш подполковник, – дип сүзгә кушылды Максименкосы. – Наоборот смеялся.

– Аннары объект йорт хуҗасы белән мусульманский зыйратка киттеләр. Без – алар артыннан. Анда мусульманскому Аллаху молились.



Әле өйләренә кайттылар…

– Слежку не заметили? – дип сорады Самохвалов, шымчыларын чыгарып җибәрү алдыннан.

– Юк, иптәш подполковник. Без бит артларына төшеп үк йөрмәдек. Объект, сизенсә, йә тизлеген шәбәйтеп безне артта калдырган булыр иде, йә туктап безне үткәреп җибәрер иде…

Тегеләр чыгып киткәч, Самохвалов уйлана биреп утырды. Кудәрдагы бер дәрәҗәле дустыннан белешмә алып өлгергән иде инде ул. Запастагы тышкы разведка полковнигы. Имеш, анекдотлар, мәнҗтләр, частушкилар җыеп йөри. Зыйратка барып, Аллаху молится… Оста конспиратор! Но ничего, и мы не лыком шиты!.. Бүген эшлисе эшләрне алда икәнлеген исенә төшереп, Самохвалов телефон трубкасын күтәрде.

– Руфиночка, мине Гапсатаров әфәнде белән тоташтыра аласыңмы?

– Энгель Заһидуллович, сезне Самохвалов борчый.

Трубкада шәһәр мэрының хатыннарныкыдай нечкә тавышы ишетелде:

– Приветствую тебя, Илья Максимович. Шәһәр хуҗасына ни йомышың төште?..

– Йомыш дип… йомыш дисәң дә була, Энгель Заһидуллович. – Самохвалов, берәрсе кереп тыңлап тормый микән дигән шик белән, булса кирәк, як-ягына каранып алды. Тавышын ярым пышылдауга күчерде. – Тик телефон аша түгел, Энгель Заһидуллович, срочно очрашырга кирәк.

– Кил. Көтәм. – дигән сүзләрне ишеткәч, Самохвалов кабаланып урыныннан торды, фуражкасын киде, көзге алдына басып аның кокардасы төгәл ике күз арасы турында икәнлегенә ышанды, ике погонындагы икешәр йолдызны барлады. Әйтерсең, төн чыкканчы чуртан әмере белән алары янына тагы берәр йолдыз очып кунар…

Гапсатаровның кәефе начардан түгел иде. Тормышындагы ниндидер аңлашылмаган үзгәреш аңа ниндирәк файда китеререн чамалап утыра иде ул. Бердән, ул хәзер мэр гына түгел, КПССның Бардаш шәһәр комитеты беренче секретаре. Бу вазыйфасыннан дөрес файдаланса, әллә ни чаклы эшләр башкарырга мөмкин. Хөкүмәткә ит тапшыру планын арттырып үтәү турындагы хаты обкомга барып яттымы? Ятты... Дөрес, әлегә Буйновскийдан «Одобрям-с» дигән җавап юк. Булмаса соң, ул барыбер Кудәр өлкәсендә

иң алдынгы беренче секретарь. Бу алдынгылык аның кесәсенә йөкләдә, йә хәтта Мәскәүнең үзендә үк яңа вазыйфа булып та тамарга мөмкин. Икенчедән, ул һаман да Бирдәш шәһәренең мэры. Мэрлыгыннан файдаланып, матди табышларга юлыкса, тотып арт сабагын укытырга, строгий выговор с занесением в учетную карточку чәпәргә, йә булмаса эшеннән олактырырга элекке парткомиссияләр юк. Теге вакытларда булган бер вакыйга нишләптер капыл гына исенә төште. Аның горкомда инструктор булып эшли генә башлаган чагы иде әле. Төзелеш трестына управляющий итеп Кудеярдан бер адәмне җибәрделәр. Тәҗрибәле төзүче. Килде, дүрт бүлмәле фатир алды, эшли башлады. Тик озакламый аның мутлыгы турында горкомга хәбәр җиткерделәр. Имеш, фатирын трест исәбеннән ремонтлаткан икән, агарткан, буяткан. Парткомиссия әлеге шикаятьне тикшереп, бюро утырышына куйды. Чынлап та, сигез йөз кеше эшләгән зур трест түрәсе бу эшкә трестның ике йөз утыз сигез сум илле дүрт тиен акчасын тотынган булып чыкты. Аңа каты шелтә чәпәделәр, тотынган акчасын тиеннәре-фәләннәре белән бергә оешма бухгалтериясенә тапшырттылар. Хәзерге күзлектән карасаң, адәм көлкесе! Шул да булдымы вазыйфадан үз максатында файдалану?!. Ул бит төзелеш тресты түрәсе!.. Күп катлы бер йортның акчасын кесәсенә салып Багам утрауларына чыгып олакмаган...

Гапсатаровның уйларын эш бүлмәсенә шакымый-нитми килеп кергән мэриянең финанс идарәсе мөдире Хрипунова атлы ханым бүлдерде. Төскә ярыйсы, сыны тутырган тавыкныкы кебек. Тыштан караганда, юаш кына, булдыксыз гына бичәгә охшаган.. Эчке халәтенә үтеп керергә мөмкинлек тапсаң, торганы җырткыч акула балыгы. Капса, тоташлае белән каба, тешләсә, өзә тешли.

– Йә, Ираида Касьяновна, эшләр ничек бара? – диде шәһәр башлыгы, түкәтмә өстәл артына килеп утырган урынбасарына.

Аныңсы кулына тотып кергән папкадан бер кәгазь чыгарып түрәсе алдына салды.

– Менә, Энгель Заһидуллович, элекке кирпеч заводының ябылган карьерын төзекләндерүгә тотынылачак средстволарга минем расчетлар.

Гапсатаров кәгазьне кулына алды, күз йөгертеп чыкты.

– Oho! Җитмеш алты миллион! Бик зурдан купкансың түгелме, кызыкай!



– Соң, өлкә бюджетыннан бирәбез дип торганда, зачем скромничать, Энгель Заһидуллович.

– Ә менә моңысы чокырны су белән тутырып, күл, пляж – ясауга реаль смета. – Бичә мэр алдына икенче кәгазь салды.

Гапсатаров маңгаена күтәргән күзлеген аска төшерде, яңадан өскә күтәрде, кесәсеннән ашъяулык хәтле кульяулыгын чыгарып, кыска борынын сызгыртып сеңгерде, аннары аптыраган күзләрен урынбасарының тәбәде.

– Алты миллион?!. Шулай гынамы?

– Аныңсы да запас белән, Энгель Загидуллович. Чуете разницу?

– Арифметиканы бераз беләм әле, – диде түрә көлемсерәп. Шуннан?

– Егермесе тегендә кала инде аның.

– Әһә, откат, – дип нәтиҗә ясагандай итте Гапсатаров.

Бичә, йөгерек күзләре белән кабинет эчен тагы барлап алды.

– Андый сүзне кычкырып сөйләмиләр, Энгель Загидуллович...

– Ә калганы?



Финанс идарәсе мөдире кәгазь кисәгенә нидер язды да, аны түрә өстәленә шылдырды. Аныңсы алып укыды, йөзе җимерелә бирде.

– Ничек пятьдесят на пятьдесят? Син хуҗамы монда, әллә мин хуҗамы? Миңа кырыгы, сиңа уны! Нәрсә, риза түгелме? Ярар, яхшылык миннән булсын: Миңа утыз бише, сиңа унбише...

Бичәнең йөзе еларга җыенган сабыйныкы төсен алды.

– Ну, Энгель Загидуллович!.. Хотя бы миңа егермесе...

Мэр авыр мәсьәләне чишә алмый изаланган укучыдай, бераз уйланып утырды. Ахыры да өстәлгә учы белән шапылдатып сукты. Килештек. Тик алдың-артыңны җыеп йөр, Ираида Касьяновна!

Самохвалов кергәндә, Гапсатаров шәһәр өчен зур эш башкарган кыяфәт белән утыра иде. Милиция начальнигының йөзе борчулы икәнлеген күреп:

– Ни булды, Илья Максимович? – дип сорады.

Самохвалов фуражкасын салды, кульяулыгы белән тирле маңгаен сөртеп алды. Аңа ияреп ирексездән мэр да кояштай ялтыраган пеләшен сөртте. Урынындамы икән дигәнрәк кыяфәт белән борынын тотып карагандай итте. Ялтыр түбәсе дә, бәрәңге борыны да урыннарында иде. Хуҗа җиңел сулады.

– Әллә ни булмады да ул, Энгель Заһидуллович.

Гапсатаров сейфын ачып бер шешә коньяк чыгарды, эчемлекне стаканнарга койды.

– Әйдә, эчеп куйыйк, Илья Максимович. Югыйсә, кобаран очкан. Минем яхшы кәефне бозарга дип килеп керүен, ахрысы.

– Әллә ни булмады да ул, Энгель Заһидуллович... Тик.. шәһәребезгә бер адәм килеп чыккан.

– Сон, Илья Максимович, шәһәребезгә кешеләр килеп тора, китеп тора инде ул.

– Бу бит бик шикле адәм. Кеше көлдереп, «Копейка» да йөри, кунакханәгә тукталмаган, фатирга Себер урамында яшәүче Габделбәр атлы картка кергән. Үзен минем егетләргә филология фәннәре кандидаты, әкияттер, анекдоттыр кебек разный чепуха җыеп йөрүче итеп таныткан.

Гапсатаров елмайды.

– Димәк, теге кинодагы Шурик кебек була инде?

– Шурик кебек безобидный адәм булса, шикләнмәс тә идек. Безнең кайсы бер «эшләребезне»тикшерергә Буйновский җибәргән шымчы түгел микән? Мин Кудеярдагы бер дустыма шалтыратып белештем инде. Никакой он не кандида филологических наук, а полковник в запасе, разведчик. Безнең тыныч кына яшәп яткан Бидрәшгә, аңа ни кирәк булган?

– Действительно, что ему понадобилось в нашем славном городе Бедряшеве? Какие меры приняли, товарищ подполковник?

– Наружное наблюдение установили, товарищ Гапсатаров. Два моих контрразведчика следят за каждым его шагом.

– Ни ачыкладыгыз?

– Иртән торгач, туалетка... тфү! Карт белән чәй эчкәннәр дә, мусульманский зыйратка барганнар, анда мусульманский аллага дога кылганнар. Хотя, ул Әюпов Фарук Йосыфович дигән адәм безнен шәһәрдә туган булса да, күп еллар монда кайтканы булмагач, аның от чистого сердца дога кылуына мин ышанмыйм. Полковник, имеш! Для конспирации филологбулып кыланадыр.

– Ярар, күзәтүегезне дәвам итегез, подполковник. Тагы ни тәкъдим итәсең?

– Сон, ат-артларны себереп куярга кирәктер инде, Энгель Заһидуллович. Мин үземнекеләргә әйттем, гаишникларымны кисәттем, сез дә со своей стороны... Аннары, тикшерергә килгәннәрне авызларыннан калганчы сыйлау без генә уйлап чыгарган



традиция түгел. Минем загородный йортымда мунчасы да, бассейны да бар, кирәк икән, кызларын да табарбыз...

– Син моны ничек күз алдына китерәсен, подполковник? Кайчан әле бер хәчтерүш кандидат наукны шәһәр мэры белән, милиция түрәсе шулай каршы алган? Ул бит, борынгыча әйтсәк, инкогнито килгән полковник. Ярар, уйлашырга кирәк. Ә син, артыннан шымчыларыңны җибәреп, дөрес эшләгәнсең. Бер генә адымын да игътибарсыз калдырмагыз. Через каждые два часа докладывайте мне!..

Милиция түрәсен чыгарып җибәргәч, Гапсатаров эчке телефоннан Хрипуновасын чакыртты.

– Карале, Ираида Касьяновна, – диде ул, кычыта башлаган борын очын кашый биреп. (Башкаларның борыны сый әмет итеп кычыта, Гапсатаровның – хәвеф янавын сизеп шулай кылана). – Теге расчетларыңны эшкә кушмый тор. Хәзергә еаграракка җый, эт тә таба алмаслык булсын!..

Бичә сорау биреп тормады, «аңладым» дигәнен белдереп баш какты да, кабаланып чыгып китте.

## ГАБДЕЛБӘР КАРТКА КӘЛӘШ ӘЙТТЕРҮ

*Ирнең бәхете дә, бәхетсезлеге дә хатын.*

***Иңглиз мәкале***



Фарук Йосыфович Габделбәр картның казак дусты Теләкбирдегә барырга бик үк ашкынып тормый иде. Ул теге төнне берни дә күрмәгән, берни дә белмәгән, гарәсәт турында да берни дә әйтә алмаячак. Әмма картның уйлары икенче якка борылып китүе, өйләнү турында сүз кузгалуы аның күңеленә дәрт өстәде. Нигә, ул кияү булмаслык яшьтәмени әле? Юк, «кияү» сүзе аның башына ялгыш кына килде. Кияү егете булмаслык яшьтәмени әле? Үз гомерендә аңа төрле кыяфәтләргә керергә, төрле вазыйфалар башкарырга туры килде. Әмма сиксән яшьлек картка кияү егете... Бидрәшкә губернатор йомышы белән килүен әле һаман күңеле тартып бетми иде. Картка кәләш әйттерү миссиясе аны, чынлап та, дәртләндереп җибәрде.

– Беләсеңме, борынгының бер полководецы Александр Македонский ни дип әйтергә яраткан Габделбәр абзый? «Килдем. Күрдем. Җиңдем» – дип мактана торган булган. Без дә синең белән Төвешкә барабыз, күрәбез, җиңәбез.

– Тагы да кемне җиңәбез инде , Фарук улым?

– «Җиңәбез»е, Габделбәр абзый, сүз өчен генә. Барабыз, күзең төшкән Фаягөл жингәбеңне күрәбез, сине өйләндереп тә кайтабыз.

– Туктале, тукта, Фарук улым. Шулай тиз генә өйләндерергә Фаягөл – тавык, мин әтәч түгел дә инде.

– Нигә, синең биш-алты ел ошатып артыннан йөрергә, аннан соң яучылар җибәрергә, аннары зур итеп туй ясарга чамаң бармы?

– Юк та ул. Бәлки, ул мине өнәмидер, бәлки, миңа кияүгә чыгарга риза түгелдер, дип әйтүем…

– Казахстаннан кыенлыклар күреп, бер генә ел элек кайткан, дисеңме? Димәк әле аның Рәсәй гражданлыгы да юк, вид на жительство белән генә яши. Ир хатыны булса, шунда ук гражданлык та алачак. Моны бит болай гына исеңә төшерүем. Габделбәр абзый, син бит әле янып торган карт!

Карт каршы стенадагы көзгегә карашын төшерде, түбәтәен салып, ап-ак чәчен сыйпады, аска салына биргән мыек очларын бөтереп өскә күтәрә биреп куйды.

Фарук Йосыфович, аның бу хәрәкәтләрен көлемсерәп карап торды.

– Вәт шулай. Хәзер шкафтан свежий күлмәк, яңа кәчтүмеңне алып киясең, кара аны орден медальләреңне дә тагарга онытма. Алары бардыр бит?

– Нишләп булмасын? «Знак почета» ордены, «Ударник коммунистического труда» белән «Ветеран труда» медальләре… Әле тагын нәрсәдер бирәбез дигәннәр иде, һаман тапшырганнары юк.

– О-hо-hо! Тоташлаең белән геройсың ич син! Шушындый егеткә чибәр кыз отказ бирәме соң! Тем более кияү егете кем! – Фарук Йосыфович кызып китеп чак кына «Полковник! Герой России!» дип әйтеп ташламады. – Кибеткә кереп күчтәнәчләр алабыз. Туй балдагы…

– Безнең чакта балдак-малдаклары булмады бит инде аның, Фарук улым. Әллә, дим, болай гына…

– Ул чакта булмаган икән, хәзер булыр, Габделбәр абзый. Үзем алам бөтенесен дә.



– Минем булачак бичәне бүген үк утыртып алып кайтабызмыни соң? Әзерлек тә юк, дөнья да бик җыештырылмаган…

– Минем эш ярәштерү, Габделбәр абзый. – Кайчан, ничек кабыну – сезнең ирекгә.

– Әнә шулай булса гына инде…

…Теге вакыт дустының капыл гына җыенып кайтып китүенә ярак үпкәләгән булса да, Теләкбирде дә, аның бичәсе Нурсәнә дә кунакларны якты йөз, ачык күңел белән каршы алдылар.

– Хуш килдегез, хуш килдегез!.. дип сөйләнә-сөйләнә карт аларны бер-бер артлы кочаклап шатлыгын белдерде. Аннары бичәсенә җикергән дә булып кыланды. – Син нәрсә, таш сындай карап каттың, тиз генә казанга ит салып җибәр, табын әзерлә!.. Габделбәр служак, кунагың белән таныштырмадың да бит әле. – дип кордашына дәште.

Фарук Йосыфович үзе телгә килде.

– Габделбәр абзыйның служагы, якын дусты икәнеңне белдем инде, Теләкбирде абзый. Мин Бидрәштә туып, Габделбәр абзыйның Сәлимә белән алар өендә уйнап үскән Фарук атлы ир-егет булам. Кызганычка каршы читтә йөрдем, бик озак еллар туган шәһәремне кайтып күрергә туры килмәгән иде. Менә Хода кайтырга насыйп итте.

– Бик хуш, бик хуш! – дип Теләкбирде карт кунакларны өйгә чакырды, кыска гына дога укып битен сыпырды, тегеләре дә аның уңаена бит сыпырган булдылар. Хуҗаның шул арада суыткычтан «артык» китереп чыгаруы Габделбәргә бик үк саер тоелмаса да, Фарук Йосыфовичны аптырауга калдырды. Җитмәсә Габделбәр карт:

– Безнең Теләкбирде хәзер Төвештә мулла булып киткән, – дип тихылдап алды. – Хәтта Фаягөл күршесе белән миңа никах та укырга җыена әле…

Хуҗа көлүеннән туктады, кордашына сынап карады.

– Әллә, чынлап та…

Аның сүзен Фарук Йосыфович бүлдерде.

– Әйе, чынлап, Теләкбирде абзый. Без монда кәләш әйттерергә килдек. Чибәр күршең риза булыр микән?

– Соң, мин аның кылын тоташ ел буена тарткалап йөрим бит инде.

– Риза булыр, булмыйча кая барсын? Хәзер чакырып кертәбез дә никах укыйбыз. Бетте китте!

– Юк, алай булмый бит әле, кордаш, – дип икәүнең сүзенә кушылды Габделбәр карт. Мин бит монда сыер алырга килмәдем.

– Әйе, абзыйлар, кабаланып кабалансак та, шартына китердә инде. Әйдә, өчәүләп өенә керик. Габделбәр абзый, син кияү кешә, Теләкбирде абзый, син – кияү егете, ә мин – яучы. Хәзер бер балагымны гына носкиемә кыстырып куям да... Хәерлегә булсын.!

– Карчык, без каләш әйттерергә киттек, әйттереп чыкканчы ашың өстәлдә утырсын! – дип әмер бирде йорт хуҗасы.

«Каләш» лапас астыннан җилене тулышкан кәҗәсен савып чыгып килә иде. Көтәтми-нитми килеп кергән «кияү»не, аның яучыларын күргәч, каушап калды. Теләкбирде күршесе аны димләп беткән иде инде, шуның өчен мәсьәләне тиз үк аңлады ул. Өйгә кереп тормадылар, ишек алдындагы эскәмиядә урын алдылар. Мөселман бичәсе «айт» дигәнгә «тайт» дип торырга тиеш түгел. Шуңа күрә Фаягөл түтәй: «Әллә ничек бит әле, әллә ничек бит әле...» – дип тәкъдимгә бераз каршылашып маташкан булды.

Ул арада Теләкбирденең әбие урталагы койма аша ашының әзер булуы турында хәбәр итте. Мәсьәлә табында хәл ителде. «Яшь»ләр кәгә муллыкта кавышырга булдылар. Бу килешүне бокаллар күтәреп ныгытып куйгач, кайту ягына кузгалырга җыендылар.

Фарук Йосыфович юлдашына мәгънәле итеп күз кысты. Габделбәр карт кесәсеннән кечкенә тартмачык чыгарды, ачып йөзекне Теләкбирде белән аның карчыгы Нурсәнәгә күрсәтәсе итте, аннары: «Йә, Фаягөл, килешүебезнең билгесе итеп, шушы кечкенә бүләкне кабул итеп ал...» – дип «кәләш»енә сузды. Анысы кызарып китте, бераз вакыт ни эшләргә белми торды. Аннары йөзекне алып бармагына киде.

– Вәт, таман гына бит, – диде Габделбәр карт уңайсыз тынлыкны бозып. – Ә мин исәр онытып кайтып китә язганмын.

## ҖАЕ ТАБЫЛДЫ

*Максат – чараларның мииене.*

*Е. Колпин*

Гапсатаров уйланып утыра иде, капыл гына телефон шалтырады. Ул «дерт»ләп китте. Әйтерсең, теге шомлы бәндә аның кабинетына килеп кергән дә: «Әһә, эләктеңме, бур!» –дип якасыннан алган. Кайсы бер бурлар үзләренең бур икәнен танмый, ә Гапсатаров – таный. Аның тормыш принцибы да бик анык. Энә урлаган да бур, дөя урлаган да бур, энә урлаганчы дөя урла. Тотылмыйча урла. Ә тотылмас өчен «тотучылар»ның күңелен күрә белергә кирәк.



Телефонда Самохвалов иде.

– Энгель Заһидуллович, –дип башлады ул хәбәрен, исәнлек-саулык белешеп тормый. Объект йорт хуҗасы белән Тәвеш авылына барды. Андагы Теләкбирде Теләкҗан улы Түләгәнов атлы казакта сыйланып утырдылар. Йорт хуҗасы – бывший чабан, әлеге көндә авылда муллалык вазыйфасын башкара. Кайтышлый мал симертү комплексына сугылдылар. Әлегә зыянлы эшләре сизелми...

Трубкада, сүз тәмам икәнлеген белдереп, пипелдәү тавышлары ишетелде.

– Сизелмәс, пычагым! – дип сүгенеп үк ташлады шәһәр мэры. – Тәвештәге биш йөз гектар көнбагыш җиренең төшеме кем кесәсенә тамганын белеп калса? Колагына тишүчеләр табылмас, дисеңме?..



Ничегрәк җаен чыгарып, ул бәндә белән танышырга, кылын тарткалап карарга, кулын тос кына итеп майларга соң?..

Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына, дип юкка әйтеп калдырмаган икән шул картлар. Капыл ишек шакыган тавыш яңгырады. Кабинет хуҗасы тагы «дерт»ләп китте, кәнәфиенә чумыбрак утырасы итте.

– Керергә мөмкинме, Энгель Заһидуллович.

Урынбасарының тавышы кыюсыз иде. Син генә җитмәгән идең монда, дип чыгарып җибәрә алмый бит инде.

– Йә, тагын ни кирәк булды? – дип тупас итеп дәште ул урынбасарына.

–Энгель Заһидуллович, сорарга гына кергән идем.

– Тагы нәрсә?

– Атом бомбасы сынауларында катнашкан ветераннарга медальләр тапшырып бетелмәгән бит әле. Тапшырып куярга иде.

– Тапшыр соң. Өйләренә бар да тапшыр. Анда әбәзәтелне мэр кадәр мэрның үзен йөртергә кирәкме? Кулларына берәр кәнәфер читле мэрның үзен йөртергә кирәкме? – Үзенең чигге тоттырган бул. Эт күңеле – бер сөяк, диләр бит. – Үзенең шаяртуы үзенә ошап куйды түрәнең. Хәтта кеткелдәп көлеп алды.

Аңа иярел, урынбасар да елмая биргән иде. Тик түрә капыл гына туктады, башына бик әһәмиятле уй китереп сукты, булса кирәк.

– Туктале, кемнәргә тапшырылмый калган, Хатип Рәхимйпович?

– Хәзер исемлекне барлап керәм.

Урынбасар йөгереп чыгып китте, биш минуттан шулай ук кабаланып килеп тә керде.

– Йә?

–Козинин, Якимчук, Сәйфелмөлековларга тапшырасыбыз бар икән Энгель Заһидуллович.

Түрәнең йөзе тәмам ачылды.

– Димәк, Сәйфелмөлеков? Казинин-мазининнарына мин әйткәнче үзең тапшырырсың әле, Хатип Рәкыйпович. Ә менә Сәйфелмөлеков... исем-отчествосы ничек әле?

– Габделбәр Шәмигулла улы.

– Сәйфелмөлеков Габделбәр Шәмигулла улына бүген, әйтик, иртәгә сәгать биштә медальне тантаналы тапшыру оештырабыз.

– Монда чакырыпмы, Энгель Заһидуллович?

– Юк, өенә барып... Тапшыру өендә, банкеты – Шатуй буендагы кунак йортында. Сиңа задание: картның өенә барып кисәтеп куй, көтеп торсын, кунагы да әллә кая чыгып китмәсен. Мәр үзе килә, диген! Ә сый турында... сый мәсьәләсен дә хәстәрлә. Высший класс булырга тиеш!.,

Сайранов хуҗасына гаҗәпләнеберәк карап торды. Бер гади картка бу хәтле тантана нигә кирәк булган? Банкет, имеш... Высший класс, имеш... Хуҗасы: «Нәрсә карап каттың, иди, выполняй!» – дигәч кенә, исенә килеп, чыгып китте.

Ә Гапсатаров, урыныннан торып, учларын бер-берсенә угалап «Всё о кей! Всё будет о кей!» дип сөйләнә-сөйләнә, япандай кабинеты буйлап йөреп алды.

## ЛОЗУНГ БАР, МАЛЛАР ЮК

*Кеше – мәңгүчан хайван. Аңа әз. Аңа иң яхшысын бир.*

*Ч. Дэм*

Тәвештән кайтышлый, Габделбәр карт Фарук Йосыфовичка гаҗәп хәлне күрсәтү өчен мал симертү комплексына да алып керде. Чынлап та, җимерек тә ватык абзарлар, тәзәнеп-ясанып кире урыннарына кайтып утырганнар. Тик әчтән мөгрәшкән мал тавышлары ишетелми дә, ихата эчендә әшлекле кыяфәт белән ары-бире йөгерешкән малчылары күренми. Аның каравы комплекс түрәсе Букреев белән аның парторгы Садрый Сәүбәнович һаман ихата капкасы төбендә капка башындагы әлеге чакыруга карап талтаналар. «Малчы иптәшләр! Илебезгә мөмкин хәтле күп ит тапшыру өчен көрәшик!» Акбүр белән сызылган «Үзебез ач булсак та...» дигән сүзләр дә җуелмаган. Букреев һаман парторгы Садрый Сәүбәновичны битәрли: «Нишләп һаман сөртеп ташламадың бу антисоветчинаны, иптәш парторг?». «Нишлим соң, Антон Харитонович? Сөртеп торам, язып торалар бит! Хет капка төбенә каравыл куй...»

Габделбәр карт бу юлы да дәшми кала алмады.

– Нәрсә, иптәш Букреев, үзең кайтулыкка кайткансың да ул, нишләп урлап алып киткән малларны кире алып кайтмадың?

Теге икәү бу сүзләрне ишетмәделәр, яңашаларына килеп туктаган юлчыларны күрмәделәр. Үткенчеләргә арытабан кузгалып китүдән башка чара калмады.

– Йә, күрдеңме инде, Фарук энем? – диде карт тамагын каты кырып.

Фарук Йосыфович тамагын Габдебәр карттан да катырак кырды.

– Күрдем, Габделбәр абзый... – Икәүләшеп көлеп җибәрделәр.

– Ни әйтерсең?

– Әлегә нинди дә нәтиҗә чыгаруы кыен. Аллаһының кодрәте бик көчле, диләр бит. Аннары, җинаятьчеләрне ниндидер көч җинаять кылган урынына тартып тора, дигән фараз да юк түгел. Сезнең Букреевыгызны шундый көч монда тартып китермәде микән? – Фарук Йосыфович елмайды. Аның башында ниндидер башка уй да ярала башлаган иде. 1977 ел. Африка. Башкортстанның Белорет районы гына чаклы Зузумбия короллеге...

– Соң, җинаятьчесен монда тартып китергән дә ул, ә аның ярдәмчесен ничек муллалыктан азат итеп, яңадан парторгка әйләндергән?

– Аллаһы тәгалә кодрәте инде, Габделбәр абзый, Аллаһы тәгалә кодрәте...

## АЛЛА КОДРӘТЕМЕ, ӘЛЛӘ ШАЙТАН ЭТЛЕГЕМЕ?

*Берәүләргә барысы да, икенчеләргә – калганы.*

*Г. Е.Малкин*

Иртән торып чәйләп алганнар иде, Габделбәр картның телефоны шалтырады. Камчаткада көн күргән улы Салим шалтырата иде.

– Әти, нихәл.
– Ару гына әле, улым.
– Ни эшләр бетереп ятасың?
– Картның эшләре нинди булсын инде, улым. Әлеге шул таң ата да кич була. Таңы иләп атып, киче тыныч тәмамланса, шуңа шатбыз.

Әле менә шатлык өстенә шатлык. Фарук дустың хәл белергә кайтты.

– Фарук?!. Әти тиз генә трубканы аңа бир әле.
– Сәлим, синме?!. Синең тавышыңны да ишетер көн бар икән! Ничек яшисең?
– Фарук! Бидрәшкә нинди җилләр ташлады?
– Командировка дисәң дә була, Сәлим. Яшьлек елларын сагыну дисәң дә…
– Мин дә искиткеч сагындым. Быел көз кайтып килермен дип уйлыйм инде. Син дә кайтсаң, ниһаять очрашырбыз, дус! Кырык ел үткән бит, әйтергә генә аңсат! Трубканы әтигә бир әле.
– Әти, гаиләбез белән көзен кайтабыз.
– Ярар, улым. Бөтенләйгә кайту турында да уйла инде син. Бидрәштә Сәйфелмөлековларның тамыры корымасын…

Бу сөйләшүгә карт чиксез шат иде.

Фарук Йосыфович хуҗага бүгенге планын белдерде. Өченче көн Бидрәштә, әле һаман нык лап эшкә тотынганы юк.

– Тагы да нинди эш соң ул, Фарук энем? – диде карт гаҗәпләнгән кыяфәт белән.
– Оныттыңмыни соң, Габделбәр абзый, мин бит монда командировкага килгәнмен. Мәзәкләр, әкиятләр җыярга, халыкның хәзерге көндәге авыз-тел иҗатын өйрәнергә…

Габделбәр карт хәйләкәр елмайды.

– Соң, әлеге без күргән хәлләр әкият түгелмени ул?.. Ярар, мин сине өемә бәйләп куя алмыйм. Кая барасың, кемне күрәсең килә, күр. Рәхәт итсәң, мин дә сиңа иярер идем…
– Бар эшеңне ташлапмы, Габделбәр абзый?
– Пенсионерның нинди важный эше булсын, энем. Мин бит Бидрәштәге хәлләрне бик яхшы беләм, мәгаен, файдам тими калмас.
– Алай булса, кайдан, нәрсәдән башлыйбыз? Мәчетегезне күреп, муллагыз белән танышып чыгарга иде. Мәктәптә каникул вакыты инде, кеше булыр микән? Аннары китапханә, музей… Берәр эшләгән предприятиедә булу да комачауламас иде.



Планнарың бик зур икән дә, Габделбәр энем. Тик бер нәрсәне исеңнән чыгарма: безнең шәһәр хуҗасы Гапсатаров әфәнде важный кунакларның шәһәргә килеп аңа күренми китүләрен бик яратмый, диләр.

Эшне аңардан башларга кирәкмәсме?..

Фарук Йосыфович уйланып торгандай итте.

– Мин нинди важный кунак булыйм ди инде, Габделбәр абзый. Филология фәннәре кандидаты, мәзәкләр, әкиятләр җыючы. Өс-башым да әллә ни түгел. Машинам да синең «Запорожец»ыңның сыңары дип әйтерлек…

Габделбәр карт хәйләкәр елмайды. Чак кына: «Сөйләмә инде миңа әкиятеңне! Кандидат, имеш…» – дип ычкындырмады. Фән кандидатын кая барса да ниндидер шикле малай-шалайлар озатып йөрми ул…

Фарук Йосыфович картның хәйләкәр елмаюының мәгънәсен аңлады. Запастагы разведчик, ялда ятып, һөнәри осталыгын бөтенләй югалткан, булса кирәк. Шәһәр полициясен генә түгел, бер авыл картын да ышандыра алмагач…

Бидрәш шәһәре, башка борынгы шәһәрләр кебек, ике өлешкән тора. Габделбәр карт яшәгән борынгы бистәсе гади авылдан әллә ни аерымый. Шәхси йортлар, каралты-куралар, мал-туар, кош корт… Алда әйтеп киткәнебезчә, заманында монда хәтта «Коммунизм юлы» атлы совхоз да эшләгән, аның зур, куәтле мал симертү комплексы да булган. Себер урамы буйлап барып, Фарук Йосыфович укыган мәктәпкә җитеп, сулга борылсаң, Карл Маркс урамы буйлап китәсең. Рәсәйнең бар шәһәрләрендә дә Маркс урамы белән Ленин урамы бар икәнен һәркем беләдер. Әлеге китеп барган урам Ленин урамы белән кисешкәч, шәһәрнең заманча өлеше башлана. Сталин заманында төзелгән өч, Хрущев заманында калкып чыккан биш катлы «хрущобалар». Шәһәрдә зур химия комбинаты төзелгәч, калкып чыккан берничә тугыз, хәтта уникe катлы «небоскреб»лар. Шулар арасында кибетләр, хәзерге тел белән әйтсәк, «мини», «супер», «гипермаркетлар», мәктәпләр, балалар бакчалары, спорт корылмалары… Шәһәрнең үзәк мәйданы элек Ленин исемен йөрткән, хәзер аны «Азатлык мәйданы» дип атыйлар. Исеме үзгәрсә дә, мәйдан уртасын һаман да Ленин һәйкәле бизи. Ул биек постаментка баскан да, сул кулына кепкасын тоткан, уң кулының имән бармагын каршысындагы өч катлы йортка төбәгән. Аңысы – сбербанк бинасы. Бөек Ленин коммунизмга бару юлын күрсәтә, ди торганнар

иде заман идеологлары. Нишләп коммунизм юлын күрсәтсен, «Храните деньги в сберегательной кассе!» дип чакырып тора иң, дип авыз ера торган иде кайсы бер аллага да, муллага да ышанмаган адәмнәр. Әйе, бина башында андый лозунг та эленеп торды. Хәер, нинди генә гыйлдә белән ул да урынына кайткан. Ленинның артында шәһәр хакимияте бинасы. Әле бинага керә торган биек баскыч янәшәсендә өч-дүрт ир шул чакыруга карап басканнар да, нәрсә турындадыр гәпләшеп торалар.

– Моны тагы кайсысы элеп куйды икән? – дип гаҗәпләнүен белдерә берсе.

Икенчесе, җилкәсен тырпый-тырпый, хихылдый.

–Хакимият каршында гына булгач, алар элдергәндер инде. Синең белән минем кесәдә җилләр уйный, сбербанкка тапшырыр байлык юк…

Өченче ир тегенең сүзен куәтли:

– Безнең кесәләрдә тишектән башка берни дә юк. Булса, сбербанкка кертмәс идек әле, хет бер «ярты» алып янган йөрәкләрнең ялкынын басар идек. Мондагылар үзләрен үгетли торгандыр…

– Әссәламмәгаләйкем, егетләр! – дип сәлам бирде аларга Габделбәр карт.

– Сәлам егетләрнең асылларына, – дип аңа кушылды Фарук Йосыфович. – Ни эшләр бетерәсең?

– Безнең эш билгеле инде, абзый кеше, – дип кулындагы себеркесенә ишарә ясады ирләрнең өлкәнрәге. – Заводы ябылды, инженерлар кирәкми, урам себерүдән башка эш тә калмады. Менә сез ни эш кылып йөрисез монда… монау мәсхәрә драндулетыгызда. – Күрмисезмени, стоянкада хакимиятнекеләрнең берсеннән-берсе тәкә машиналары…

Фарук Йосыфович көлеп җибәрде.

– Нәрсә, ул тәкә машиналар, безнең «драндулет» алар рәтенә кунаклавыннан гарьләнерләр дип уйлыйсызмыни?

– Машина – җансыз нәрсә, алар гарьләнмәс, хуҗалары гарьләнер…

Габделбәр карт Фарук Йосыфовичка ияреп мэрия бинасына керүдән баш тартты. «Мин зур хуҗалар тирәсендә йөреп өйрәнмәгәнмен. Син, Фарук улым, ул Гапсатаров белән үзең генә гәпләш инде , – диде. Аннары, – Кабул итсә…» – дип тә өстәп куйды. Фарук Йосыфович икенче катка күтәрелде. Тоныкпыялалы



ишекне ачып приемнаяга керде. Ялаңдай зур бүлмәдә гадәти булмаган тынлык иде. Секретарь бичәнең ярым пышылдап кем беләндер соңгы гайбәтләр белән уртаклашуы да, ачык форточкадан адашып килеп кергән ата чебеннең чыгар юл тапмыйн безелдәве генә бу тынлыкны боза алмый иде. Кунак әлеге бичәгә сәлам бирде. Анысы ваемсыз гына трубкадан аерылган булды, сәламгә каршы баш каккандай итте, аны бик әһәмиятле шөгыльдән бүлдергәнгә йөзе дә җыерылып китте булса кирәк. Фарук Йосыфович ат башыдай алтын хәрефләр белән язылган табличкалы ишеккә күз салды: «Мэр города Бедряшево Гапсатаров Энгель Загидуллович»…

–Хуҗагыз мине кабул итәр микән, ханым?

– Ә сез язылган идегезме соң?

–Юк, мин сезнең шәһәр кешесе түгел, Кудеярдан килдем.

Ханымның кырыс йөзе ачыла биргәндәй булды.

– Аймылыштыгыз шул безнең хуҗа белән. Ул кичә сөйләп кына Кудеярга киткән иде. Бүген төштән соң кайтып җитәргә тиеш…– Секретарь кечерәк көмеш хәрефләр белән «Заместитель мэра города Бедряшево Сайранов Хатип Ракипович» дип язылган ишеккә ымлады. – Урынбасары урынында. Бәлки, аңа керерсез.

Фарук Йосыфович түш кесәсеннән визитка чыгарып ханымга сузды.

–Әйтегез соң… Кабул итсә…

Сайранов хуҗасы кушып киткән бик тә мөһим эш белән мәшгуль иде. Ничек Габделбәр Сәйфелмәлеков йортына барып тантаналы шартларда әлеге медальне тапшыруны оештыру. Анда шәһәр җитәкчелегеннән кемнәрне чакыру. Ул картның серле кунагын ничегрәк хөрмәтләү. Тантананың банкет өлешен кайда һәм ничек үткәрү. Сый мәсьәләләре. Кунакның нинди әчемлек, нинди ашамлыклар яратуын ничегрәк ачыклау…

Аның бу уйларын өстәленә визитка кертеп салып, секретарь бичә бүлдерде.

– Кудеярдан килгән ниндидер әтрәк-әләм кабул итүегезне сорый, Хатип Рәкыйпович. Бәлки, эшегез күплеккә сылтанып, откаэттыр. Бетмәс алар!..

Урынбасар «Аюпов Фарук Юсуфович. Кандидат филологических наук» дигән язулы визиткага күз салды. Аның йөзендә тоң аптырау, аннары шатлык билгеләре пәйда булды. Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына – шушы буладыр инде. Ул, секретарь

бичәгә ияреп, алгы бүлмәгә үк чыкты, кунак белән куш кулын биреп күреште.

– Хуш киләсез безнең шәһәргә, Фарук Йосыфович. Әйдәгез, минем бүлмәгә үтик.

Төкәтмә өстәл артында капма-каршы утырышкач, секретарь бичәне чакырып кертеп, әмер бирде.

– Тиз генә чәй ясап керт. Бидрәш балы белән чәйләп алу комачауламас, Фарук Йосыфович. Бәлки, катырагыннан да…

– Юк, Хатип Рәкыйпович. Бердән, мин эш өстендә, икенчедән, за рулем…

Бер филология кандидатын да шәһәр түрәләре болай кабул итмәвен Фарук Йосыфович яхшы белә. Аның башына тагы да «Провал…» дигән уй килде.

– Килүегезнең максаты нидә? – дип урынлы соравын куйды түрә, чәй эчеп алгач.

– Фольклор җыю белән шөгыльләнәм, – диде Фарук Йосыфович бик үк ышанычлы булмаган тавышы белән. Бидрәш – борынгы шәһәр, монда фольклорчыга эш җитәрлектер, дип уйлыйм.

Кабинет хуҗасы елмайды.

– Фольклор… Фольклор, дисез инде. Бик яхшы. Кайсы кунакханәдә урнаштыгыз соң? Шартлар ярарлыкмы? Бездән нинди ярдәм кирәк?

– Кунакханәдә түгел, Сәйфелмәлеков Габделбәр абзыйда. Бәлки, беләсездер, Себер урамында яши. Мин бит Бидрәштә тудым, аның улы белән бергә аунап үстек.

– Беләбез хезмәт һәм кораллы көчләр ветераны Габделбәр Сәйфелмәлековны!

– Әйткәндәй, ул үзе дә монда, мине озатып йөри.

– Соң, нишләп аны алып кермәдегез, Фарук Йосыфович? Кайда калды ул?

– Мэрия алдында.

Урынбасар тагы секретарь бичәне чакырып алды.

– Руфина Хөршатовна, урамга чык та, тиз генә монда Габделбәр атлы картны чакырып керт әле.

Карт түрә бүлмәсенә кыймый гына керде, кергәч, аякларын ышкыган хәрәкәт ясады. Сайранов аны ишек төбенә килеп каршы алып өстәл артына утыртты.

– Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына, ди, Габделбәр абзый. Без бит хуҗа белән бергә иртәгә өегезгә барып сиңа медаль



тапшырырга җыенабыз. Кичке бишләрдә өеңдә бул, пажалысты. Олы кунакның тантанада катнашуы безнең өчен бигрәк тә зур мәртәбә.

– Нинди медаль ул тагы? – диде карт гаҗәпләнеп.

– Атом бомбасы сынавында катнашкан өчен югары награда!

## ЮЛЫ УҢМАДЫ

*Кешеләр хайваннар кебек: зурлары кечеләрне ашый, кечеләре зурларны тешли.*

*Вольтер*

Күптән, өлкәгә чакырып, киңәшмә-фәлән үткәргәннәре юк иде, Гапсатаров анда барып разведка ясап кайтырга уйлады. Нинди яңалыклар бар? Яңа себерке ничегрәк себерә? Кемнәрне эштән алган? Кемнәрне майлы урыннарга куйган? Бидрәш хуҗасына карата губернатор ниндирәк фикердә? Шәһәргә шымчымы, тикшерүчеме җибәрүенең сәбәбе нидә? Нишләп ул качып-посып эш итеп маташа? Билгеле, аның бу сорауларына җавапларны губернатор үзе биреп утырмас. Власть коридорлары озын һәм бормалы. Гапсатаров аларны үзе үтеп чыгар, бик күп нәрсәләрне белер, бик күп нәрсәләргә төшенер. Тик төп хуҗа белән очрашып сөйләшү дә комачауламас. Кабул итсә, аның ничек сәлам алуы, аның ничек итеп урын тәкъдим итүе, аның елмаюымы, ырҗаюымы, аның һәр соравы, һәр сүзе күп нәрсә турында сөйли бит…

Кудеярга кичләтеп килеп кунуының да сәбәбе юк түгел иде. Байтактан бирле яшь һәм чибәр сөяркәсе белән күрешкәне, сөешкәне юк. Бидрәш мэры алып биргән ике бүлмәле кысым гына фатирда син дә мин көн күреп яткан марҗа әледән әле телефоннан шалтыратып: «Энгельчик, когда приедешь? Соскучилась!» – дип теңкәсене тетеп тора. Әллә Энгельчикны сагынган, әллә аның крокодил тиресеннән тегелгән калын кошелегын?..

Олпат шәһәр түрәсенең студентка кыз белән танышуы, кавышуына да ике еллап гомер үтеп киткәндер. Кудеярга китеп барышы иде. Степной шәһәре тәңгәленә җиткәч, юлда кул күтәреп торган кызны күрделәр. Энгель Заһидуллович шоферына машинасын туктатырга әмер бирде. Зарыгып попутка көтеп торган юлчыны җәлләп түгел, болай, берүзе китеп баруы күңелсез булганга гына. Бәхетенәдер, үзен «Снежана» дип таныштырган кыз бик сүзчән

булып чыкты. Яргы сәгать эчендә машина хуҗасына бөтен тәрҗемәи хален сөйләде дә бирде. Егерме ике яшьтә, Кудеярда университетта укый икән. Булачак социолог. Степной шәһәрендә әтиәнисе бар, гади адәмнәр. Заводы ябылып, әтисе эшсез калган, әнисе хастаханәдә шәфкать туташы. Студентканың матди хәле мактанырлык түгел икән дә, төнге клубта савыт-саба юучы булып эшләп очын-очка ялгый икән. Анда бай балаларының ничегрәк типтерүләрен күреп әллә эче поша, әллә инде көнләшә икән…

Энгель Заһидуллович кызны жәлләгән булды, хәтта аркасыннан сөеп юатып та маташты. Әрсез кыз моңа үпкәләмәде, ирнең кулын этәреп җибәрмәде, аңа сыенарак та төште, булса кирәк. Ә түш кесәсендәге алтын ялатылган савыттан затлы эчемлек тә тәкъдим иткәч, борын чөермәде, савытның борынын килешле генә итеп кызыл иреннәренә тигезде дә тамагын голтлатмый гына эчемлекне чөмерде. Аннары савытка ягылган иннеген кульяулыгы белән сертеп алды да, хуҗаның үзенә сузды. «Танышлык өчен, – дигән булды ул оялып-нитеп тормый, – Мин үзем белән таныштырдым инде, сез, абый кеше, кем буласыз соң?

Күрәм: заводтан кыскартылган әтрәк-әләм түгел. Андыйлар биш миллион торышлы япон джибында йөрми…»

Энгель Заһидуллович көлеп җибәрде. Бик әрсез кыз булып чыкты ич аның очраклы юлдашы. Үтеп чыккан кызга охшаган.

– Мин скромный Бидрәш шәһәренең скромный мэры Энгель дәдәң булам, – диде ул.

– Oho! – диде кыз, йөзенә соклану тойгысы чыгарып. – Мэр! Везёт же людям!

– Кому везёт, мне что ли? – диде Энгель Заһидуллович елмаеп.

– Тебе уже повезло. Везёт твоей любовнице…

Бу сүзләрдә чын мәгънәсендә чакыру яңгырраганын аңлады ир. Шәһәрнең Мәдәният сарае директоры Хәмдүдә ханым аны күптән ялкыткан иде инде. Бердән, картаеп, ямьсезләнеп бара, икенчедән, һаман туя белми.

– Минем сөяркәм юк, хатыным гына бар, – диде ир.

– Шушындый олпат ир! Ничек бер хатынга гына карап яшәргә мөмкин? Әллә инде чибәрләрне үзенә каратыр төсең-сыйның бар…

Ир кызга текәлебрәк карап торды.

– С-синеме… с-синең кебекләрнеме?

– Ә хотя бы мине… Интересная идея, бу турыда уйлап карарга мөмкин.



Ул арада, шәһәргә керәп, университет ятагына килеп җиткән иделәр инде. Ир-ирешнәрен кызның битенә тигезде, түш кесәсеннән визитка чыгарып аңа сузды.

– Снежана… Снежаночка, син миңа бик ошадың. Вакытың булганда шалтырат, – диде.

Кыз машинадан төште, шаркылдап көлеп җибәрде.

– Дядя Энгель… Энгельчик, сез дә миңа ошадыгыз. Шалтыратырмын…

Менә шулай башланып китте аларның «мәхәббәт романы». Кудерга икенче килүендә Энгель Заһидуллович Снежананы рестоpанга алып кереп сыйлады, кунакханә бүлмәсендә алар шашып, җүмәкләшеп төн үткәрделәр. Мондый төннәр ешайгач, гашыйк ир кызны баштан аяк затлы киемнәргә төрендерде, алтын, асылташлар белән сөсиндерде, фатир алып бирде.

Менә әле ул сөяркәсе фатирына кисәтми-нитми генә барып керерго уйлаган иде. Снежанасы ишекне ачу белән каушап калды, әмма үзен тиз генә кулга алалды, ирнең кочагына сарылды.

– Энгельчик милый! Как неожиданно! Әйдә, бүлмәгә дә үткәрен тормыйм, тиз генә душ коенып чык… – Ул ир сузган төенчекне алды, аны көчләп дип әйтерлек ванна бүлмәсенә төртеп кертеп җибәрде. – Мин өстәл әзерли торыйм… постель…

Кыз, ир ваннадан капыл килеп чыкмасын дип, аның келәсен тышкан эләктереп үк куйды. Йокы бүлмәсендә шыр ялангач ни эшләргә белми торган заман Ромеосына:

– Ну-ка, киемнәреңне генә эләктер дә, дуй отсюда! – дип әмер бирде. Үзе урын-җирен, өстәлне җыештырырга тотынды. Ванна бикен ачып куярга да онытмады.

Энгель Заһидуллович ваннадан бер трусиктан гына килеп чыкты, халат эләктерде. Аныcы нишләптер дымлы иде. Күңелендә шик уянды. Ә идәндә ятып калган бер ирләр ноские шиген көчәйтә төште. Аена бер мәртәбә генә килгән ирга генә риза булып ятмыйдыр бу шлюха дигән уй йөрәген сыдырып узды. Дәшмәде, халатының төймәләрен дә эләктерми, көзге каршына басты. Әйе, илле алты яшьлек ир, башы пеләшләнгән, корсагы кинәйгән, йөзен җыерчыклар басып, аяклары кәкрәеп бара. Мачо түгел. Ә Снежана? Егерме дүрт яшьлек бичә! Яшь бияләй уйнаклап тора! Биле нечкә, түшләре, билдән түбән төшләре тыгыз. Аяклары төз. Кочакка сыенып бер елмайса, җаннарың эреп китәрлек. Һай! Спорттагыча әйткәндә, авырлык категорияләре тигез түгел шул!.

Ир, залга килеп кергәч, хатын шулай эшләде дә. Кырыс дәшеп битәрләргә җыенган ир эреде дә китте. Хатынны түшенә кысып бер ике мәртәбә үпкәндәй итте дә, «Шампанское» ачырга тотынды…

Төнен ир, гомердә булмаганча, уңышсызлыкка очрады. Инде дә дәртләнеп ирлек бурычын башкарырга җыенган иде, прихожайда ятып калган сыңар оек күз алдына килде, дәрте сүрелде дә куйды. Хәер, Снежанасының моңа бик исе китмәде. Карт алашаның назы кирәкмени аңа? Акчасы явып торса шул җиткән. Көндезен яшь сөяркә белән әүмәкләшеп йончыган иде инде ул. Стенага карап борылып ятып йоклады да китте, хәтта тамагыннан җиңелчә гырлау авазы да ишетелде, борыны да ара-тирә сызгырып алгалады. Ә эше барып чыкмаган ир төнен йокысыз үткәрде…

Җитмәсә… Гадәттәгечә, туганнарында кунган шоферы Владик аның артыннан сәгать сигездә килергә тиеш иде. Энгель Заһидуллович иртәнге кофедан соң күңеле кайта башлаган сөяркәсе битеннән генә чупылдатып үпкән булды да, аска төшеп, подъездан чыкты. Машинасы килмәгән иде әле. Аның каравы ишек төбендә бер килбәтсез озын карачкы кемнедер сагалап тора иде. Энгель Заһидулловичны сагалаган икән. Якасыннан борып тотып алды да, авызыннан килгән сасы самогон исен борхытып аңа иелде. «Беттем!» дигән уй мисен яндырып алгандай булды ирнең. Хәзер, менә хәзер пычагын чыгарыр да аның эченә тыгар. Мескен «Ярдәм итегез!» дип сөрән салырга уйлады. Тамагыннан бары көчек шыңшуыдай гына аваз чыкты. Бандит пычак чыгармады, хәтта йодрыгын да эшкә кушмады. Очлы тезе белән ирнең ике бот арасына бик каты тамызды. «Старый козёл!» дип сүгенде һәм үз юлына китеп барды. Яшь кызлар кочагын яратучы «кәҗә тәкәсе» сыны катып, ике кулы белән сызлап авырткан төшен каплап чүгәләп утырып калды. Ул арада шофёры да килеп җиткән иде инде. Бу халне күреп, шофёр тиз генә машинасыннан чыкты, һаман да сынсыз булып утырган хуҗасы өстенә иелде.

– Ни булды, Энгель Заһидуллович? Йөрәгегез кыстымы әллә?

Түрә күзләрен акайтып шофёрына карады, ямьсез итеп сүгенде.

– Нигә соңладың, сволочь?

– Соң, биш кенә минутка инде, Энгель Заһидуллович. Пробкалар бит…

– Биш минутта мине биш мәртәбә үтерергә мөмкиннәр иде.

Шофёр хуҗасын култыклап урынына алып барып утыртты. Бардачоктан таблетка чыгарып аның авызына салды, минералка шешәсен ачып су йоттырды.



– Менә, Энгель Заһидуллович, йөрәк кысуын баса ул.

Хуҗа кешенең ыржайган йөзендә елмаюга охшаш бер нәрсә хасил булды. Кайсы бер ирләрнең «йөрәге» түшендә түгел, корсагыннан астарак төшендә икәнлеген ул үзе белмиме дә, аның күпне күргән шофёры белмиме.

– Әйдә, Ак йортка, диде ул тешен кысып кына. – Биш минутка соңлаганың өчен квартал премиясеннән мәхрүм итәм.

Ак йортта да түрәнең юлы яртылаш кына уңды. Губернатор Мәскәүгә киткән иде. Аның белән очрашып, кылларын тарткалап карау бәхетенә ирешә алмады. Ул, чатанлап, йортның икенче катына төште, финанс министры Митрохинның приемнаясына керде. Секретарь кыз хуҗасының Бидрәш мәры белән яхшы мөнәсәбәтләрдә булуын белә иде, шуның өчен аны озак көттереп утыртмады.

– Хәерле иртә, Адам Аронович! – Гапсатаров ялан хәтле кабинетны аркылыга үтте, хуҗага кул бирде.

– Хәерле… хотя хәерлеме, хәерсезме, сездән кала инде, Энгель Заһидуллович. Нишләп чатанлап киттегез әле?

– Эш бит, эш, Адам Аронович. Әлеге благоустраивать ителәчәк карьерга белгечләремне алып төшкән идем, кыеш басып аягымны сындыра яздым. Бу кызу эш өстендә ярый әле сынмады, сеңере генә сузылды.

– Сочувствую, Энгель Заһидуллович, сочувствую. Вам надо беречь себя. Вы нужны вашему городу, вы нужны стране. Кстати, благоустройство карьера…

– Шул мәсьәлә белән кердем дә инде мин сезгә, Адам Аронович. Минем начфин Ираида Касьяновна планнарыбызны сезгә җиткергәндер.

Митрохин Гапсатаровның күзләренә тишеп карады.

– Җиткерде, Энгель Заһидуллович. Киләсе атнадан да калмый откроем финансирование. Калганын инде үзегез карагыз…

Министрның йөзендә елмаю билгесе пәйда булды. Аңа карап, Гапсатаров та авызын ерды. Кулны кул кысты…

Финанс министрыннан чыкканда, Гапсатаровның кәефе бераз яхшырган иде. «К чёрту Снежанасын! – дип сүгенде ул эченнән генә. Аңа башка снежаналар да бетмәгән. Шәһәр уртасындагы ике бүлмәле фатиры гына жәл. Ул шлюха исеменә яздырырга кирәк булмаган…

ФСБ түрәсе Запеканкин урынында, эшлекле кыяфәт белән «Комсомольская правда»ның соңгы санында чыккан кроссвордны чишеп утыра иде. Австралиядә яшәгән тереклек иясе. Анда

нәрсәләр эшн соң әле? Тәк… мөгаен, кроликтыр инде, шуны бетерә алмый изаланар, диләр бит. К-р-о-л-и-к. Килми, монда җиде шакмак, ә кроликта алты гына хәреф…

Түрәнең шушы әһәмиятле шөгылен Бидрәш мэры Гапсатаров бүлдерде.

– Керергә мөмкинме, Антон Харитонович?

Рөхсәт сорап торган буласың, кердең бит инде, дип битәрләргә уйлаган иде дә, тупас мөгамәләсенең урынсыз буласын аңлап, йөзенә көчләп елмаю чыгарды.

– Узыгыз, уз, Энгель Заһидуллович. Йә, безнең тарафларга нинди җилләр ташлады? – дип кунакның йөзенә сораулы карап ташлады, ул төкәтмә өстәл артында урын алгач.– Шәһәрегез ыксым, олы сәясәттән читтә, анда безнең контора хәл итә торган проблемалар юк…

– Анысы шулай да ул, – дигән булды Бидрәш мэры. Үзебезнең проблемаларны без үзебез дә хәл итәргә сәләтле. Тик… сәер дип әйтимме, серле дип әйтимме миссия белән бер агентыгызны безгә җибәргәнсез бит әле.

Запеканкин аптыраган кыяфәткә керде, бер сүз дә дәшми озак кына түшәмгә карап утырган булды.

– Тагы да нинди агент инде ул, Энгель Заһидуллович?

– Сон, полковник Әюпов.

– Ул кешене әз-мәз беләм. Шляпочное знакомство, дисәң дә була. Тик, бердән, ул полковник түгел, запастагы полковник. Икенчедән безнең конторага аның бер катнашы да юк. Туктале тукта, ул университетта алган белемен исенә төшереп, филология фәне белән шөгыльләнә башлаган икән дигән хәбәр чыккан иде бит.

– Әйе, мәзәкләр, әкиятләр, табышмаклар җыя, имеш. Ә университетның филология факультетында, ачыклабрак әйтсәк, фольклор кафедрасында аның турында берни дә белмиләр.

– Шулаймыни? – дип йөзенә гаҗәпләнү тойгысы чыгарган булды Запеканкин. – Карале, Энгель Заһидуллович, сезгә бит кызыклы… киттеле шәһәрнең мэры булып түгел, разведкада эшләргә кирәк. Әюповның чыгышы сезнең шәһәрдән түгеме соң? Запаска чыккач, Мәскәүдә калмый, безнең төбәккә кайтып төпләнүе дә шуның белән бәйледер инде ич. Бидрәшкә баруы да яшьлек эзләрен барлап йөрүедер. Туганнары калганмы соң анда?

– Бер туганы да юк. Куңакханәгә төшми Габделбәр Сәйфелмөләков атлы картта яшәп ята.



– Анысын да белеп өлгергәнсең икән.

– Без үз шәһәребезгә үзебез хуҗа, Антон Харитонович. – Гапсатаровның йөзендә горурлану тойгысы пәйда булды. ФСБ түрәсе елмайды.

– Бдительность никогда не помешает, Энгель Заһидуллович. Тик борчылырга урын юк. Своих мы в обиду никогда не дадим.

Бу сүзләр генә Бидрәш мэрының күңелен тынычландыра алмады. Запеканкин берни дә белми булып кылана. Аның җәһәннәм тишегендәге шәһәренә шпионны Мәскәү үзе үк җибәрмәгәндер инде?!. «Ничего. Мы и сами с усами», – дип сөйләнде Гапсатаров Запеканкиннан чыккач.

Әле кайтып җитәсе бар, шоферы «кара айгырын» камчылап куса да, кимендә өч сәгатьлек юл. Анда мөһим чарага әзерләнәсе тикшерәсе бар. Урынбасары Сайрановка гына ышанып калдырса… Дөрес, анысы да төшеп калганнардан түгел, юрганны үз ягына айһай оста тарта белә. Тик, эшкә килгәндә, кушканны гына башкарырга өйрәнгән. Артыгына бер дә фантазиясе җитми… Ә бит кирәк кешенең күңелен күрү гади эш түгел. Аның күңелен күреп кенә калмаска, аптыратырга кирәк. Гомере буе исендә калырлык булсын…

Гомере буе исендә калырлык… Гапсатаровның уйлары капыл гына икенче юнәлеш алды. Иртәнге ямьсез күренешне күз алдына китерде, хәтта теге колганың һөҗүменә дучар булган ике боты арасы тагы сызлап киткәндәй булды. Гади юлбасар түгел иде дә ул. Акча таптырмады ич, кыйммәтле сәгатен, кесә телефонын да тартып алмады. Азгын Снежананың күңелен күрүчеләрнең чираттагысы гынадыр. Вәт мәртәт бичә!.. «Энгельчик» аңа шешке тун алып бирә, чыршы бизәгәндәй, аның колакларын, муенын, бармакларын алтын-асылташлар белән бизи, көч-дәрман түгеп «эшләп алган хәләл акчасын» күпме сарыф итә. Юк! Башка ул бозык хатынга ике салганын бирсен дә басмаячак. Кием-фәләнен, йөзек алкаларын салдырып алып булмый инде аның, фатиры жәл, сатсаң, кимендә өч миллион тартыр еврофатир! Әнә шул «евро» итәр өчен генә дә күпме расхутыннан чыкты. Нишлисең, бу дөньяда алдау бар, алдану бар. Соңгы акчалары түгел бит. Соңгы фатиры түгел. Кудеярда йорт салдырып куйдымы? Куйды! Аның гаражында биш миллионга төшкән «Лексус» атлы машинасы утырамы? Утыра! Боларны һәм калган башка байлыкларын, мәсәлән, Бидрәштәге өч катлы дачасын үзенә яздырмаска башы җитүен җитте аның. Җитүен\җитте… Тик… Туктале, ә хатыны? Яшь чибәр, кадерле хатыны, Кадриясе?..

Дүрт ел элек кенә гомер иткән Вәсиләсен аерып, аңа фатирын калдырып, чираттагы сөяркәсе Кадриягә өйләнгән иде ич ул. Моңысы инде картаеп, җан тәслим кылганчы яшәр соңгысы булыр дип өйләнгән иде. Ирлек бурычын башкарудан мәхрүм иргә риза булып яшәрме икән соң ул? Яңып торган кырык яшьлек хатын. Аерылам дисә? Өч катлы дачасын да, аның затлы җиһазын да, дача гаражында утырган «Мерседесы» белән «Фордын» да, «Тетрацикл» белән снегоход-фәләннәрен дә үзе белән алып китәчәк ич!..

Яшь сөяркә табачак, теттереп яшәячәк... Ә инде тапкан да булса?.. Бу хәтәр уй ирнең миен ярып үтте.

Уе – өенә сугылып тормау иде аның. Планлаштырылган чарага ике сәгать кенә вакыт калган. Тик шоферының:

– Кая, шеф, эшкәме? – дигән соравына катгый итеп:

– Юк, өйгә! – дип җавап бирде.

Аның күз алдыннан ямьсез күренеш йөгереп узды. Менә ул җенләнеп кайтып керә. Аяк киемнәрен салып тормый йөгереп хатынының икенче каттагы бүлмәсенә атылып керә. Юк, кергәнче сейфыннан «Тайга» атлы мылтыгын эләктерә. Хатынының түшәктә яшь ир белән сөешеп ятканын күрә. Тегеләр «Аһ» та итәлми кала, тәү ирне атып үтерә, аннары хатынын. Юк, бәлки, хатынын тәү атып үтерергәдер. Ирнең бу очракта гаебе дә юк инде ич. Бия кешнәмәсә айгыр килми, диләр ич халыкта. Анысын үтерерлек атмаска, ирлек әгъзасыннан гына мәхрүм итәргә. Йөрмәсен азып, кеше хатыннарын аздырып.

Энгель Заһидуллович дачасының тимердән бизәкләп чүкелгән капкасы янына килеп туктаганда, бераз суына төшкән иде инде. Шулай да, өенең тәүге катында Кадриясе күренмәгәч, ул йокы бүлмәсенә менде.

Хатыны чынлап та түшәгендә аунап ята иде. Ирнең куанычынадыр, берүзе генә.

– Көндезге өчтә нишләп аунап ятасың? – дип тупас кына дәште ир аңа.

– Энгельчигым, кайттыңдамыни?.. – диде, хатын бохар песие кебек киерелеп-сузылып. – Мин, кайтмассың дип, ашарга да әзерләмәгән идем бит әле. Әнә, суыткычны ачып кара, анда сервелатлар, сырлар кебек калдык-постык булырга тиеш...

Энгель Заһидулловичның бигрәк тә «Энгельчик»ка ачуы килде. Теге фахишә дә илле алты яшьлек олпат иргә «Энгельчик» дип дәшә, монда ятканы да. Ярый әле хатынын җинаять өстендә тотмады...



– Юк, ашап тормыйм, – дип тупас кына җавап бирде ул хатынына. – Минем вакытым юк, минем эшләрем күп, дәүләт эшләре... Көпә-көндез постельдә дә аунап яталмыйм. Аннары, ташла әле шул «Энгельчигыңны». Мин – дәүләт кешесе, Энгель Заһидуллович, Гапсатаров әфәнде!

– Соң, Энг... Энгель Заһидуллович, Гапсатаров әфәнде, башым авыртканга гына, тәннәрем коелып барганга гына торалмый ятам. Гафу ит инде...

Сөекле хатынының башы авырту, тәннәре коелып бару сәбәбен белсә, нишләр иде икән ир? Анысының яшь ир кочагында төн үткәргән белсә. Ярый әле белмәде. Шуның өчен «бетмәс синең башың авыртулары, тәнең коелып барулары» дигән мәгънәдә кулын гына селтәде дә, ашыгып чыгып китте.

## ЧАРАГА ӘЗЕРЛЕК

*Чара – максатның мишене.*

***Е. Колпин***

– Йә, – диде, – Гапсатаров эш бүлмәсенә килеп кереп урынына барып утыргач, артыннан ияреп кергән урынбасарына сөзеп карап. – Әзерлек ничек бара? – Үзе, зур кульяулык чыгарып, маңгаена бөрчек-бөрчек чыккан тирен сөрткәләштерде.

– Все окэй, шеф! – диде урынбасар, майлы елмаеп.

– Окэймы, окэй булмасмы – анысын инде соңыннан күрербез. Булмаса... – Түрә мәгънәле итеп тамагын кырды. – Как бы закускага кыздырылган дуңгыз бөрече урынына үзеңне согынып куярга туры килмәсен. – Гапсатаров үзенең шаяртуыннан үзе риза булып, көлеп җибәрде. Түрәсе көлүенә урынбасар кушылды.

Сайрановның йөзе айның ундүртенче кичәсе кебек балкый иде. Ала сый әзерләргә куш та, тамагыннан артып калганчы сыйланырга ирек бир, дип уйлап алды түрәсе. Әнә бит, сыйланып та җитешермәгән, йөзе каймак ялап мыекларын тазартып утырган песичекенә охшап киткән.

– Тоташ килеш кыздырылган дуңгыз бөрече дә булыр, шеф. Өстәлгә тоташ килеш томалап пешерелгән мәрсин балыгы да китерелер. Метр ярымлы. Әйдә, кунакның күзе маңгаена менсен әле.

– Мәрсин балыгы? Син нәрсә уйлап чыгардың тагы, Хатип Рәкыйпович?

Урынбасар көлеп җибәрде.

– Мәхин балыгы түгел, мәрсин балыгы. Урысчасы – осётр. Борын заманнарда сарайларында утырган патшалар гына сыйланыр затлы азык. Хәзер инде Невасында да беткән, Мәскәү елгасында да, Донында да… Иделдә дә бетеп бара. Ә безнең Шатуйда, Аллага шөкер, кайсы бер кирәкле адәмнәр өчен бар, Энгель Заһидуллович!

-Ярар, миңа табигатебезнең байлыгы турында лекция укып утырма. Мин белмим ди, имеш, осетрның күпме калуы турында да, аның кемнәр тамагына тамуы турында. Кара аны, теге вакыттагы кебек, өсталгә китереп куеп, пычак тыгуга, бар табынның ямен җибәреп, сасы ис таратмасын. Эсвижий килеш кенә әзерләсеннәр дә, эсвижий килеш кенә китерсеннәр. Тагы нәрсәләр?

– Шашлык-машлыгы, бишбармагы-кулламасы, казысы-тутырмасы, тозлысы-мозлысы, каклаганы-ысланганы, кызыл һәм кара уылдыклары, җиләк-җимеше турында сөйләп тормыйм инде, шеф. Барысы да исәпкә алынган, берсе дә онытылмаган…

Гапсатаров маңгаен җыера бирде, җилкәсен кашып алды.

– Ә әчемлек мәсьәләсе?

– Үзебезнең фирменный напиток «Шатуйская» инде.

– «Шатуйская»ң синә генә фирменный напиток ул. Аның нәрсәдән әчетелгәнен мин белмимме дә, син белмисеңме? Зәмзәмбикә карчык көмешкәсеннән әллә ни өстен сыйфаты юк.

Сайрановның йөзенә үпкәләгән бала кыяфәте чыкты.

– Ул гына дип әйтмим бит мин, Энгель Заһидуллович. Анысы для затравки гына. Биш йолдызлы әрмән коньягы да, кызыл һәм ак шәраблар да…

– Югары даирәләрдә әрмән коньягы модадан чыкты хәзер. Артта каласың, энем. Үзен ихтирам иткән дәрәҗәле кеше Шотландия виские чөмерә.

– Бигрәк кыйммәт тә инде ул, Энгель Заһидуллович! Шешәсе биш мең.

Түрә урынбасарына тәү күргәндәй аптырап карап торды.

– Хет унбиш мең булсын. Үз янчыгыңнан чыгарып түлисеңмени. Кара аны җитәрлек итеп ал. Мәҗлестә катнашканнарның берсе дә әле моңа чаклы халявадан баш тартканнары юк.

Сайранов хуҗасының сүзен хуплавын белдереп баш какты.

– Әйткәндәй, шеф, әле катнашучыларның исемлеген дә карап чыгасыбыз бар бит әле.



– Бар. Артыклары әләкмәсен, кирәкләре торып калмасын. Хәтерлисең булыр, Горбачев перестройкасы башланып, эчкечелеккә каршы көрәш җәелдереп маташканнары чагында, күрше өлкәдә булган вакыйганы.

– Кайсысын, Энгель Заһидуллович?



– Соң, шул эчкелек белән көрәшкә бәйлесен инде. Райкомның беренче секретаре белән икенчесе сәхрәгә чыгып күңел ачканнар. Үзләре белән райпо рәисен дә алганнар. Ә өченче секретарьне алырга онытканнар. Тегесе бик каты үпкәләгән, обкомга шикаять юллаткан. Ул кәгазь «Правда»ның бу төбәктәге үзхәбәрчесе кулына эләккән. Икенче көнне үк дип әйтерлек «Правда» газетендә бик каты тәнкыйть мәкаләсе дөнья күрде. Аның шау-шуы бөтен СССРга таралды. Өч көн үттемекими, тегеләрне партбилетларыннан мәхрүм итеп, арт якларына типтеләр.

– Өчесендәме, Энгель Заһидуллович?

– Дүртесен дә. Әлләә шикаятьчесен урынында калдырганнар дип беләсеңме? Мораль: банкет-манкеттан бер кирәкле кешене дә онытып калдырырга ярамый. Хәтта ул вакытларның инде үткәнлеге исте тотканда да. Онытуыңның күсәге үз маңгаеңа бәрергә мөмкин. Йә, исемлекне карап чыгыйк әле.

Сайранов түш кесәсеннән таушалып беткән кәгазь кисәге чыгарды.

– Сез, мин, Энгель Заһидуллович. Аннары шәһәр кунагы, фольклорчы (бу урында урынбасар мыскыллы елмайды) Әюпов Фарук Йосыфович. Анысын алып киткәч, фатиры хуҗасыГабделбәр картны да калдырып булмый бит инде. Кәнишне, булачак табында лишний кеше.

Энгель Заһидуллович борынын җыерды.

– Әйе, нежелательный. Высший классның ничегрәк типтергәнен бөтен шәһәргә сөйләп йөрсенме… Тик…

– Тик шул, шеф. Банкетның СССР Коралды Көчләре ветераны Габделбәр Шәмигулла улы Сәйфелмәлековка дәүләт наградасы тапшыру хөрмәтенә оештырылуын онытып җибәрмик.

– Ярар, әлеге тантаналы кичәнең секретный чара булуы турында мин аңа үзем кисәтермен. Атом бомбасын сынау секрет булган

бит. Безнең әлеге банкетыбыз да шул атом бомбасы сынаугә бәрабәр дип аңлатырмын. Әй, юк ла... Олы башым белән вакланып утыру миңа килешмәс, шәһәребезнең КГБ... тфү, шушы каһәрле сүз әллә кайдан тел очына килеп эләгә... ФСБ хуҗасы Бородулинга йөкләтербез. Хет шунда «обязательство о неразглашении»гә карттан кул куйдырмыймы...

– Ничек, аны да чакырабызмыни, Энгель Заһидуллович? Күпкә китә бит әле...

– Син – надан, дисәм инде, энем, үпкәләрсең. Төп кунагыбызның шушы ведомствога мөнәсәбәте барлыгын онытып җибәрәсең, ахрысы. Югыйсә, фольклорчы, имеш. Ул фольклорчы булса, мин – Америка президенты! – Түрә үз шаяртуыннан үзе риза булып көлеп җибәрде.

Аңа урынбасары кушылды.

– Димәк, Бородулин Яков Иванович, Энгель Заһидуллович.

Шушы чак кабинет ишеге ачылып китте. Анда тәү секретарь хатынның зур түше күренде, аннан эшлекле йөзе, куәтле гәүдәсе пәйда булды. Түрә әле елмаю китеп бетмәгән йөзен аңа табан борды, кашларын җыера бирде.

– Ни булды, Руфина Хөршатовна ?

– Энгель Заһидуллович, приемныйда водоканал хуҗасы Гаврилов. Срочно ярдәм кирәк, ди. Авария, ди. Калдык сулар Шатуйны пычрата, ди....

Шәһәр хуҗасының йөзе тәмам бозылды.

– Күрмисеңмени, монда без дәүләт әһәмиятендәге эш белән мәшгульбез. Канализация, имеш, Шатуй,имеш... Бер Бирдәшнең генә калдык сулары Каспий диңгезен әллә нишләтә алмас әле.Гони к черту Гаврилова. Кирәк икән, иртәгә килер. Әйт, бик иртә йөрмәсен. Иртән баш... (ул чак кына «баш авыртачак» дип әйтеп ташламады) башка мөһимрәк эшләр бар.

Секретарь чыгып китте. Шәһәр хуҗасы карашын урынбасарына юнәлтте.

– Бородулинда тукталдыкмы әле?

– Әйе, подполковник Бородулинда.

– Туктале, Рәкыйпович, Руфина бөтен зиһенемне таркатып чыгып китте. Водоканалның пычрагы Шатуйга безнең кунак йортыннан өстә агып төшәме, әллә астамы?

– Аста, Энгель Заһидуллович.

– Алай булса... әйдә аксын. Икс-өч көн акканнан берни дә булмас.



Тәк, подполковник Бородулин, аның янына подполковник Самохваловны да өстибез инде. Күптән полковник булырга хыяллана, бәлки, кунак белән файдалы связь булдырып кала алыр.

– Ә судья белән прокурорны нишләтәбез, Энгель Заһидуллович?

– Алары само собой разумеется. Халявага сыйланырга алар да бик ярата. Шуннан... берчак көнебез алар кулына калып куерын да онытып ташларга ярамый, туган.

– Шуның белән вәссаламдыр бит инде, шеф.

– Син нәрсә, акча янчыгы Иранданы кая куясың?

– Хрипуновнамыни, шеф? Аны чакырмый ярамый шул. Тик гел ирләр арасында бер генә бичә була бит әле.

– Куркма, хәмерис ул ирләрдән дә болайрак чөмерә. Исереп алса, ирләргә бәйләнү гадәте дә бар. Сакланыңкыра, үзеңне куак астына алып кереп көчләп куймасын.

Бу юлы инде ике ирнең көлешүеннән Гапсатаровның баш очында гына эленеп торган хрусталь люстра өзелеп төшә язды. Түрә үзе моны сизмәде дә, урынбасарының башына кызык кына уй килә биреп куйды.

Люстра ычкынып төшеп, Гапсатаров җан тәслим кылса, урынына Сайрановны куяр иделәр микән, әллә Кудеярдан берәр этрәкләм китерерләрме? Гапсатаровның җәрәхәте «бытовая травма» исәпләнерме, әллә «травма на производстве»гә керерме?

– Шуның белән тәмамладыкмы инде, Энгель Заһидуллович?

Мәр уйлана бирде.

– Ә кызлар турында ничегрәк уйлыйсың, Рәкыйпович?

– Читен мәсьәлә, шеф. Габделбәр картка инде кызни дә, үзе кебек комы коелган корткамыни. Кунак әле гайрәтле күренә. Әмма баш тартса, безгә уңайсыз булачак. Үзебезгә...

– Үзебезгә, үзебезгә... – Түрә, кичәге уңышсызлыгын исенә төшереп, кызып китә язды. – Бер кичкә түзәрсең. Шулай да запасной вариант кирәк. Безнең кунак йортыннан ерак түгел Самохваловның дачасы бар бит. Әйткәндәй, чарабызны шунда үткәрергә дә тәкъдим иткән иде. Кызларыңның төяге шунда булыр. Әйдә, шампан чөмерсеннәр дә, бассейнда чаптырдасыннар. Кирәкләре чыгып куйса инде...

– Тагын бер мәсьәлә калды бит әле, шеф, – диде урынбасар, җилкәсен кашый биреп. – Банкетта тамада үзегез булырсыз микән?

– Син нәрсә, энем, мине хезмәтче малай урынына куясың? Мәҗлесне алып бару – ул синең эш. Кара аны , авызыңнан чыккан

һәрбер сүз чәпкә тиярлек булсын. Кунак ның безнең шәһәргә килү максатын без яхшы да белмибез. «Фольклорчы»га әкият сөйләп утырмассың, әмма төрле мәкальләр, әйтемнәр, башка чурт-чурамандырыңны җаллама.

–Анекдотлардыр да инде?

– Чамалап кына анекдотларны да кыстыр. Алар бит хәзерге заманның төп фольклоры.

– Кичә генә ишеткән бер анекдотны сөйлимсәм, шеф. «Ире командировкадан кайтып кергән, имеш...»

– Ташла әле шул бозык хатыннар турындагы мәзәкләреңне!..

– Алайса... Чукчалар турындагылары искерде инде. Бәлки, милиционерлар турындагыларыңдыр.

– Нәрсә, ришвәтче милиционерлар турында сөйләп, Самохваловны фашларга уйлыйсыңмы?

– Юк ла. Миндә намуслы милиционерлар турындагысы да бар. Тәмам хәерчелеккә төшкән бер карт ахшам намазын укып утыра ди. Намазының төп өлешен тәмамлагач, Аллага үтенечен җиткерергә дә онытмаган икән: «Игелеклеләрдән игелекле Ходаем! Пенсиям бәләкәй, ишәүләре бигрәк авырайды. Хет бер ун мең белән генә булса да ярдәм итәр идең!..» Өмәлгә каршы бу җәйге кичтә картның тәрәзәсе ачып куелган булган, һәм аның догасын тәмәке көйрәтеп торган ике постовой милиционер ишеткән. «Әйдә, картны кызык итәбез. Кесәңдә күпме акчаң бар?» – дигән берсе. «Өч мең, – дигән икенчесе. – Ә нәрсә?» «Шуңа минем кесәдәге дүрт меңне кушабыз да, Алла сиңа ярдәм җибәрде дип, картка кертеп бирәбез». Тегесе ризалашкан. Шулай картны кызык иткәннәр. Икенче көн ахшам намазы вакытында болар тагы әлеге тәрәзә астына килеп басканнар. Карт дога кыла икән: «И кодрәтлеләрдән кодрәтле Аллам! Рәхмәт сиңа ярдәмең өчен! Тик син инде акчаңны милиционерларга биреп җибәрмә. Югыйсә, кичә өч меңеңне йомып калдылар...»

Урынбасар бу мәзәкне үзе сөйләде дә, үзе кычкырып көлеп җибәрде. Аның көлүенә түрәсе дә кушылган булды. Тик капыл гына көлүеннән туктады да, кырыс карашын урынбасарына юнәлтте.

– Милиционерларның шаяртуы, бәлки, яхшыдыр да, әмма картның хәерчелеккә төшүе начар. Кунак моннан нинди нәтиҗә чыгарыр? Шуның өчен мәзәк сөйләгәндә дә, авызыңны үлчәп ач, энем. Безнең шәһәрдә хәерче картлар юк!..



# ГАБДЕЛБӘР КАРТНЫ ЗУРЛАУ ТАНТАНАСЫ

*Хәтта дөя дә сыңа бер күчеп ача.*

***Адыгей мәкале***

Тантанага барырга чыккач, Гапсатаровның күтәренке кәефен ике нәрсә боза язды. Ярый әле хакимият йортыннан ерак китеп җитмәгән иделәр, ул «шап» итеп маңгаена сукты, шоферына туктарга әмер бирде.

– Военкомны оныткансыз ич, Хатип Рәкыйпович! СССР Кораллы Көчләре ветеранына награда тапшырырга барабыз, хәрби комиссар юк.

Тиз генә аның номерын җый әле.

Сайранов кесә телефонын чыгарып, номер җыйды. Ярый әле майор Ерохинның телефоны шунда ук җавап бирде.

– Тыңлыйм, Хатип Рәкыйпович.

– Трубканы шефка бирәм, Семен Кириллович.

Гапсатаров, йөзенә усал төс чыгарып телефонга дәште.

– Ты, где болтаешься, майор?

Әгәр ул эш урынында булып, хезмәткә чакырылучылар белән патриотик әңгәмә корып утырган, йә һич югында «Красная звезда» гәзитенең чираттагы кроссвордын чишеп утырган булса, бу тупас сүзгә үпкәләр иде.

Трубка азмы-күпме шытырдап торды, аннары хәрби комиссар:

– Балыкка чыккан идем, Энгель Заһидуллович, – дип кыюсыз гына җавап бирде.

–Шәһәрдән еракмы?

– Юк.

– Киемең алам-саламмы?

– Алам-салам инде. Тик мин бит машинамда һәрчак формамны да йөртәм. Рыбнадзор килеп чыгып бәйләнә башласа...

– Вот что, майор, немедленно облачись в свою майорскую форму и дуй в город. Себер урамына, ветеран Сәйфелмөлеков йортына. Тебе – на все пятнадцать минут!..

Гапсатаров, зур эш башкарган кыяфәт белән, кульяулыгын чыгарып тирле пеләшен сөртте. Мин булмасам, нишләрләр иде икән, дип үз алдына сөйләнеп алды.

Тик юлларында тагы бер тоткарлык туды. Карл Маркс урамына Анатолий Чубайс тыкрыгы килеп кушылган почмакта чүп-чар контейнеры янында өч сәләмә киенгән ир алып-биреп сугышып ята иде. Джипны тагын туктатырга туры килде.

– Бу нинди мәхшәр, Хатип Рәкыйпович? – дип җикереп үк җибәрде шәһәр башлыгы. Төш тә, тиз генә разберись!

– Хәзер полиция чакыртам! – дип куркыткач, тегеләр сугыш мәйданын шунда ук ташлап качтылар.

– Нәрсә, алкашлармыни? – дип каршы алды хуҗа урынбасарын. – Нигә сугышалар?..

– Бомжлар, – диде урынбасар, урынына утырып тынычлана биргәч, – чүп-чар контейнерын бүлешә алмый сугышалар. Контейнерлардагы калдык-постык белән тукланып көн күрүче этрәк-әләмнәр...

– Алары да Кырым чирүедәй үрчеделәр, дип мыгырданды шәһәр хуҗасы. – Хет барысын җый да, йөк вагоннарына төяп җәһәннәм тишегенә олактыр... Шәһәребезне позорить итәләр.

Урынбасар бу сүзләргә кушылмас та иде, бәлки, тик аларны нигәдер үзенә карата юнәлтелгән тәнкыйть итеп кабул итте.

– Эшсезләр күбәйде бит, Энгель Зәһидуллович. Химия комбинатын яптык, спирт-аракы комбинатын яптык, шикәр заводын яптык,Кирпеч заводын...

Шәһәр башлыгы кызып китеп үк урынбасарын бүлдерде.

– Син нәрсә хилаф сүз сөйлисең. Яптык та яптык... Заманы сәясәте шундый булгач... Иртәгә үк ул контейнерларны үзәк урамнардан чит тыкрыкларга аткарт. Сугышалар икән, шунда сугышсыннар! Шәһәребезнең ямьле күренешен бозмасыннар!

...Төрле илләрдә йөреп, төрле халыкларның төрле чараларында катнашып, Фарук Йосыповичка бик күп галәмәтләр күрергә туры килде. Ашату-эчерүләрен генә дә искә алса да. Бер Африка илендә, мактап-мактап, аны кыздырылган кобра ите белән сыйладылар. Икенчесендә, бик тәмле азык дип ашаган иде, аның кыздырылган саранча булып чыкты. Крокодил итен дә авыз итәргә туры килде аңа. Тәме үрдәк ите тәменнән әллә ни аерылмый аерылулыкка, бик үзенчәлекле соусы, урыс сатиригы сүзләре белән әйткәндә «специфический вкусәжка» ия. Тик, ашап торгач, ул, кызыксынып, учак эргәсендә үз эшен дәвам итүче пешекче негр янына килде. Аның чираттагы порцияне «тәмләтү» белән шөгыльләнә иде. Ниндидер агач яфрагын



авызын тутырып чәйни-чәйни дә әлеге кыздырылган крокодил итенә төкерә, чәйни-чәйни дә төкерә... Саранча ашап укшымаган иде, Бу юлы укшыды, читкәрәк китеп ашказанын бушатырга туры килде. Кореяда эт ите ашарга туры килде аңа, Вьетнамда – маймыл мие, чи килеш. Франциядә – бака боты...

Ә инде бәйрәм чараларының төрлелеге... Дипломатик сөйләшүләрнең киеренкелеге... Гражданнар сугышы барган банан республикаларына керү, чыгу юлларының хәвефлелеге...

Габделбәр карт андый тантаналарда да булмаган, андый бәлаларга да тарымаган. Шул Тоцк далаларында атом бомбасы сынавын искә алмаганда. Тәү монда китерелгән солдатлардан әллә нинди корылмалар төзеттеләр, араннар ясаттылар. Аннары көтү-көтү малларны куып китереп шул араннарга яптырдылар. Солдат мескеннәр бу эшләрнең нигә башкарылганын аңламый иде әле. Дәүләт сере шул! Аннары аларны төп объекттан әллә ничәмәләр чакрым ераклыктагы ныгытмалар артына яшерендерделәр. Шартлавын сөйләп аңлатырлык түгел иде инде. Күпләр аны заман ахры җитүе итеп кабул иткәндер. Теге төнне Теләкбирде ихатасында күзәткән табигать күренеше Тоцк гарәсәтенә охшаса бераз охшагандыр. Соңыннан ул мәхшәр турында сөйләнеп йөрмәскә солдатлардан кул да куйдырдылар бит. Сөйләнмәделәр. Түзделәр. Бүген килеп әйтерләргә дә, сөйләргә дә ярый икән, ләбаса. Хәтерләү генә түгел, хәтта Тоцк вакыйгаларында катнашучыларга медаль тапшырырга да ярый икән. «За участие в испытаниях ядерного оружия СССР».

Бүген иртән Бидрәш мэрының урынбасары Сайранов үзе килеп шушы хөкүмәт наградасын тапшыру тантанасы булачагын яңадан кисәтеп куйды.

– Сәгать кичке алтыда өегездә булыгыз, Габделбәр Шәмигуллович, – диде ул, картның йортын күз алдыннан үткәреп. – Мэр Гапсатаров үзе киләчәк. Аннары кунакның кулын кысты. – Ә сезнең, Фарук Йосыфович, бу тантанада катнашуыгызны безнең шәһәребезгә, аның бер мактаулы ветеранына хөрмәт күрсәтүегез дип кабул итәчәкбез. Энгель Зәһидуллович үзе шулай дип әйтергә кушты!

– Әйе, – дип көрсенде Габделбәр карт, эшлекле адәмне капкасы төбенә чаклы озаткач, – Медален дә тапшырырлар, кулымны да кысарлар... Тик, килгән түрәне пүнәтәйләре белән бергә болай гына да озатып булмый бит әле. Сый өстәле әзерләргә кирәк булыр инде, Фарук энем. Ярый, каклаган каз салдым ди, каз янына тозлысын-

мозлысын, әчесен төчесен әзерләп куйдым ди. Әчесе дигәннән, үземнең төннә куганым ярар микән, әллә кибеттән берәр шешә «Шатуйский»ны да алып кайтыргамы? Вәт, аларда медаль тапшыру кайгысы, миндә кунак каршы алу кайгысы…

Фарук Йосыфович картның бу сөйләнүләрен елмаеп тыңлады. Бүләк тапшыруда, аны юу табынында катнашкалаганы бар иде аның. Әлеге төрле кыйтгалардагы сыйлануларын искә төшереп утыруы да, бәлки, бүген узачак чара белән бәйле булгандыр. Урыс иле әллә кайсы Африка илләренең артык бай әшәми, әмма хөкүмәт бюджеты исәбенә сыйлау-сыйлану мәсьәләләрендә теләсә кайсы илләрнең борынына чиртә иңде. Һәр хәлдә бака боты согындырмыйлар, шул баканың өлкән агасы крокодил биләмәсе белән сыйламыйлар. Фарук Йосыфович бер нәрсәне аңлады: бүген Бидрәш шәһәре хуҗаларына менә шушы күбенгәнче бушлай сыйлану форсаты чыгып тора. Алар бу форсатны ике йөз проценты белән файдаланырга әзерләр. Тик бер нәрсә эчен пошыра бирде аның. Габделбәр картка да, аның медален дә текерде ди алар. Берәр йомышчыларын җибәрерләр иде дә, кулына тоттырырлар да китәрләр иде. Шәһәр кунагы, чыгып та, фольклор җыючы бер этрок-әлем булса, ана да текерерләр иде. Юк шул. Ул Бидрәшкә килеп өлгермәде, аның кем икәнен белеп тә өлгерделәр. Күпме илләрдә йөреп, мондый фашлануга тарыганы юк иде әле аның. Ярый командировкасы – ФСБ заданиесе түгел, бары Кудеяр өлкәсе губернаторы Буйновский Аристарх Федоровичның шәхси үтенече генә. Кемнәдер фашлану, кемнедер төрмәгә утырту бурычы да тормый аның алдында. Бары күзәтү, анализлау, нәтиҗәләр чыгару гына. Әлеге тантанада катнашуы да менә шушы бурычына буйсынадыр…

Бидрәштә нинди дер кәсәфәт булган: табигать шаяруымы бу, инопланетяннар эшмәкәрлегеме, әллә җен-пәриләр эшлегеме? Гомере буе атеизм рухында тәрбияләнгән Фарук Йосыфович өченче пунктны сызып та ташлый ала. Ә Габделбәр картның Тәвеш авылыннан шәһәр өстендәге гарәсәтне күзәтүен кайда куясың? Ә ГИБДДшникларның күптән юкка чыккан каланчада постта торулары, үзләрен полиция дип түгел, милиция дип атаулары? Ә күптән юкка чыккан мал симертү комплексында аның директоры Букреев белән, элекке парторгы Садрыйның син дә мин йөреп ятуы? Ә үле спиртзаводның «терелүе»? Һәм, ниһаять, Бидрәш мэры Гапсатаровның капыл гына беренче секретарьгә әйләнеп, симертелмәгән маллар, булмаган ит турында Кудеяр губернаторына биргән рапорты? Ярый әле бу



галәмәтләр ике көн эчендә Бидрәш тормышында әллә ни эз калдырмый юкка чыктылар.

Американың Алабама штатында булганда, ул үзебезнең ил астрофизигы Блюменталь белән танышкан иде. Яһүд – яһүд инде. Үз фәненең бөтен нечкәлекләренә үтеп кергән галим. Альберт Эйнштейнның эшен дәвам итүче. Хәтере ялгышмаса, галим анда, үзенең сүзләре белән әйткәндә, «Вакыт» атлы субстанциягә бәйле бик сәер бер вакыйганы өйрәнә иде. Фарук Йосыфович физик та, астроном да, астрофизик та түгел, бу гаҗәп вакыйганың ваклыкларын бик белеп бетерми. Әмма бер самолётның ике йөз сиксән пассажиры белән Алабама аэропортыннан күтәрелүе, һәм радарлардан юкка чыгуы, бер ай үткәч нинди дер гыйлләт белән шул ук аэропортта хасил булуы сенсациясе иде.

Блюменталь белән алар гостиница ресторанында бер өстәл артында туры килделәр. Сүздән сүз чыгып, байтак мәсьәләләрдә фикердәшләр икәнлегенә инандылар. Көн саен кичләрен аш өстәле артында аралаштылар. Бер-берсенең бүлмәсенә йөреп шахмат уйнадылар. Телефоннарын алыштылар. Шалтырашканнары юк иде әле. Фарук Йосыфович, моны исенә төшереп, капыл гына кесәсеннән телефонын чыгарды. Мәскәүдә микән, әллә һаман җәһәннәм тишегендә «Вакыт» атлы субстанция» артыннан куып маташа микән?

Көтмәгән дә иде, телефон Блюментальнең карлыкканрак тавышы белән җавап бирде.

– Фарук Йосыфович! Сколько лет, сколько зим. Кайдасың?

– Туган җирем Кудеяр өлкәсендә, Арий Аронович. Дөресрәге, үз туган шәһәрем Бидрәштә. Ә син кайда?

– Тагы да җәһәннәм тишегендә инде, Камчаткада. Булганың бармы монда?

– Бар Җир шарын урап чыктым, Арий Аронович, әмма үзебезнең Камчаткада булганым юк икән ич.

– Күпмене югалткансың, Фарук Йосыфович. Бик үзенчәлекле, сихерле табигать бит. Мин монда әлеге үзенчәлекләрнең «Вакыт» субстанциясе» белән бәйләнешен өйрәнеп маташам. Күзәтүләрем турында сөйләсәм, исең китәр…

– Кара әле, Арий Аронович, анда, Петропавловск-Камчатскийда минем балалык дустым Салим Сәйфелмөлеков та яшәп ята бит.

– Салим Габдульбарович? Известный геолог? Знаю! Его знает весь Камчатский край. Интересный ученый. Безнең байтак күзәтүләребез, ачышларыбыз бер-берсенә бик якын килә…

– Ярар, аңа сәлам тапшырыгыз. Вот, монда, безнең Бидрәшебездә дә, произошло интересное природное явление. Сөйләсәм, исең китәр.

Фарук Йосыфович яһүд дустына Бидрәштәге хәлләрне кыскача гына бәян итте.

– Менә шулай, Арий Аронович, Бидрәш сагашып алды әле, – дип сүзен очлады.

Анысы уйланып торгандай булды. Аннары капыл гына:

– Вакыт сикереше! – дип нәтиҗә ясады. Вакыт бит ул елга кебек. Ага да ага, ага да ага. Кайчагында зур борылыш ясап, кирегә киткәндәй була да, аннары янадан үз юнәлешенә төшә. Теге чак Алабамадагы кебек. Кайчагында тын гына аккан җирендә шарлавык хасил итеп аз-маз сикергәләп ала. Димәк, сездә ул җиңелчә сикергәләп алган да, аннары үз ызанына кайткан. Әллә ни зур зыяны юк. Әмма көзен мин Салим дустың белән бергә Бидрәшеңә барып, бу катаклизмның последствияләрен өйрәнәчәкмен әле. Өчәүләп очрашырбыз анда.

...Фарук Йосыфович Габделбәр карт белән башлаган әңгәмәсен дәвам итте.

– Син нәрсә, Габделбәр абзый. Бидрәш мәрының синең каклаган казың белән «тәнен куган»ына калган көне бар, дисеңме? Хафаланма, уңайдан файдаланып, әллә нинди сыйлар әзерлиләрдер инде. Бүген тамакларыбыз сыйлы булачак.

Карт кунагының сүзләрендә ниндидер үзе төшенеп җитмәгән дөреслек булуын аңгарды. Ә төштән соң аның йорты тирәсендә башланган ыгы-зыгы менә шушы уеның дөреслеген исбатлый барды.

Тәү зур, кызыл машиналарында янгын сүндерүчеләр килеп китте. Якын тирәдә бернинди төтен чыкмавы, бернинди ялкын күренмәвенә карамастан, ниш... машиналарын үкертә-үкертә килделәр. Тик шлангларын сузып, янмаган өйгә су сиптереп маташмадылар, бары янгынга каршы хәвефсезлек чаралары белән генә кызыксындылар. Алар китү белән Габделбәр картның капка төбендә санэпидемстанция машинасы туктады. Инспектор, сары чәчле юан марҗа, хуҗаның йорт-курасын карап чыкты. Әллә ни житешсезлек таба алмады булса кирәк, бары казларына болгау сала торган улакны тазартып куярга кушты. Хәер, каңгылдашып, итәген тарткалаган сөмсез кошларны да чара үткәнче каядыр куярга боерды.

– Тантананың бөтен ямен җибәрәчәкләр бит! – диде ул, очлы борынын җыерып.



Шушындый әһәмиятле вакыйгалардан күрше бичә Хөршидә читтә калмыйы соң. Ул инде күптән Габделбәр карт белән Фарук Йосыфович тирәсендә чуала иде.

– Минем ихатага куып кертеп торырбыз аларны. Тыннарын да чыгартмам, – дип бу мәсьәләне дә чишешеп куйды уңган бичә.

Санэпидстанция машинасы китеп озак та үтмәде, ихатада ак халатлы ике бичә пәйда булды. Колгадай озыны Габделбәр картның култык астына термометр тыкты, гәүдәгә кечкенәсе аның күкрәк җиңен күтәртеп, кан басымын тикшерергә тотынды. Икесе дә күрсәткеч нәтиҗәләре белән разый калдылар.

– Утыз алты да биш, – диде озыны.

– Йөз егермегә сиксән, – диде кыскасы.

– Оһо! – диделәр икәүләп, – Сине бит, карт, бүгеннән космоска очырып була.

Карт көлеп җибәрде.

– Очырасызмы? Очам!

Фарук Йосыфович бу күренешне елмаеп күзәтте.

– Әйтегез әле, кызлар. Сез шәһәрегездәге барлык картларга карата да шушылай игътибарлысызмы?

– Юк ла, начальство кушканга гына... – дип башлаган иде кече гәүдәлесе, аны усал карашы белән озыны бүлдерде.

– Әйе, игътибарлыбыз. Ветераны всегда в... поле нашего внимания!

Ак халатлылар, кызыл тәре төшкән машиналарына утырып, китеп югалдылар.

– Дөньяда сиксән ел яшәп, мондый галәмәтне күргән юк иде әле, – диде Габделбәр карт, утырып, бераз тын алгач. – Ни булган боларга? Әллә, чынлап та, мине, сынау өчен, җиһанга аткарырга уйлыйлармы? Кызык булачак иң! Американнарның тагы борыннарына чиртәчәкбез. Алар җибәрәлми, без җибәрәбез сиксән яшьлек картны...

– Ярар, тынычлан, Габделбәр абзый, рекорд куярга ашыкма. Үзең әйтә торган идең бит әле: «Һәр эшнең бер әтнәкәсе була». Әтнәкәсен соңрак күрербез...

Төш кичкә авышкач, Габделбәр картның капка төбендә укучы балалар җыелды. Пионерлар дисәң инде, муеннарына элеккечә кызыл галстук түгел, чуар галстук такканнар. Кызыллы, зәңгәрле, аклы, Рәсәй флагы төсендә. Кулларында барабан, быргылары юк, әмма тавышлары чиксез яңгыравыклы. Фарук Йосыфович белән Габделбәр карт алар янына чыктылар.

– Исәнмесез, балалар!

Балалар әле тынычланып өлгермәгән иде, чыр-чу киләләр. Ике өлкәннең сулъямына житәкче кыз бала, ул да чуар галстук таккан, җавап кайтарды.

– Исәнмесез, ветеран бабайлар!

Габделбәр карт әдәп саклап тормады.

– Нишләп йөрисез бу уттай кызу (башын күтәреп аяусыз кыздырган кояшка карап алды) эш көнендә чыр-чулашып?

– Сезне югары хөкүмәт наградасына лаек булуыгыз белән тәбрикләргә килдек, бабай.

– Соң, тәбрикләгез дә, шылыгыз инде моннан. Эсседә әлсерәп тормагыз.

– Ю-ук, бабай, – дип елмайды җитәкче кыз, – безнең бит шәһәр туралерен көтеп аласы, сценарийга яраклы тантаналы митингта катнашасы бар.

Карт, аптыраганын белдереп, ике ботына ике учын шапылдатып сугып алды.

Фарук Йосыфовичка кызның мөләем йөзе ничектер таныш кебек тоелды. Кайда күрде икән? Хәер, ул әллә кайларда, кыз бала монда – кайда күрсен инде? Түзмәде:

– Исемегез ничек соң сезнең, вожатый апа? – диде Фарук Йосыфович, кыз янына килеп.

Кыз елмайды, алсу битенең ике ягында да матур чокыр хасил булды. Ирнең хәтеренә нидер төшә бирен куйды.

– Минем исемем, абый Сәрия була. Шәһәребезнең беренче мәктәбендә тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшлим.

– Ә әтиегезнең исеме! Директор урынбасарына мин авыз күтәреп «Сәрия» дип кенә дәшәлмим бит инде.

Кыз кычкырып көлеп җибәрде.

– Шулай дип кенә дәшсәгез, минем күңелемә ятышлырак та була бит абый. Ә болай… мәрхүм әтиемне «Мәхмүт» дип атый торганнар иде.

– Димәк, Сәрия Мәхмүтовна… Матур яңгырый!.. Ә әниең исәнме?

Кыз житдиләнә бирде.

– Әнием исән. Зөбәйдә Зәйнулловна. Гомере буе мәктәптә эшләде. Әле пенсиядә. Берүзен калдырмас өчен укыргә очно керә алмадым. Әле педагогика университетын читтән торып тәмамлап йөрим.



Фарук Йосыфовичның мие яшендәй ярып бер уй йөгереп үтте. Зөбәйдә Зәйнулловна? Зөбәйдә! Менә кемгә охшаган икән әлеге алчак кыз. Аның сыйныфташына. Сыйныфташы гына түгел, балалык дусты, үсмер чагында тәүге мәхәббәт хисе уяткан кызга.

– Ә мин…

– Беләм инде, беләм инде, абый. Сез Әюпов атлы зур кеше буласыз.

Әнинең сыйныфташы. Бу тантананы да әллә пенсиядәге малчы Габделбәр карт хөрмәтенә оештырганнар дип беләсезме? Сезнең күзегезгә төтен җибәрү өчен оештырдылар бит аны.

Фарук Йосыфович көлеп җибәрде. Менә сиңа мә! Шәһәр җитәкчелегенең бар хәйләсен бу кыз ачты да бирде ич! Сәрия аның көлүенә кушылды.

– Әгәр форсат табалсагыз, әни безгә сугылып чыгуыгызны сорады.

– Килем, – диде Фарук Йосыфович, уйланып та тормый. – Әгәр мөмкин булса, иртәгә сәгать уннарда.

– Көтәбез, Фарук абый.

Үзе түземсезләнгән укучылары ягына борылды, аларга тезелергә әмер бирде.

– Йә әле, репетиция ясап карыйк, балалар. Ничек каршы алабыз мэрны? Хор белән. Бер, ике… «Здравствуйте мэр нашего славного города Бедряшево товарищ Гапсатаров Энгель Заһидул-лович!» Хор бик тигез килеп чыкмады. Вожатый ризасызлык белдерде.

– Это не приветствие, ребята. Давайте стройнее и громче! Потом… я ведь вам уже сказала: сейчас уже не принято обращаться «товарищ», этого мэр не любит. Я своими ушами слышала как к одному обратившемуся к нему он сделал замечание: «Гусь свинье не товарищ!»



Шушы урында бер сипкелле малай вожатыйга сорау бирде:

– Апа-апа, монда кем каз, кем дуңгыз була инде?

Сәрия апалары каушабрак калды, булса кирәк. Аның карауы бер яңгыравык тавышлы кыз җавапны тиз тапты.

– Монысы инде само собой разумеется: мэр – дуңгыз, без – казлар. – Монысы инде… урамны яңгыратты. Җитмәсә бу балаларның көлешү тавышы бар урамны яңгыратты. Җитмәсә бу Балаларның көлешү тавышы бар урамны яңгыратты. Җитмәсә бу

Сәрия Мәхмүтовна апалары, ниһаять, төркемдә тәртип урнаштыра алды.

– Господин Гапсатаров Энгель Заһидуллович дип әйтәбез, балалар. Господин дип. Ә сез, – дип эндәште ул әлеге чуар битле малай белән яңгыравыклы тавышлы кызга, – ятладыгызмы данлыклы якташыбыз Сәйфелмөлеков Габделбәр Шәмигулла улының биографиясен. Медаль тапшыру алдыннан тотлыкмыйча кычкырып сөйлисез. Тик... аны инде «Сәйфелмөлеков әфәнде» дип атый күрмәгез. Иптәш Сәйфелмөлеков...

– Әйе, апа, – дип аның сүзен хуплагандай булды сипкелле малай, – Ветеран Вооруженных сил, ветеран труда Сайфульмулюков к мэру города Гапсатарову не товарищ...

– Ярар, Хәкимов, артыгын сөйләнмә, – дип аны тыеп куйды апалары. Күп сөйлисең... Артыгын сөйләгән – авырмый үлгән. Ә хәзер чакыруыбызны кабатлап карыйк: «Юные пионеры! К борьбе за дело процветания нашего славного города Бедряшево будьте готовы!» «Всегда готовы!».

Әзерлек эшләрен тәмамлагач, Сәрия бу күренешне кызыгып күзәтеп торган Фарук Йосыфович ягына борылды.

– Менә шулай инде, Фарук абый, кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың.

– Ничего, Сәрия туган. Балаларыгыз чос күренә. Аллага шөкер, алар икенче җырларга да өйрәнә икән. Бу – җырламасалар да күренеп тора.

Балалар тагы өч-дүрт мәртәбә репитиция ясап өлгерделәр әле: «От имени юных жителей... приветствуем... тов... господина Гапсатарова!»

Ниһаять, Себер урамына Карл Маркс урамы килеп тоташкан почмактан мэрның кара үгездәй кара машинасы килеп чыкты. Танк диярсең. Аның артыннан шәһәр түрәләренең «Вольво»лары, «Форд»лары, «Фольксваген»нары, тагы әллә нинди, әллә нинди чит ил галәмәтләре ияргән иде.

Себер урамы моңа чаклы мондый кавалькаданы күргәне булмады. Шуңа күрә кешеләр капкаларыннан чыгып, гаҗәпләнеп, бу күренешне күзәттеләр, әбиләр белгән догаларын укыды. Йә Ходаем, әллә сугыш чыктымы икән? Әллә Бидрәшкә Рәсәй патшасы үзенең дусты Әмрикә президентын ияртеп дуслык визиты белән килгәнме? Булмас, дип әйтмә. Бик борынгы, бик танылган шәһәр бит ул Бидрәш! Аның мэры гына да ни тора! Советлар вакытында эшләде,



перестройка атлы галәмәте башлангач, урынында торып кала алды, Ельцин мәртәт, урыны оҗмахта булыры, властьтан киткәч, эшләде. Өлкә губернаторы Монастырев җәһәннәм тишегенә олакгач, һаман эшләвен дәвам итә... Димәк, Бидрәшкә әллә кемнәр килсә дә, ул мах бирерлек түгел...

Болары – Бидрәш шәһәренең Себер урамында яшәүче кайсы бер адәмнәренең пешер-пешмәс фикерләре генә.

– Киләләр! Киләләр! – дип капыл кычкырып җибәрде әлеге сипкелле малай.

Көтүдән ялыгып, эсседән әлсерәгән халыкны уятты бу чакыру.

Шәһәр мэры, үз кадерен үзе белгән кыяфәт белән, әй генә машинасыннан төште, авыз чите белән генә елмайгандай булып балаларның тәбриген тыңлады, Фарук Йосыфовичны кочаклады, тулы, кытырап торган битен аның какча яңагына өч мәртәбә тигезеп алды, Габделбәр картның сузган куш учына битараф кына сул кулын салды. Ул арада берәм-берәм машиналарыннан төшкән түрәләрне ияртеп, ихата эченә узды.

Балалар «П» хәрефе рәвешендә тезелде, халык арттарак урын алды.

– СССР Кораллы Көчләре һәм хезмәт ветераны Сәйфелмөлеков Габделбәр Шәмигулла улына югары хөкүмәт наградасы тапшыруга арналган митингны ачык дип игълан итәм! – дип башлап җибәрде тантананы Гапсатаровның алыштыргысыз урынбасары Сайранов. Аның тавышы яңгыравыклы һәм тантаналы иде. – Иң башта сүзне ветеранны тәбрикләргә килгән балаларга бирәбез.

Арттарак торган төркемнән кул чабулар яңгырады. Пионерларның тигез рәтеннән ике бала алгарак чыкты. Әлеге дә баягы шул сипкелле малай белән яңгыравыклы тавышлы кыз. Алар алмашлап тантана героеның тәрҗемәи хәлен сөйләде: ...туган...бик тырыш малай булып үскән... хезмәт иткәндә атом бомбасы сынавында батырларча катнашкан... малчы булып эшләгән... алдынгылар рәтендә булган... менә хәзер хаклы ялда...

– Габделбәр Шәмигулла улы, хаклы ялда булуына карамастан, укучылар белән еш очраша, тормыш тәҗрибәсе белән уртаклаша, – дип тәмамлап куйды бу чыгышны сипкелле малай.

Гапсатаровның сул ягында басып торган карт, кем икән ул «укучылар белән еш очрашып тормыш тәҗрибәсе белән уртаклашкан адәм» дигәндәй арт ягына борылып карап куйды.

Сәрия Мәхмүтовна апаларының әлеге «...будьте готовы»сы белән балаларның «Всегда готовы!» тантананың бу өлешен очлап куйды.

– Күрксезме, иптәшләр, әфәнделәр, – дип башлады Гапсатаров үзенең чыгышын. – Хөрмәтле ветеран... – диде дә ниндидер тотлыкты. Габделбәр картның исем-шәрифләрен мэрның исеннән әллә кайсы арада чыгып өлгергән иде, – ветеранны котларга яшь буын бидрәшчеләр дә килгән. Нинди матур символик күренеш! Шәһәребезнең данлыклы үткәне, – мэр Габделбәр картның иңбашына уң кулын салды,– бүгенгесе, – ул сул кулының имән бармагын түрәләр төркеменә юнәлтте, – һәм якты киләчәге, – балалар ягына ымлады, – бер табын булып... тантанага җыелдык.

Гапсатаров кулына урынбасары сузган тартмачыкны алды, ачып медальне чыгарды, аны ялтыратып халыкка күрсәтеп алды һәм Габделбәр картның кешелеккә кия торган костюмына, «Почёт билгесе» орденны, «Хезмәт казанышлары өчен», «Хезмәт ветераны» медальләренә иш итеп тагып куйды.

Дәррәү кул чаптылар. Бүләкләнүченең үзенә дә сүз бирергә кирәк иде дә. Гапсатаров монысын онытты.

– Иптәшләр, әфәнделәр, – дип сүзен дәвам итте ул. – Бу чарада данлыклы якташыбыз пол... якташыбыз, күренекле галим, филология фәннәре докторы («кандидаты» дип кенә атауны күңеле кабул итмәде) Әюпов Фарук Йосыфовичның катнашуы тантанабызга тагы да ямь өсти.

Шушы урында Сарбаев килеп хуҗасы колагына нидер пышылдады. Моны хуҗа үзе генә түгел, сый көтеп түземсезләнә башлаган башка түрәләр дә дөрес аңлады. Кабаланырга кирәк, кабаланырга, анда, Шатуй буенда, табигатьнең гүзәлләрдән гүзәл бер төшендә аларны зур сый көтә!..

## Иртән торгач

*Имгән бозау кычкырмый.*

***К. Гельвеций***

Иртән торгач, Фарук Йосыфович, Буйновскийга шалтыратып алды. Аңа нәрсә әйтсен соң инде ул? Бидрәштә Вакыт аз-маз чыгымчылап алган, дисенме? Сатышып алган, дисенме? Кеше ышанмастай хәбәрне чын булса да, сөйләмә, диләр бит. Фарук



Йосыфович сөйләсә, губернатор аның үзен саташканга чыгарып куймасмы? Юк, илче мондагы хәлләргә кыска гына итеп бәһа бирүдән үтмәде. Шәһәр гадәти тормышы белән яшәп ята. Аның тормышы Рәсәйнең башка эреле-ваклы йөзәрләгән шәһәрләре тормышыннан әллә ние белән аерылмый. «Килгәннәрне сыйлый беләләр,» – дип өстәргә теләгән иде дә, шаяртуны губернатор дөрес аңламас дип, бу уеннан кире кайтты.

Әгәр дә зур сыйда, кайсы берәүләр кебек, кубенгәнче сыйлансалар, Габделбәр карт белән аның кунагы, ашказаннары богырлап, бавырлары чеметеп, башлары чатнап тора алмый ятарлар иде әле. Юк, Фарук Йосыфович шәһәр хуҗасы сыйлавын гадәтенчә,тыйнак кына кабул итте: аллы-артлы тост әйтелеп күтәрелгән рюмкаларга иреннәрен генә тигезеп утырды, өстәл өсте сыгылып торган ашамлыклардан да ара-тирә генә авыз иткәләде. Әллә кайсы илләрдә, әллә нинди экзотик азыклар татып караган кешене (кичә бит юкка гына шуларны исенә төшереп утырмаган иде) безнең казы белән кызыктырып буламы да, кыздырылган дуңгыз бәрәче белән аптыратып буламы.

Гомумән, ул табынга барыргамы, бармаскамы дип тә уйланган иде. Барса, кем исәбенәдер сыйланырга кирәк. Кайсыдыр ил посольствосының дипломатик приемы түгел ич. Бидрәш мэрының, Габделбәр карт әйтмешли, күзгә төтен җибәрүе генә. Андый сыйларны җене сөйми Фарук Йосыфовичның.

Тышта кангылдашкан казларен туендырып йөргән Габделбәр картның да уйлары әлеге мәҗлес тирәсендәрәк чуала иде. Күрмәгәнен күрсәттеләр картка! Ул ашамлыклары, ул эчемлекләре! Хәер, миңа күрсәттеләр дип, ничек үз-үзен алдасын инде. Бу «төтен очыру»ның әлеге кунагы Фарук хөрмәтенә оештырылуын аңламый микәнни ул. Ветераннарны хөрмәтләргә булгач, аларның түшенә медаль тагарга булгач, нишләп Теләкбирдене чакырмаганнар да, нишләп Тоцк вакыйгаларында катнашкан башкаларны чакырмаганнар? Хөрмәтле Габделбәр карт, имеш. Нигә ул бу көнгә чаклы хөрмәтле булмаган да, бер көнгә хөрмәтлегә әйләнгән дә куйган? Иртәгә ул зур түрәләрнең берәрсе аңа игътибар итәрме? Аңа сәлам бирерме? Җитмәсә, Бородулин атлысы, исергеч, картның янына утырып алды да, аңа «дәүләт сере» турында фәлсәфә сата. Имеш, атом бомбасын шартлату да дәүләт сере булган, анда катнашкан ветеранга медаль тапшырып, аны «юу» мәҗлесе дә – «дәүләт сере». Имеш, теләсә кемгә мактанып сөйләп йөрмәскә!

Сайрановлары, Самохваловлары, Бородулиннары, Ерохиннары Хрипуновалары, тагы әллә кемнәрне состылар гына! Карт юньләп ашап эчалмады. Аппетиты булмаганнан түгел, аптыравыннан. Бу хәтле сый-нигъмәтне кайлардан алып беттеләр икән дә, кем кесәсеннән чыгарып әзерләттеләр икән? Гапсатаров кесәсеннә түгелләр дә инде?

Өйгә кергәч тә Габделбәр картның кунагына биргән соравы шул булды. Фарук Йосыфович сыны катып көлеп җибәрде. Көлеп туйгач, яшьле күзләрен сөртте дә гаҗәпләнеп картка карап торды.

– Түгел, – диде ул җитди хәленә кайтып. – Гапсатаров кесәсеннән түгел, Габделбәр абзый. Хөкүмәтнең акча капчыгы бар, «бюджет» дип атала ул.

– Анысын гына беләбез инде, – дип карт кунагының сүзен бүлдерде.

Безне тал... бездән җыялар-җыялар да шул капчыкка тутыралар.

– Икътисадый яктан белемле икәнсең, Габделбәр абзый, дип көлемсерәде Фарук Йосыпович. – Безнең Рәсәйнең акча токчае, кызганычка каршы, тишек тә тошык шул. Теге тишегеннән сыпыралар да, бу тишегеннән сыпыралар. Кем миллионлап, кем миллиардлап.

– Бәй энем, кичә синең белән мин дә сыпырдык булдымы инде?

Мин ике кәса хәмерләрен чөмердем дә, ике телем казы каптым. Үз гомеремдә хәрам азык ашаганым юк иде. Акчасын кемгә илтеп түлим икән?

– Алай булгач, шул ике кәса хәмер белән ике телем казы янына мин эчкән өч кәса хәмер белән мин ашаган бер балык кисәген дә өстә инде, Габделбәр абзый, – диде кунак җитди булырга тырышып. Икебезгә ике йөзләп хәрам ашаганбыз. Илтеп түлик соң.

– Кемгә?

– Кемгә булсын, Хрипунова атлы бичәгә. Шәһәрнең акча токчае ул ич. Начальник финансового управления дип атала.

– Ә-ә-ә, исереп алып, сине сәйрәп биергә алып төшеп киткән теге бичәгәмени?

Фарук Йосыфович инде тыелып кала алмады. Габделбәр картның мәрхәмәтенә барып, Хрипунова бүлмәсенә кереп, кесәсеннән акча чыгарып нәфис бичә кулына: «Менә, Ирайда Касьяновна, үзем белән кунагымнан кичә сыйлангән өчен», – дип акча тоттыруын күз алдына китереп, тагы көлеп җибәрде.



Карт кулын селтәде.

– Түләп тормасак та ярар инде, Фарук улым. Синең белән бик ...лас, бик бирелеп биеде бит. Әллә кая сөйрәп тә маташты, булса ...ирак... – Карт хәйләкәр елмайды, – Гомумән, үз кешебезгә әйләнде. ...ке йөз акчаны йомып калганнан үпкәләмәс әле. Әнә күбенгәнче ...йланганнар түләсеннәр...

Фарук Йосыфович картка тагы бер җентекләп карады. Аның ...ңелен нишләптер кеше гомере турында фәлсәфи уйлар кылә бил ...п куйды. Әйе, гомер, гомер, дисәң дә, төрле кешенеке төрлечә узу ...ына түгел, төрлечә очлана да шул. Яши белү белән үлә белү икесе ...зур көч талап иткән нәрсәләр. Кайсы берәүләр юньләп яши дә ...елми, утызда ук картая башлый. Габделбәр картка сиксән яшь, әле ...р эшендә, һәр кылыгында яшәү көче төсмерләнә. Хәтта әле юмор ...кен дә югалт маган. Андыйлар чәбәләнми картая-картая да, ...рдән бер көнне, тыныч кына, мае бетеп сүнгән шәм кебек, якты ...ньядан китә. Шушы чакта янында якын кешесе булса... Аның ...вәш авылындагы тырыш хатын Фаягелгә өйләнү уена көлеп тә ...арга мөмкин. Тик картның бу адымын хупларга да кирәктер...

Иртәнге чәйне эчеп торгач, Габделбәр карт кунагына карады.

– Йә, Фарук улым, кичәге әкиятеңнән туеп кайттык,бүген кай...рга барып, кемнәрдән әкият сөйләтәбез инде.

– Габделбәр абзый, – диде Фарук Йосыфович, өстәл артыннан ...орып. – Синең вакытыңны болай да күп алдым. Дөньяң бар. ...планлаштырган эшләрең дә бардыр. Мин кичә теге кыз балага ...гъдә иткән идем бит.

Карт мут елмайды.

– Тагы кайсы кыз балага ул? Кочаклашып биегән акча токчаемыни? Аны «кыз бала» дисәң, Тәвештәге минем кәләшем Фаягөл ...терер җиткән кыз гына булып чыга түгелме?

– Юк ла, Габделбәр абзый, тәрттерергә дисәң, сиңа куш. Бала...ар алып килгән кызны әйтәм, Сәрия Мәхмүтовнаны... Әнисе ми...ем сыйныфташым булып чыкты ич. Зөбәйдә.

– Кайсы Зөбәйдә ул. Әллә теге ат караучы мәрхүм Зәйнулла ...ызымы? Укытучы Зөбәйдәме?

– Нәкъ үзе, Габделбәр абзый. Бидрәшкә гомер эчендә бер кайтып, ...ны да күрми китсәм, үпкәләр бит, үземнең дә үкенечкә калачак.

– Аны күрергә кирәк. Күрергә. Укып кайтты, мактапта эшләде. ...к озак кияүгә чыкмады. Халыкның теле озын бит, бер яраткан ...теге булган, шуны көтә икән дип тә сөйләделәр. Күрәсең, көтеп

алалмагандыр. Соңлап кына Махмүт исемле бер инженерга чыккан иде. Тик аныcына Хода гомер бирмәде. Ярый әле Зөбәйдәсенә бер кыз бала калдырып дөньядан китте. Шул кыз бала булдымыни инде кичәге укытучы? Күргәнем дә юк иде, чибәр булып үскән икән, әнисенә ошаган. Безнең Хөршидә күршенең Әлтәф улы шуның артыннан йөри икән дип чыгарганнар иде. Йөргәч, кавышсыннар иде инде. Тик... Әлтәфе милиция бит әле аның. Ул милициясендә эшләп-эшләп бозылалар кайсы ирләр...

– Хөршидәнең улы бозылмас, Габделбәр абзый, – дип көлде Фарук Йосыфович. – Әнә бит өченче көн миннән сыпырган меңлекне дә, гафу үтенеп, кире кайтарып бирде.

...Габделбәр карт булганда, беркемнең разведкасы да, контрразведкасы да кирәкми. Берничә сүз белән отставкадагы разведчик колагына барлык кирәкле белешмәне җиткерде дә куйды. Кичә Сәрия адресларын әйткән иде. Карл Маркс урамында ике бүлмәле фатирда яшиләр икән. «Чәчкә үстерә ул. Йортыбыз тирәсен чәчкәгә күмде инде» дип мактанып та алган иде. Зөбәйдә йортына китеп барганда уйлары чуалчык булды ирнең. Унынчы сыйныфта укыганда гашыйк булган иде ул кызга. Зөбәйдә гашыйк булмаслык та кыз түгел иде шул! Ул беленер-беленмәс сипкелле ак, чибәр йөзе, ул бер калын толым итеп үрелеп калку түшенә төшерелеп куелган күгелҗемгә якын кара чәче, ул шундый ук кара күзләренең үзәкләргә үтеп керә торган тылсымлы карашы, ул зифа сыны... Алар икесе дә активистлар иде. Мәктәпнең бар шау-шуы уртасында бергә кайнадылар. Тик ул чакта Фарук кимсенү чире белән (урыслар аны комплекс неполноценност дип атый) изалана иде. Зөбәйдә янып торган, өлгергән кыз. Алты яшеннән мәктәпкә кереп, әле яше белән дә, гәүдәсе-сыны белән дә иптәшләреннән бераз калышкан Фарук малайлыктан чыгып җитмәгән үсмер. Көзгегә караса да, эче поша.Тәсе уртачадан бик артып бармый. Зөбәйдә тирәсендә егетләр күп чуала. Фарук, ни чаклы гына тәннәрен кызны уйлап йокълый алмасын, әле кызга авыз тутырып: «Мин сине яратам!» – дип әйтерлек халәткә җитмәгән. Зөбәйдә аны чынлап үз итүен сизенә ул. Тик кызның яратуына ышана алмый. Кыз аңа яраткан энесенә караган кебек кенә мөнәсәбәттәдер, дип уйлый.

Унынчыны беттеләр, таралыштылар. Әйтелмәгән мәхәббәте шулай әйтелми калды. Бәлки, ул чын мәхәббәт тә түгел, яшьлек мавыгуы гына булгандыр? Соңыннан, Ленинградта укуын тәмамлап йөргәндә, Башкортстаннан укырга килгән Фәридәне очратты. Танышкач, озак йөри дә алмадылар. Фарукны озайлы командировкага



ит илгә җибәрергә тиеш иделәр. Командировканың бер шарты: ул ында гаиләсе белән барырга тиеш иде. Шулай итеп капыл гына гаиләле булып куйды ул. Үкенечкә калмады, матур яшиләр, яраташып яшиләр. Тик шулай да сыйныфташы Зөбәйдә исенә төшкәндә, йөрәге җилкенеп куйгалый иде. Ни эшлисең? Бу тормышта тәүге мәхәббәтнең гомерлеккә булу очраклары бик сирәк очрак.

Ә кемне көтеп озак кияүгә чыга алмады икән соң Зөбәйдә? Фарукны түгелдер дә инде. Егетнең кыюсызлыгы аркасында аңлашырга өлгермәделәр, вәгъдә бирешмәделәр. Кияүгә чыгарга булса, сайлап-сайлап, егетнең төскә дә, гәүдәгә дә, акылга да иң камилына чыга алган булыр иде бит... Чыккан ире белән озак яши алмавы жәл.

Шушы уйларына бирелеп Зөбәйдә яшәгән йортка килеп җиткәнен сизми дә калды ир. Хәтта су сиптергеч тотып подъезд төбендәге чәчкәләрне сугарып йөргән хатынны да килеп җиткәч кенә күрде. Зәңгәр спорт костюм ы кигән килешле гәүдәле ханымга ул аптырабрак карап торды.Зөбәйдә түгелме соң? Хатын ирнең карашын аркасы белән тойды, булса кирәк. Капыл аңа табан борылды да, тыныч кына:

– Исәнме, Фарук, диде.

Әйтерсең, кырык ел элек түгел, кичә генә аерылышканнар. Фарук югалып калгандай булды.

– Исәнме, Зөбәйдә... Менә бит, ниһаять, күрешергә дә Хода насыйп итте. – Дөресен әйткәндә, кысып-кысып иркәлисе килде хатынны, кыймады, Зөбәйдәнең күрешергә сузган кулына иренеп генә тигезде, аңа юлда сатып алган роза чәчкәләре гөлләмәсен сузды. – Менә тере чәчкәләрең янына өзелгән чәчкәләр, – диде.

Сәрия әзерләп куйган табында сөйләшеп сүзләре бетмәде аларның. Бөтен сыйныфташларын барлап чыктылар. Фарук кыска гына итеп үзенең хәлләрен сөйләде, Зөбәйдәнең тормышын сорашты. Бары бер генә темага кагылмадылар. Кагылсалар да, кагылмасалар да соң иде инде.

– Менә шулай үтте гомер, Фарук, – диде Зөбәйдә аерылышкан... – Эшләдем дә, эшләдем. Эшләдем дә эшләдем. Шәһәрдә рус теле, әдәбияты укытучыларының секциясен җитәкләргә туры килде. «Отличник образования» исемен дә биреп ташладылар. Эшләр идем әле, укыту эшенә ЕГЭ атлы галәмәт кертеп күңелемне төшерделәр. Белем бирү түгел бит ул, әзер сорауларга әзер җаваплар ятлату. Баланы бит уйларга өйрәтергә кирәк.

Тагын бер нәрсә эчемне пошыра минем, Фарук. Филолог булгангамы, яшьтән шигърият белән мавыгам. Үзем дә язгалап маташтым. Анысы яшьлек мавыгуы гынадыр инде. Шәһәребездә бит бөтен мөселман дөньясына билгеле шагыйрь Бәшир Бидрәши туган, яшәгән, шушындагы мәдрәсәдә укыткан. Байтак борынгы шагыйрьләрнең иҗаты өйрәнелгән, ә безнең акташыбызга галимнәрнең һаман кулы җитми. Мин кулымнан килгәнчә аның тәрҗемәи хәлен барлап, сакланып калган хәтле шигырьләрен туплап маташкан булам. Шигырьләре борынгы татар телендә язылган. Безнең хәзерге укучыга бик үк аңлашылып җитми. Гарәп һәм фарсы телләрендә язылганнары да байтак. Белүемчә, син көнчыгыш телләрен өйрәнгәнсең. Бәлки, шуларны татар теленә тәрҗемә итеп карар идең.

Фарук Йосыфович көлеп җибәрде.

– Әле генә мин фольклорчы идем, хәзер тәрҗемәчегә дә әйләндемме инде? – Шунда ук капыл гына җитди төс алды. – Ул шәхеснең язмышы турында уйланганым бар. Әйдә болай итик: көзен мин Бидрәшкә иркенләбрәк кайтачакмын. Син материалларыңны туплый тор. Очрашырбыз, киңәшләшербез. Мин дә бит әле әдәбияттан бик ерак торган туң йөрәкле ир түгел, филология факультетын тәмамлаган кеше. Хәтта үзем өчен генә булса да шигырьләр язштырам. Шәһәр музеена кереп чыгалмам, ахрысы. Анысын да көзгә калдырырга туры килер инде. Анда Бәшир Бидрәши турында мәгълүмат бармы, ичмасам?

– Бар, тик бик кыска гына. Урындагы рәссамның күзаллап төшергән портреты да, мин язып биргән кыскача белешмә. Ә музейга теләсәң дә керә алмассың, Фарук. Бәхтияр байның гасыр ярым элек салынган йортында урнашкан бит ул. Йорт бик нык искерде, капиталь ремонтка ябып куйдылар. Кайчан ул ремонтка акча табарлары, кайчан эшне башкарырлары әлегә билгесез.

– Һай, акча! Һай, әлеге шул акча!..

– Синең казанышларыңны сорашып тормыйм инде, Фарук. Гомерем буе белешеп бардым. Ниндирәк эштә эшләгәнеңне дә күзаллыйм, хатыныңны, улың белән кызыңның барлыгын да беләм, тормышыңның иңле дәвам итүенә шатланам да. Бераз көнләшәм дә. Хатын кеше бит мин, ә һәр хатын үзенә күрә разведчик ул. Тагы да әкиятләр җыярга килсәңә, керми китмә. Күрешеп яшик!. Әйткәндәй, тагын бер сыйныфташыбызны хәтергә төшерергә онытканбыз икән, Соломин Витяны.



– Витя?!. Исән-саумы? Кайда яши?

– Шәһәребездән беркая да китмәде. Журфак тәмамлап кайтты да, газет эшенә чумды. Хәзер пенсиядә инде. Өе моннан ерак та түгел. Беләсең булыр. Әтисеннән калган урында йорт бетереп керде. Вакыт таба алсаң, кереп хәлен бел. Шәһәребезнең аяклы тарихы бит ул!

– Барам, – диде ир, икс дә уйлап тормый. – Мэрыгыз белән вәгъдәләшкән вакытка хәтле мин буш әле. Хәзер үк шунда барам.

...Ә Зөбәйдә матур сакланган. Кешенең, бигрәк тә хатынкызның картлыгында да менә шулай саклануы нидән кала икән? Заманында барлык СССР ирләрен чибәрлеге белән һуштан яздыра торган киноактриса бар иде. Азак экраннарга чыкмый башлады. Беркөн шулай телевизордан күрсәткәннәр иде, Фарук Йосыповичның исе китте. Биллаһи, убырлы карчык! Андыйлар тыныч кына яшәп ятсыннар иде дә, телевизор экраннарына чыкмасыннар иде, әлеге гашыйк ирләрнең күңелендә шулай яшь, шулай чибәр булып саклансыннар иде. Ә Зөбәйдәне хет бүген киногә төшер дә, хет бүген телевизордан күрсәтеп утыр. Зөбәйдәне, Фарукның кайчандыр бөреләнеп тә чәчәк ачылмаган мәхәббәтен!.. Чыгарылыш кичәсеннән соң, сыйныфташлар күмәкләп төне буе Шатуй әрәмәсендә йөргән иделәр. Күңелләре иләс-миләс иде. Фарук Зөбәйдәне шунда тәү мәртәбә үпкән иде. Үбүе дә инде... иреннәре нишләптер кызның иреннәренә туры килмәде, аның борын очын әллә үпте, әллә ялап алды. Кыз шаркылдап көлде... Икенче көнне дип әйтерлек Фарук, документларын алып, Ленинградка чыгып китте. Тәүге мәлләрдә хат языштылар, әмма хатлар сирәгәйгәннән-сирәгәеп юкка чыктылар...

## ГАПСАТАРОВ

*Кеше чыккан та маймылга охшаган, югарырак күтәрелгән саен арт ягы ныграк күренә.*

*Ф. Бэкон*

Энгель Заһидуллович йокысыннан көч-хәл белән торып, көч хәл белән эшенә килеп утырды. Тәне ватылган, башы авырта иде. Кунак чамалап кына тоткач, ул да әллә ни эчәлмәде. Махмыр түгел, тәнендәге авырлык, башындагы буталчыклык соңгы көннәрдә кичергән кәсафәтләре шаукымы булды, ахрысы. Акыл белән аңлатып булмаган ниндидер саташуы. Имеш, советлар да кире кайткан, партия дә бар, горком да эшләп ята. Ә ул элекке кебек авыл

хуҗалыгы мөдире түгел, тоташтае белән беренче секретарь. Имеш, ит планын уңышлы үтәү турында обкомга хат юллата. Ә мал симертү комплексына барып караса, анда Букреев бар, корсагын кереп, күне агарганчы кырылган папкасын тотып, тегендә-монда йөреп ята. Эргәсендә Садрый парторгы да чуалана. Комплекс директоры бар, парторгы бар, араннарда бер генә баш та үгезләр, таналар юк. Әйтерсең, көтмәгәндә давыл купкан да аларны очыртып җәһәннәм тишегенә алып киткән. Ә горкомның беренче секретаре КПССның өлкә комитетына җиңүчел рапорт юллата. Килеп тикшерүчеләр, аягын җиргә дә тигезмәсләр бит! Шыр тиргә батып уянып киткән иде. Бераз уйланып яткач бу өнгә охшаган төшнең саташу гына икәнлегенә төшенде дә, җиңел сулап тагы йокыга талды.

Моңысы күп серияле төшнең тәүге өлеше генә булган икән. Йоклап китеп өлгермәде төшенең икенче сериясе дә башланды. Имеш, горкомның бухгалтеры аңа айлык эш хакын керткән. Төгәл өч йөз сум! Мәсхәрә! Шәһәрнең водоканал хуҗасы да шул чаклы ала, Беренче секретарь дә. Водоканал хуҗасы әле труба сатыпмы, башкасын аткарыпмы урлый ала. Гапсатаров урлый алмый, ул бит партия кешесе. Ә партия дәвернең акылы һәм намусы. Урлап кына кара, шунда ук партомиссия атлы зәһәр оешма, коерыгыңа да басар, утлы табага да бастырыр. Вот тормыш! Тырышасың-тырышасың да, вактеяк өчен җәзага тарттырыласың. Партиядән куып, эшеңнән азат итеп кенә калсалар ярый да ул, утыртып ук куйсалар…

Бу юлы уянып киткәндә, Гапсатаровның, бите, тәне генә түгел, аяк очларына чаклы тирләгән иде. Ул заманнар кайтса, куркыныч!

Бу саташуының өченче сериясе дә булды әле аның. Йоклап кына киттем дигән иде, үзен йомшак түшәктә чибәр кыз куенында күрде. Инде дә тәмләп сөешәләр иде. Шулчак бүлмәдә капыл прожектордай лампа янды. Ишек ачылып китте, анда, кулына фотоаппарат тотып әлеге мәртәт парткомиссия рәисе килеп керде.

Гапсатаровның бар дәрте сүнде, дарманы бөгелеп төште.

– Ә-ә-ә, злактеңме сволочь! Моральным разложением занимаешься?

«Коммунизм төзүченең әхлак кодексын» санга сукмыйсың? За это – тебе расстрел!

Тагы уянды. Шул көнне эшкә баргач, шәһәргә ниндидер шикле кеше килгәнлеген ишетте. Саташулары юкка булмаган икән. Өлкәгә барып разведка ясап кайту планы да яртылаш кына үтәлде. Шәһәренә килгән шикле кешенең ниндирәк адәм икәнлеген дуслары ярдәмендә



бераз чамалый алды, финанс министры Митрохин белән алыш-биреш мөнәсәбәтләренә дә ачыклык кертә алды. Әмма губернатор Буйновский белән очраша алмады. Очрашсалар, күзгә-күз карашып нигәмәләшсәләр, бәлки, яшь түрәнең Бирдәш мэрына карата мөнәсәбәтен дә чамалый алыр иде. Мөнәсәбәте уңай булса… Шулай да булырга мөмкин. Өч кенә ай эшләү дәверендә өлкәнең байтак түрәләрен алыштырып ташлады бит. Хәтта урынында төп кебек утырган Соловейчикны да аямады. Степной шәһәре мэры, Гапсатаровның сердәше, шешәдәше. Ә Гапсатаров урынында утыра. Буйновскийның күңелен нечкә табарга мөмкин икән дип , баш ватып утыра. Монастырев белән барысы да ачык иде. Кесәсенә ни чаклы күбрәк тамызсаң, син шул чаклы яхшы. Моңысы әлегә, урысча әйткәндә, «серая мышь». Рус әдәбиятындагы бер әдәби герой ришвәтне затлы ау этләре белән алырга яраткан, имеш. Әлеге көндә дә ришвәт алмаган түрә юктыр ул. Һәр хәлдә Гапсатаров андыйның барлыгына ышанмый. Ә Буйновский? Бәлки ул да ришвәтнең бер экзотик төрен сайлагандыр. Әйтик, каклангән чөгә балыгымы шунда, башка берәр деликатесмы…Әгәр шулайрак була калса, губернатор хәтле губернаторны сыра чөмерерлек балык белән генә ризалатып булмый бит инде.Бидрәш валютасын (каклаган чөгәсе бар Кудеяр өлкәсе шулай атый) йөкләп-йөкләп аткарырга туры киләчәк.

Һәр хәлдә Буйновскийның Гапсатаровка карашы начар булмаска тиеш. Һаман урынында утырга бит. Шулай булгач, нигә Бидрәшкә шымчы җибәрә? Әгәр аралары бозылып китсә, Гапсатаров та малай-шалай түгел, аның запас варианты бар. Өлкә думасы рәисе Сайганов белән күптәнге дуслар алар. Әллә кайчаннан бирле, думага депутат булып сайлан, үзем үткәреп җибәрәм, дип теңкәсенә тия. Мэрлыгын ташлый да, депутат булып китә. Монда туплаган байлыгы җитәрлек, депутатның дүрт йөз мең эш хакына иза чикмичә генә яши алыр әле.

Кудеярга баруында тагы бер нәрсәгә күңеле каты кырылды аның. Сәркәсе Снежананың тотанаксызлыгы, үзенең постельдә уңышсызлыкка очравы. Мондый уңышсызлык – губернатор нәфрәте түгел. Аңардан да яманрак. Губернатор нәфрәтеннән котылып була, бу оятлыктан берниндә ришвәтләр ярдәмендә дә котылып булмый…

Начар уйларыннан арыну өчен ул урыныннан торды, кабинетының арткы бүлмәсенә чыкты, андагы зур көзге каршына килде, сул кулын костюмы эченә тыгып, Наполеон кыяфәте алды. Юк, бөтенләй сөрсегән карт түгел әле ул: йөзе, чиртсәң каны чыгарлык кызыл, бераз

кысык күзләре мәгънәле карыйлар, корсагы зур булса да гәүдәсе нык күренә, аякларының бераз кәкрелеге... кавалеристларда шулай була, диләр бит. Зурайганнан зураеп барган пеләше генә бераз эчен пошыра. Наполеон әлеге өчпочмаклы хәрби баш киемен кигән дә, тыныч йөргән. Әллә Гапсатаровка да берәр баш киеме киеп йөрергәме? Мәскәү мэры Лужков кебек, җәен-кышын шул бер күн кепкада. Бу – идея! Әйтик, Күн кепкала түгел, кара эшләпәдә, урыс артисты Боярский кебек, йә булмаса ак эшләпәдә, татар җырчысы Асаф Вәлиев кебек...

Мэрның бу уйларын кабинетына килеп кергән секретарь хатын Руфина бүлдерде.

– Йә, нәрсә кирәк тагын? – дип каршы чыкты аңа түрәсе. Йөзенә ризасызлык билгесе чыккан иде.

Руфина Хөршатовна, әллә алгы бүлмәгә чыгып теге чувашны борып кайтарып җибәрергә генә микән, хуҗа бик кәефсез күренә, дип уйлаган иде. Аннысы:

– Йә, әйтсәң әйт тә... – дип бичәне туктатып куйды.

– Приемныйда Гаврилов, Энгель Заһидуллович, су-канализация хуҗасы. Кичә кабул итәргә вәгъдә биргәнсез икән...

– Нинди вәгъдә ул тагын? Әйттем генә. Кичә әйттем... бүген... Ярар, керсен. Кисәт, биш кенә минутка. Минем вакытым тар. Бездельник! Йөри шунда...

Кечкенә гәүдәле ябык ир кыюсыз гына керде, ишек төбендә басып калды, бераз калтырана да иде, булса кирәк.

– Энгель Заһидуллович, кичә килгән идем бит инде, трассада авария. Юынтык сулар Шатуйга ага. Ярдәм кирәк.

Түрә аңа утырырга тәкъдим итмәде.

– Нәрсә, кәрәк тотып барып эшкә мин тотынargymмы?

– Юк ла, экскаваторыбыз ватык. «Дорремонт»ка әйтмәссез микән, экскаваторларын биреп торсыннар иде. Барыбер әлеге көндә берни дә эшләмиләр. Имеш, һаман финанслау ачылмаган... – Артык нәрсә әйтеп ташлавын Гаврилов үзе дә аңлады. Чөнки түрәнең йөзе бозылды, кашлары җимерелде.

– «Дорремонт» эшләренә синең ни кысылышың бар? – дип җикереп үк җибәрде ул – Прекрасно эшләп йөриләр, синекеләр кебек бездельниклар түгел.

Әйе эшлиләр иде юлчылар, тик юлда түгел, хәзер бер атна инде мэрның дачасы ишек алдында плита түшиләр иде. Гапсатаров «Водоканал» хуҗасының сүзләрен шуңа ишарә итеп аңлады. Куып чыгарырга да уйлаган иде, үзен чак тыеп кала алды.



– Миңа тиз генә Водкинны тап әле, шалтыратсын, – диде ул, секретарьне чакырып кертеп.

Аннысы, чынлап та, биш минут та үтмәгәндер, шалтыратты.

– Энгель Заһидуллович, – дип башлады ул сүзен исәнләшеп-иминләшмәстән, – тагы бер биш-алты көннән эшне тәмамлыйбыз. Клумбаларны читли торган плиталарны үзегез килеп карасагыз икән, төсләре, формалары...

– Аннысын куеп тор әле, Яков Лукич, – диде хуҗа, тавышын йомшарта биреп, – «Водоканал» трассасында авария, Гавриловка экскаваторыңны биреп тор... Югыйсә, бу... (Түрә чак кына «мүкләк бозау» дип әйтеп ташламады).

Водкин үз алдына гына сүгенгән иде, күрәсең трубканы читкәрәк күчерергә оныткандыр, тупас сүзләре Гапсатаровның гына түгел, Гавриловның да колагына барып чалынды.

– Нәрсә, нәрсә, Водкин, мине кайда җибәрәсең син?

– Гафу итегез, Энгель Заһидуллович, сезне түгел ул, Гавриловны.

Труба сораган идем мин аннан, өемә кергән җирдә юл астына салырга, утыз гына метр. Бирмәде куркуль. Ә мин аңа экскаватор...

– Ярар, сатулашма! Алыш-биреш мәсьәләләрен соңыннан кайтарсыз. Әле мин әйтәм! – дип «мин» сүзенә басым ясады хуҗа.

Гавриловны чыгарып җибәргәч, хуҗаның кәефе бераз күтәрелә төште. Әйе, «мин» шул ул! Бу шәһәрдә һәркемгә дә аның сүзе – закон! Ул секретарен янә чакырып кертте.

– Карале, Руфина Хөршатовна, арткы бүлмәгә мул гына итеп сый әзерлә. Чәй-мәй белән генә чикләнмә, колбасасы-сервелаты да, ысланган чөгәсе белән казысы да булсын. Теге шәһәребез кунагын чакырган идем. Эш тә эш дип, әле үзем дә авызыма чык тамчысы да тамызганым юк...

– Бигрәк күп эшлисез шул, Энгель Заһидуллович, ял да юк, ял да юк... – дип көрсенде секретарь бичә чыгып барышлый.

– Руфина Хөршатовна, миңа акча токчаебызны чакыр әле.

– Юан марҗаңнымыни!

– Ярар көлмә. Син дә аңардан бик калышмыйсың әле.

– Аннысын сез беләсез инде Энгель Заһидуллович. Минем белән генә кәнәгать булмый, аңа да үрелгәч...

– Ярар, ярар, күп сөйләмә, Руфинәкәй. Синең белән яратышып, аның белән эш буенча... Чакыр.

Бидрәш хакимиятенең финанс идарәсе начальнигы Хрипунованың эшләре бүген хөртерәк иде. Кичә, Габделбәр карт хөрмәтенә юктан бар итеп корылган табында артыграк төшереп ташлаган. Бертуктаусыз тостлар яңгыравы хәтерендә дә, мәҗлеснең төп кунагы Әюповны сөйрәп дигәндәй танцага алып төшүе хәтерендә. Әллә фәннәр кандидаты, әллә инде полковник аның күңелен күрергә бик ашкынып тормавы да исерек аңына сеңеп калган. Шуңа күрә мэр бүлмәсенә кергәндә аның йөзе караңгы иде.

– Нихәл, Ираида? Нишләп йөзең бик боек?

– Хәлләр бик хөрт булса, баш төзәттерерсеңме әллә? Сездән, хәзерге ирләрдән, сый да, сыйпау да өмет итәрлек түгел инде ул. Гусарлар юк хәзер…

– Ярар, ярар, зарланма. Кичә кунак белән бик ихлас биигез иде бит Менә бүген аның белән тагы очрашырга ният бар. Ул гади кеше түгел. Тегендәгеләр белән (Кабинет хуҗасы уң кулының баш бармагын әлеге селкенеп торган люстрага юнәлтте) бер даирәләрдә кайнаган кеше.

– Нәрсә, Энгель Заһидуллович, Буйновскийның үзе беләнмени?

– Буйновский кем ул, Ираида Касьяновна? Яңа кабыгын тишеп чыккан тавык чебеше. Фантазияңны югарырак күтәрә бир.

Бичәнең йөзенә аптырау катыш соклану билгесе чыкты. Ул инде ачылып җиткән түгәрәк күзләрен хуҗасының кысык күзләренә төбәде.

– Неужели, Энгель Заһидуллович?

Хуҗаның йөзенә горурлык хисе бәреп чыккан иде. Әйтерсең, озаклamый аның тупсасын атлап үтәр кунак югары даирәләрдә кайнамый, ә ул, Бидрәш шәһәре башлыгы шул даирәләрдә кайнаган кешеләрнең ишекләрен аягы белән тибеп ачып кереп йөри.

– В самом деле, Ираида җаныкаем. Сиңа задание, срочно гына бер миллион табаласыңдыр бит.

– Нәрсә, «яшел» беләнмени? – Хатынның йөзе бозылып китте, күзләре акайды.

– Син нәрсә? «Яшел» белән тегендә-монда таратып ятарга Әндрәй казнасы бармыни синең белән миндә. Үзебезнең «агач» акча белән. Матур гына итеп бер кап әзерләп куй. Өчәүләп кәеф-сафа корып утыра торгач, мин кунакны бистәбезне күрсәтергә алып чыгып китәрмен.



Ә син әлеге капны…

– Бер кап булмый инде, Энгель Загидуллович, бишәр меңлекләрдән ике кап була.

– Әнә шул ике капны ипләп кенә аның кейсына тыгып куярсың. Әйдә, сюрприз булсын әле тегеңа. Ришвәт дип безгә бәйләнә дә алмасын.

Дөресме-түгелме, ришвәт алмаучылар да бар диләр бу дөньяда, Ираида. Тик андыйлар да аз бирсәң генә алмый. Бар эш ришвәтнең кимәлендә…

Миллион ул әлеге безнең кунак өчен әллә ни күп түгелдер, тик синең белән мин бит аны «төртмибез», ә ул «алмый»…

Хуҗа, үзенең тапкырлыгына үзе сокланып, бар кабинетын яңгыратып көлеп җибәрде. Хатын нечкә тавышы белән аңа кушылды.

## ҺӘВӘСКӘР БАКЧАЧЫ

*Качып китсәң дә, чәчеп кит.*

***Татар халык мәкале***

Фарук Йосыфович Карл Маркс урамы буйлап үргә атлады, Аннан Чубайс тыкрыгына борылды. Элек бу тыкрык Степан Халтурин исемен йөртә иде. Яңа власть кешеләре революционер Халтуринның исемен шәһәр тарихында калдыруны кирәк тапмаганнар булып чыкты. Хәзер тыкрык Ельцинның алыштыргысыз киңәшчесе, СССРны таркату идеологы Анатолий Чубайс исемен йөртә икән.

Элекке урынын белгәнгә, сыйныфташының йортын шунда ук таныды ул. Яңарткан, әллә ни зурайтмаган. Гади бер катлы өй. Бер ягында ике катлы, пыяла мансардалы, икенче ягында өч катлы, колонналы йортлар арасында кысылып калгандай тоела. Күрәсең, шәһәр уртасындагы, бу урыннарны заман байлары да үз итмәгәндер.

Башына төсе уңган бейсболка, ас ягына камуфляж төсендәге кыска ыштан элэктергән ялангач ир туңкаеп әллә түтәл йомшарта, әллә чүп үләне йолкый иде. Арырак хатыны бәрәңге җиреннән колорадо куңызы чүпли иде, булса кирәк.

Фарук Йосыфович калын гына итеп тамак кырды. Эшкә мавыккан икәү моны ишетмәделәр. Аннары:

– Хозяева! Здравствуйте! Можно к вам? – дип сәлам бирде.

Хуҗалар чакырылмаган кунак ягына борылдылар. Ир маңгаена кулын куеп кунакка карап торасы итте, кояшта көрән булып янган кырыс йөзендә елмаю хасил булды, ул йөгерә-атлый сыйныфташы янына килде.

– Фарук, ты? Сколько лет, сколько зим! – дип аны кочаклап алды.

– Узнал? – диде Фарук Йосыфович, Виталийны аның үзеннән дә катырак итеп кочаклап. – Узнал, старина!..

Алар бер-берсенең аркасына шапылдатыштылар, йөзләрен җентекләп тикшерештеләр. «Изменился», «не изменился» кебегрәк бәяләр бирештеләр.

Сыйсыфташының хатыны ике ирнең малайларча кылануын көлемсерәп карап тора иде.

– Маша! – дип кычкырып җибәрде капал йорт хуҗасы, – Иди домой, готовь стол. Не видишь что ли, одноклассник приехал, друг детства!

Хатын икәү эргәсенә килеп, кунакка тыйнак кына итеп кул бирде.

– Мария Ивановна. Супруга этого неуёмного.

– Фарук Юсуфович. Такой же неуёмный, как ваш.

Көлештеләр. Өйгә үттеләр. Кайсыдыр арада хуҗа белән хуҗабикә киемнәрен алыштырып алдылар. Ирләр хәл-әхвәл белешкәнче, аш-су ягында таба чыжылдаган, яшелчә телгәләгән тавышлар да чыга башлады. Ул арада түр ягында сый өстәле хасил булды. Хуҗа: «Не пьянства ради, токмо ради здоровья», – дип сөйләнә-сөйләнә суыткычтан тирләгән бер шешә китереп утыртты.

– Свое производство! Чистейший, целебный напиток, – диде ул рюмкаларга коя-коя.

– Менә кайттым әле күпме еллардан соң, – диде Фарук Йосыфович, эчемлекне кирәк җиренә аткарып, урыс дустының ысланган дуңгыз итеннән авыз иткәч, кыяр-помидорын капкалагач.

– Хәл белергәме, әллә командировкагамы? – дип кызыксынды Виталий сыйныфташы.

– Алай дисәң дә була, болай дисәң дә... Синең журналистик белемең булса, минеке дә филология бит әле. Соңгы вакытта фольклор белән шөгыльләнәм, заман халкының авыз-тел иҗатын җыям, – диде Фарук Йосыфович, үз сүзләренә үзе ышанмаса да.



Үзе ышанмагач, аның хәбәренә кырык ел журналистика өлкәсендә тире калынайткан хуҗа ничек ышансын инде.

– Димәк, «Кавказская пленница»дагы Шурик кебек, – дип көлеп җибәрде хуҗа. – Ярар, Фарук дус, твоя информация принята во внимание. Мина килгәк инде, МГУның журналистика факультетын тәмамлагач, үзәктә тамыр җибәрергә дә мөмкинлек бар иде. Әти-әни картаеп баралар, мин аларның бердән-бер терәге. Кайттым Бидрәшкә – анысына һич тә үкенмим. Яшьлек дәрте белән җиң сызганып эшкә тотындым. Шәһәр газетен хәтерлисеңдер инде, «Знамя Ленина»ны. Язам, тегендә дә барам, монда да, тегенең белән күрешеп интервью алам, моның белән дә... Биология укытучысы Мария Ивановнага өйләнеп ташладым. Бер-бер артлы өч кызыбыз туды. Мине «Знамя Ленина»ның баш мөхәррире итеп ташладылар. Ни әйтсәң, тормыш җайланды, дисәң дә була иде инде. Тик әллә кайлардан килеп чыкты-лар бит Горбачевлары, Ельциннары, Чубайслары, Бурбулислары... Новое мышление, имеш, перестройка, имеш, демократия, имеш, гласность, имеш... Син мине сөрсегән, әллә кайларда, адашып торып калган бер адәмгә санып курмә, дус. Юньле адәм өй яңартырга, яңа өй төзергә булса да, тәү аның планын сыза, стройматериаллар әзерли. Әболар, күчләрен акайтып власть, байлык турында хыялланганнар, алдылар да ул властьне... Хәзер инде барыбызга да ачык, Белоруссиянең кара урманы эчендәге аучылык хуҗалыгында тәү хәмер чөмерделәр, аннары өч республика җитәкчесе үзләренең СССР империясенең чыгулары турында нәрсәнедер Бурбулис ашык-пошык эшмәккән кәгазьгә кул куеп тагы берәр рюмка хәмер күтәрделәр дә, бу шатлыклы хәбәрне Америка президенты белән бүлешүне фарыз санадылар. Правильнее выразиться, докладывали в Вашингтонский обком партии о выполненном задании по разрушению СССР.

Сыйныфташының бу чыгышын Фарук Йосыфович елмаебрак тыңлап утырды. Мондый фикерләрне ул урам фәйләсуфләре авызыннан да, югары даирәләрдә эшләгән коллегаларыннан да ишеткәне бар иде. Алар белән килешмичә дә мөмкин түгел иде. Шуның өчен иптәшен бүлдермәде.

– Кешелек кайчан да булса коммунизм идеяларына кире кайтачак, Фарук дус. – Коммунизм идеяларына, тигезлек, намуслылык идеяларына.

Бар Кытай социализмы, бар Куба социализмы, Бар, ниһаять, Швеция социализмы. Бер урында катып калырга ярамый, шушындыйрак вариантларның берсен сайларга кирәк иде...

– Карале, Витаий дус, – диде аны бүлдереп сыйныфташы. Җәмгыять үсеше мәсьәләсенә мондый карашларың белән кем сине шәһәр газитенең баш мөхәррире итеп тотты?

– Тотмадылар, кудылар, – дип җавап бирде ана элекке мөхәррир. Юк, җәмгыять үсеше мәсьәләләренә аларның чыпчык мие чаклы акыллары җитми иде әле. Ә мөнә кулларына тамып, кесәләренә төшеп барган байлыкны үзләштерүгә акыллары ай-һай бик тә җитте һәм җитә.

Партия кәнәфиен калдырып, демократлар кәнәфиендә бик ятеш урын алган Гапсатаровны газитгә азмы-күпме чеметкәләргә туры килде. Минә кырын карады, әмма түзде, гласность заманы ич! Бу чакта аның эшләре дә хертерәк иде. Шәһәрдәге берничә абруйлырак адәмнәр үкчәсенә басып килә. Аларның да «демократия» атлы бәлештән авыз итәселәре килә. Химия комбинаты директоры Шаповалов, спирт заводыннан, ит җитештерү комбинатыннан Букреев... Тик алар бит... Гапсатаров партия коридорларында буынын ныгыткан овчарка, тегеләр әле капка астыннан ләңгелдәп яткан көчекләр генә.

Мәр вазыйфасына претендовать иткән адәмнәрдән тиз котылды ул.

– Ничек? – диде Фарук Йосыпович үзе дә аңгармастан. Төрмәгә җибәрерлек көче юк та инде аның.

– Причем монда төрмә! – диде авыр сулап йорт хуҗасы. Алар бит зур түрәләр, алар төрмәләрдә утыра торган гади бәндәләр түгел. Просто-напросто предприятиеләре ябылды, житәкчеләре юкка чыкты. Юк, аларны бетерү дә юк итмәде. Берсе Кудеирда ширкәть ачкан, ди, икенчесе Владимир өлкәсендә депутат булып йөри, ди, өченчесе – Мәскәү өлкәсендәге бер шәһәрчекнең мэры, ди... Ә Гапсатаровның мондагы утыруы – утыру, хакимлек итүе – хакимлек итү...

Аның методы гади. Урынына дәгъвә иткән адәмне белеп ала да, шәһәрнең контроль комиссиясе рәисен ана өстерә. Ә тегесе, әйткәндәй мэрның бажасы, әлеге мескеннең ширкәтен энәсеннән җебенә чаклы тикшерә дә, булыр-булмас гаепләрен таба. Хәзерге житәкчеләрнең гаепләрен табу кыен эшмени? Тикшерү белешмәсен укыйлар да, әлеге бәндәгә әйтәләр: «Йә, энем, Бирдәштән табанынны ялтыратасың, йә төрмәгә утырасың». Менә шулай. Сталин: «Нет человека, нет проблемы», – дип әйтеп калдырган бит.

– Ә син ни белән ярамадың шәһәр хуҗасына? Сәяси карашларың белән генәме?



– Мина да бурыч йөкләтеп маташты ул, Фарук дус. Мине дә кесә журналисты итәргә чамалады. Юк, риза булмадым. Китәргә туры килде.

Хәзер инде газитнең дә исемен алыштырдылар. «Демократия байрагы», имеш. Тиражы ике меңгә дә җитми. Элек егерме меңнән ашя иде.

Хәзер инде газитләр халыкка гына кирәк, аның да өлкән буынына. Яшьләр интернет чүп-чары белән риза. Ә властька бу бик уңайлы. Тормыш мәсьәләләре белән кызыксынмасыннар, әлеге рухи наркотикка риза булып яши бирсеннәр. Ә заман хуҗаларының үз мәгълүмат чаралары. Һәрберсе үз сайтына үзенең казанышлары турында хәбәрләр кертә да, үзе укып, хушкүңеллелек тойгылары кичереп тик утыра. Синең газитең аңа ни пычагыма кирәк...

Кунак хуҗаның бу сүзләрен игътибар белән тыңлап утырды, ана, тәү күргәндәй, гаҗәпләнеп карап утырды.

– Ну, дускай, син дә... Бүгенге яшәешкә карашларың менә минем белән тап килә, булса кирәк. Гади фольклорчымын дип, минем күземә төтен очыруың бер эш, югары власть коридорларында зур урын биләвең икенче... Сине ничек анда тоталар?

– Тотмыйлар. Отставкага аткардылар бит инде, – диде Фарук Йосыфович, елмаеп. Шунда ук артык сүз ычкындырып җибәрүен аңлады. Хәер, ычкындырса да, ычкындырмаса да. Бидрәштә аның әкиятләр җыеп йөрүенә хәзер инде беркем дә ышанмый иде, булса кирәк. – Хәзер мин – вольная птица, туган. Гел сәясәт сөйлибез дә, сәясәт сөйлибез, үзең ни эшләр башкарып ятасың соң, Витя?

– Бакча үстерәм, – диде хуҗа, ишек алдына караган тәрәзәгә ишарәләп. Бидрәштә иң уган бәрәңге – минеке, иң тәмле кыяр белән помидор – минеке, иң кортсыз алма белән виноградлар – минеке!.. Мин

– Мактанчык! – диде хатыны, иренә мыскыллабрап карап. Мин булмасам...

– Әйе, әйе, сөеклем, син булмасаң. Син бит шәһәребездә генә түгел, бар өлкәдә иң мактаулы биология укытучысы булдың. Синең мактап алды бакчаң ВДНХ дипломына лаек булганын да онытканым юк.

Хуҗабикә авыр сулады.

– Эшләр идем әле. Балаларны эшләтергә рөхсәт итмиләр. Бакчада эшләтү генә түгел, хәтта класс идәнен юдыртырга да рөхсәт юк. Гомүмән, военно-патриотическое воспитание дип лаф орабыз, укучыларны кадет дип атап, хәрби киемнәр кидереп айт-двага ба-

стырабыз, ә әхлакый тәрбиясе, хезмәт тәрбиясе турында оныттабыз. Менә шулай, биолог буларак җирдә чокыну теләгемне үз бакчамда канәгатьләндерергә туры килә. Виталием белән бергәләп.

– Виталийның әлеге властька төкереп тә бирми, дисез инде? Диссидент битлеге киеп…

Хуҗалар көлеп җибәрде.

– Фарук, синең сүзләреңдә дә верноподданныйлык хисләре аңкып тормый.

– Анысы шулай инде ул, Виталий. Без синең белән заманында престижный уку йортларында югары белем алган, тормышның ачысын да, төчесен дә байтак татыган зыялылар. Ә Русия зыялылары кайчан властьның һәр төркергәненә «Йорхәмбикалла!» дип дога кылып торган? Патшалар заманындамы, Сталин чорындамы, Горбачев кәефләре вакытындамы. Без бит үзебезчә фикер йөртеп, үзебезчә нәтиҗә чыгарып маташабыз. Декабристлар кебек мәйданнарга чыкмыйбыз. Тик, минем һаман да кайсы бер нәрсәләр кулымнан килә әле. Телисеңме, Гапсатаровны эшеннән кудыртам.

Отставкадагы журналист отставкадагы чекистның күзләренә аптырап карады. Уйланып утыргандай итте.

– Юк, теләмим.

Фарук Йосыфович мондый җавап көтмәгән иде.

– Ник?

– Бер кечкенә шәһәрнең мэрын алып ташлау белән тормыш яхшы якка үзгәрер дисеңме? Хәтерем ялгышмаса, Рәсәйдә сигез йөз шәһәр бар. Аларның күбесенең башлыклары Гапсатаровтан яхшырак дисеңме? Аннары, мәсьәләнең икенче ягы да бар бит әле. Гапсатаровлар үзләренә инде байлык туплаганнар. Ә аларга алмашка килергә омтылып торганнары? Аларына банкларда түгәрәк счет кирәкме, хан сарайлары кебек йортлар, дачалар, төкә машиналар кирәкме? Хәтта түрәләрнең кечерәкләрен алсак та. Минем бер ягымда «Водоканал» атлы оешма түрәсе яши. Ике катлы мансардалы мәһабәт өенә игътибар иткәнсеңдер инде. Шәһәрнең әле бер өлешендә, әле икенчесендә елга булып саф сулар да, юынтык сулар да ага. Черегән торбаларның тишекләренә имән чөйләр кагып өлгерә алмыйлар. Икенче ягымда, колонналы өч катлы йортта «Дорремонт» атлы оешманың түрәсе көн күрә. Үзәк урамда асфальт такыр да ул, чит урамнарга чыксаң… Ярый әле Ходай шул адәмгә күрше иттерде, өемә юлым такыр.

Хуҗабикә түземсезлек күрсәтеп ирен бүлдерде.



– Йә, әтисе, җитәр инде, кунакка ашарга да бирмисен.

Ир туктап калды, графин алып рюмкаларга теге «полезный» эчемлеген койды.

– Чынлап та, мавыгып киткәнмен шул, дускай. Әйдә берәрне күтәреп җибәрик әле. Как говорится, без янганчы, ул яныйн. Бу хәлләрне син белмисеңме дә, мин белмимме…

Фарук Йосыфович, кунакчыл хуҗаларның ай-ваена карамый, кайтырга кузгалды. Дөресрәге, Гапсатаров белән сөйләшкән вакыты җитеп килә иде.

– Ай күрде, кояш алды кебегрәк булды бит әле бу очрашуыбыз. Мин сиңа әкиятләрне байтак сөйләп ташладым, булса кирәк инде, – дип мөләем елмайды сыйныфташы. Тагы әкият җыярга килсәң, – дип күз кыскандай итте ул, – миңа сугылмый китмә. Мине гел үз дөньям, үз бакчам белән генә яши икән дип уйлама, ветераннар советында әгъза булып торам. Бидрәшебез тарихын, бүгенгесен барлап китап язам. Мәскәүләрдән картрак шәһәр бит ул. Борынгы «Ефәк юлында» барлыкка килеп, монгол яуларын үткәргән шәһәр. Аларын үткәргәч, боларын гына үткәрер әле.

– Шуннан. Кайчан язып бетәсен?

– Бетүен беттем инде мин аны. Ничек чыгарырга белмичә йөрим.

Китап чыгару Маша белән минем пенсиягә генә башкарырлык эш түгел. «Үзем өчен түгел, шәһәр өчен бит. Киләчәк буыннарыбыз өчен», – дип Гапсатаровка кергән идем, «Безнең бюджетта андый акча каралмаган», – дип куып дигәндәй чыгарды…

Менә шулай, Фарук дус. Китап китап инде ул. Әлеге көндә бар шөгыльебез – бакча үстерү. Бәрәңге яхшы уңа безнең… Үзебезгә, балаларыбызга да җитә, артып калганын кечкенә пенсияләренә изаланып яшәгән карт-корыга да таратам.

## АК ЙОРТТА

*Кешелек җәмгыяте ике сыйныфтан тора: берәүләренең азыгы бар, аппетиты юк, икенчеләренең аппетиты бар, азыгы юк.*

***Ж. Д. Аламбер***

Акмы алар, яшелме, сорымы – бар Русиядә хакимият бинадарын менә шулай зурлап «Ак йорт» дип атау гадәткә кергән. Янәсе, без кемнән ким, Америкада президент төягән генә шулай

атыйлар, ул бер генә. Бездә һәр шәһәрдә, район үзәгендә, хәтта кайсы бер авылларда да – йөзәрләгән ак йортлар. Иң әһәмиятлесе, аны сыларга-сыйпарга акча табалар, шәһәре ярым җимерек, ташландык булса да, аның «Ак йорты» хуҗасының абруен исбатлап, балкып утырырга тиеш. Фарук Йосыфовичны Бидрәш мэры әлеге балкып утырган йортының биек бусагасында колач җәеп каршы алды. Шәһәр үзәге мәйданын себереп йөрүче дворникларны каядыр аткарганнар иде. Мәйдан таза, уң кулын «Сбербанк»ка сузып, каядыр юл күрсәтеп торган Ленин һәйкәле дә урынында, аның кепкасын да, «Сбербанк»ка күрсәтеп торган уң кулын да күгәрчен тизәгеннән арындырганнар иде.

Гапсатаров кунагын кочаклады, ике битеннән чупылдатып үбәргә дә нияте бар иде, кунакның йөзе бозылыбрак китканен күреп, моны эшләргә кыймады, бары аркасын гына шапылдатты. Фарук Йосыфович хуҗага кул гына бирде дә, кейсын бусага парапетына куеп торып, аяусыз кыздырган кояшка карады, кульяулыгын чыгарып, тирле битен сөртте, эсседән йончыгандай, әлсерәгәндәй тоелган Ленинга күз ташлады.

Мэрның йөгерек күзләре кунакның карашы артыннан иярде.

– Әйе, Фарук Йосыфович, тора. Байтаклар Ильич һәйкәлен җимереп бетте, без тарихи традицияләргә тугрыбыз. Без бит октябрят, пионер, комсомол, коммунист лар булып... короче, Ленин балалары булып тәрбияләнгәнбез. Ә Ленин бабай нәрсә дигән әле?

Фарук Йосыфович көлемсерәде.

– Укырга, укырга, укырга! – дигән.

– Әйе, укырга да кушкан. Аннары илгә намуслы хезмәт итәргә дә өндәгән бит. Минем хезмәттәшләрем һәр көн иртән һәйкәл янынннан үткәндә, шушы өндәүне исләренә төшерсеннәр, дип тә алдырмадым мин аны. Йә ярар, соловья баснями не кормят, диләр урыслар. Әйдә, Фарук Йосыфович, эчкә үтик.

Керделәр, эш өстәле текәтмәсе артында урын алдылар. Гапсатаров җитди төс белән эчке телефон трубкасына дәште.

– Руфина ХөршатовнаИраида Касьяновна миңа керсен әле.

Хатын керде, тыйнак кына итеп сәлам биргән булды.

– Менә, Ираида Касьяновна, кичә шәһәребез кунагы белән танышкан идек инде. Бүген ул безнең мэрия кунагы. Әйдә бергәләп аны мэрия эшләре белән таныштырыйк. Шәһәребезнең социально-экономическое положениесе турында сораулары булса, бергәләп җавап бирик.



Фарук Йосыфович көлеп җибәрде.

– Мин бит сезгә инилидер ревизор булып килмәгәнмен, Энгель Заһидуллович, Ираида Касьяновна, фольклорчы булып килгәнмен. Габделбәр белән Телләкбирдә картларга рәхмәт байтак әкиятләр, мәзәкләр сөйләделәр. Сыйныфташларым Зөбәйдә Зәйнулловна белән Виталий Соломинга рәхмәт.

«Соломин» исемен ишеткәч, хуҗаның йөзе бозыла бирде.

Шул шелкоперга да кердегезмени инде? Пенсия акчасын ашап тыныч кына яши белми, тегендә борынын тыга, монда тыга. Имеш, китап язган, имеш, аны чыгарырга акча кирәк.

Фарук Йосыфович мэрның сүзен бүлдерде.

– Ә чынлап та ярдәм итсәгез?..

Әңгәмәнең бу өлешендә Ираида ханым сүзгә кысылуны кирәк тапты.

– Кайдан алыйк аңа бит йөз меңне? Бюджетта андый акча каралмаган. Язган икән, үзе чыгарсын!..

– Әйе, Касьяновна дөрес әйтә, Фарук Йосыфович. Ярар, сезгә аның кысылышы юк. Шәһәрнең бүгенге торышын барлап үтсәк, мөгаен шунысы сезгә кызыграк булыр. Әйе, менә тәнкыйтьләү-челәр күп. Химзаводны япты, Механика заводын япты, Спирт заводын япты,Кирпеч заводын япты, Шикәр заводын япты, мал симертү комплексын юкка чыгарды... Сезнең дә колагыгызга аз пышылдамагангардыр... Моны бит заманча фикерли белмәгәннәр әйтә. Башка шәһәрләрдә башка предприятиеләр ябылмаганмы? Яшибез бит...

– Ничек яшисез? – дигән сорауны куйды үзе дә аңгармастан Фарук Йосыфович.

Ираида ханым калкына биреп куйды.

– Менә дигән итеп яшибез, Әюпов әфәнде. Эчәсен эчәбез, ашыйсын ашыйбыз...

– Халык ничек яши, предприятиеләр эшләмәгәч, кайдан таба яшәү чыганагын?

Гапсатаров хихылдап көлеп җибәрде.

Халык ул таракан белән бер, җаен таба. Бер тәрәсе вахтага – Халык ул таракан белән бер, җаен таба. Кайсы берләре хәер йөри, икенчеләре сәүдә итә, өченчеләре урлый... Кайсы берләре хәер дә сораша.Шундый бер мәзәк тә бар бит. Бер хуҗа завод эшчеләренә акча түләми икән. Өч ай түләмәгән, ярты ел. Директор урынбасарыннан сорый, имеш: «Эшкә йөриләрме әле эшчеләребез?». Урынбасары: «Йөриләр, Иван Иванович, йөриләр сволочьлар!» «Бәлки, проходнойдан түләтеп үткәрә башларга кирәктер?!.»

Бу юлы кычкырып көлү ике авыздан яңгырады, кунак кушылмады.

– Менә шулай, Фарук Йосыфович, сезнең сыйныфташыгыз Соломин сүзләренә караганда, безнең Бидрәш Париж белән Лондоннан да, Мәскәүдән дә картрак, имеш. Чыңгыз хан яуларын да үткәргән, Аксак Тимерне дә, Туктамышлыкын да, Кудеяр атаман да талаган аны, Степан Разин да... Юкка чыкмаган бит. Лотуңг язып элеп куйсаң да була: Бидрәш булган, Бидрәш бар, Бидрәш булачак!

Без бит борынгы сәүдә юлында утырабыз. Безгә күрше Казак далаларыннан да киләләр, кыргызлар белән үзбәкләре дә килә, төрекләр белән әзербайҗанлылар да, әрмәннәр белән грузиннар да. Хәзер инде кытайлар иңләшеп бара. Әле бушап калган спирт заводын сорыйлар. Ниятләре: тегү фабрикасы ачып, безнең халыкка арзан кием житештерү.

Без кунакны сүз белән генә сыйлыйбыз түгелме, Иранда ханым. Әйдә, син дә ике-өч сөйләм белән генә шәһәребезнең икътисади хәленә төшендер дә...

Хрипунова ятлап алган кебек сөйли башлады.

– Икътисади хәлебез тотрыклы. Агымдагы елның алты аенда былтыргының алты ае белән чагыштырганда налогны 1,3 процентка артыграк җыйдык. Шәһәр бюджетының 33 процентын...

– Ярар ул подробностьләренә кереп торма, – дип бүлдерде аны хуҗа кеше. Ничек инде бюджетның өчтән бере генә шәһәр акчасы, өчтән икесе дәүләт дотациясе дип әйттереп утыртсын. – Хәзер мин, Иранда Касьяновна, Фарук Йосыфовичка конторыбызны күрсәтеп киләм, ә сез Руфина Хөршатовна белән арткы бүлмәдә чәй әзерли торыгыз. – Бу сүзләрен әйткәндә, аның бер күзе бичәгә, бер күзе кунакка карый иде. Бичәгә караганы сизелер-сизелмәс кенә кысылып куйды. – Тамак китте, чәйләп алырга вакыттыр. Шулай бит, Фарук Йосыфович.

– Кунак хуҗаның ишеге, – дип елмайды ир.

– Алай булгач, киттек.

Алар бүлмәләр буйлап үттеләр. Сайранов кисәтеп куйган хезмәткәрләр бүген чәй дә эчмиләр, бүлмәдән бүлмәгә йөреп гайбәт тә сатышмыйлар иде. Барысы да эшлекле төстә, йә компьютерга текәлеп, йә нидидер кәгазь язган булып утыра. Хатын-кыз хәтта затлы киемнән дә килгән. Барысы да хуҗа белән кунакны басып сәламләде.



Фарук Йосыфовичның күңеленнән әле кичәге «тантана»дан калган тәэсоратлары да чыгып бетмәгән иде әле. «Тәҗрибәле прокуродимец! Тик минем күзгә нигә шул чаклы төтен очырырга кирәктер? Хәер...» – дип уйлап алды ир.

Ул арада хуҗа кабинетында торып калган Иранда ханым яләп кенә кунакның кейсын ачты. Сыйныфташларына тагаенләнгән күчтәнәчләрдән тартма бушап калган иде. Бик уңайлы түгел иде шул. Аны ачу белән ир юктан бар булган ике капны күрәчәк. Җәнжал күтәрүе дә мөмкин. Тик монда аны иншләп ачып карап утырсын әле ул?

Өстәмә саклану чарасы да табылды. Тартманың арткы өлешендә замокка ябыла торган күренер-күренмәс, беленер беленмәс бер кесәсе дә бар икән. Бичә ике капны шунда тыгып сыйпап куйды. Тартмасын ачса да, монысын тиз генә ачмас әле ул! Тиз генә тапмас! Ә тапкач инде соң булыр. «Минем кейска ялгыш бер миллион акчагыз төшеп яткан икән», – дип йөгереп килмәсә, мәгаен, башы җитәр.

Сыйлы өстәл артында урын алдылар. Зөбәйдә сыйныфташында Сәрия телне йотарлык итеп койган коймагы белән чәй эчеп, Витаций классташында аның «исключительно полезный напитогын» чөмереп, ысланган дуңгыз кабыргасын кимереп килгән Фарук Йосыфовичның тамагы тук иде. Тик, тамак тук дип, ничек инде анау хәтле сыйлы өстәл артына утырудан баш тартасың. Җитмәсә, шәһәр мэры Гапсатаров әлтереп тора да, аның ярдәмчесе Иранда ханым келтереп тора.

– Ничек? – диде мэр, – берәрне йотып җибәреп, кара икраны кашык тутырып эчемлек артыннан аткаргач, – Бидрәш турында тәэсоратларыгыз ничек?

Иранда ханым түрәсе сүзен тагы эләктереп алды.

– Энгель Заһидуллович, шәһәр безнеке генә түгел икәнлеген онытып ташламагыз. Фарук Йосыфович шушында туып, шушында үскән егет.

Бидрәш безнең уртак йортыбыз. Туган йортка карата начар мнение булырга мөмкинме соң? Шулай бит, Фарук Йосыфович! – Хатын үзенең уңышлы сүзләренә үзе риза булып шаркылдап көлеп җибәрде. Аңа хуҗа үзе кушылды.

– Онытканы юк инде ул. Кунак, бәлки, риза да булып кайтып китәр дә ул, тегендә... Әйткәндәй, Фарук Йосыфович, Безнең Буйновский белән очрашканыгыз бардыр бит?

– Юк, – диде кунак елмаеп. – Губернатор хәтле губернатор һәр кандидат наук белән очрашып гәпләшеп утырса, аның башка бөек эшләргә ничек вакыты калсын.

Табын хуҗалары икесе дә хәйләкәр елмайды.

– Ну, сез бит инде гади кандидат наук кына түгел. Мөгаен, бер очрашмасагыз бер очрашырсыз әле. Әйтегез...

– Әйе, әйе, әйтегез, – дип хуҗасы сүзен эләктереп алды бичә. – Без монда аны бик нык ихтирам итәбез. Закупанск шәһәре мэры булып торганда да, өлкәнең налог системасын җитәкләгәндә дә үзен искиткеч оста оештыручы...

Гапсатаров бичәнең алга чыгарга атлыгып торуына ризасызлык белдерде. Шәһәрдә кайсыдыр юньсезе хәбәр тараткан. Имеш, Гапсатаров пенсиягә китә икән дә, аның урынына Хрипунова кала икән. Бу бичә әллә шушы гайбәт нигезендә үзен мэр итеп тоя да башлаганмы. Алай булса, Гапсатаров аның муенын тиз борыр. Губернатор фарманымы, үзенең теләгеме белән генә китмәсә, Бидрәштә аны урыныннан шылдырырлык әтрәк-әләм юк әле. Һәм булмас та!

– Әйе, Фарук Йосыфович, миңа эш буенча да, болай да (мэр сыйлы өстәлгә ишарә ясады) Буйновский белән очраштырырга туры килде. Исключительно акыллы кеше. Намуслы... – Монастырев кебек сөмсез ришвәтче түгел, – дип тә әйтергә уйлаган иде, монысы артык булырын чамалап, әйтмәде. – Аның җитәкчелегендә өлкәбез зур уңышларга өлгәшәчәк әле. Ә безнең хәлләргә килгәндә... Бик катлаулы шартларда яшибез бит. Минем җилкәдә...

– Әйе безнең җилкәдә, – дип хуҗасы сүзенә тагы кысылды, иртә инде берәм-берәм күтәргән рюмкаларыннан байтак ук кызмача була барган Ираида ханым.

– Минем җилкәдә, – дип сүзен дәвам итте Гапсатаров, «минем» сүзенә басым ясап, – Бидрәш шәһәре генә түгел бит әле, тоташ район да. – Унбер колхоз, өч совхоз.

Ираида ханым нык ышанычлык күрсәтте.

– Әйе, унбер колхоз, өч совхоз бар иде. Без аларны...

– Ираида Касьяновна, дай слово сказать своему шефу! – дип аны туктатты хуҗа кеше.

– Әйе, без аларны таркаттык, как пережитки социализма. Әйдә, пусть живут вольной жизнью.

– «Коммунизм юлы» совхозындамы? – дип, ниһаять, сүз кыстырды кунак та.



– Әйе, аны да. Югыйсә, үзебез ит җитештерәбез, үзебезгә... – сугым малының башы белән тояклары гына кала, – дип әйтергә уйлаган иде мэр, бу уеннан тагы кире кайтты. Горком секретаре үгез башы белән үгез тоякларыннан холодец ашап яшәгәненә барыбер ышанмас.

Фарук Йосыфович бу икәүне тыңлап, дөресен әйткәндә, аптырап утырмады. Иксез-чиксез Рәсәй киңлекләренә сибелгән башка шәһәрләр, башка авылларда түрәләр ничек яши дә, халык ничек яши соң!.. Аптырарлык нәрсә бармыни...

Очрашу азагында инде Хрипунова гына түгел, Гапсатаров та байтак исереп алган иде.

– Так ышта-о-о, – диде көрмәлгән теле белән мэр, – хөрмәтләрдән хөрмәтле беренче секретарь... түгел дә, губернаторыбыз Бай... Буйновскийга әйтегез, без аны хөрмәт итәбез. Юк, юк хөрмәт кенә итмибез, яратабыз... – Иренең бу карлыккан чыгышы ничектер элекке ил башлыгының айнык булмаган телмәренә ошап китте.

– Үз атабыз кебек яратабыз!.. – дип Фарук Йосыфовичны кочаклап ук алды Ираида ханым. Губернатор эргәдә булмагач, күрәсең аны ни дәрәҗәдә яратуын Фарук Йосыфовичны кочаклап белдерергә теләгәндер.

Тәкъдим ителгән машинадан кунак баш тартты. Яшьлек шәһәренә кайт та танктай кара джипта, шәһәренең кечкә торышын кап-кара пыяла аша күзәтеп ваемсыз гына йөр әле... Юк, бу аның аңына сыймый. Капма-каршылыклы уйларына бирелеп, шәһәр урамнары буйлап җәй гына атлады. Артыннан әлеге тугызлы «Жигули»ларен килүен күрми-сизми буламы соң инде ул, тик игътибар итмәгәнгә сабышты. Мескен «курган солдатлар...» дип үзалдына көлде дә әле.

Көндезге эсселек бераз басыла төшкән иде. Капкадан кергәч тә, кунак ишек алдындагы «шак» та «шок» иткән тавышка игътибар итте. Көртнеп салып ташлаган, күлмәге җиңнәрен сызганган Габтүмәргә чабып куеп, башын күтәрде, билен язды.
делбәр карт, мунчасына яңа бусага ясап ята иде. Ул балтасын

– Ә, кайттыңмы, улым? Сине көтә-көтә көтек булдым. Ачык-
кансыңдыр, сусагансыңдыр инде.

Фарук Йосыфович көлеп җибәрде.

– Көне буе кунак булып йөрдем, Габделбәр абзый. Тамагым
сыйлы. Бик бирелеп ни эшлисең болай?

– И-и-и, сөйләмә дә инде, Фарук улым, мунчамның бусагасы че-
рәп сынып бара, шуны яңартам. Югыйсә, оят булачак бит...

– Кемнән ояТ?

– Теләкбирдә шалтыратты. Якшәмбе көн базарга киләм, ди. Фаягөлне дә утыртып алып киләм, ди. Калашем алдында оят булачак бит. Мине бер эт ялкавына чыгарып куйса... Никахтан баш тартса?

– Тартмас, Габделбар абый. Синең кебек егетләр жирдә аунап ятмый ул.

...Сержант Куроед белән рядовой Максименко подполковник Самохваловның ишеген шакыдылар.

– Керегез.

Керделәр дә, формада түгеллекләрен онытып, тагы честь бирделәр.

–Иптәш подполковник...

– Сколько раз вам можно повторить: с пустой головой честь не отдают!

– Иптәш подполковник, объект больше никуда не заходил, прямо пошел к своему старику. Проводили до ворот.

– Ладно, завтра с утра будьте на месте.

Хезмәткәрләре чыгып киткәч үк Самохвалов Гапсатаровка шалтыратты.

– Энгель Заһидуллович, объект от вас прямо направился домой к старику, больше никуда не заходил, ни с кем не встретился.

Гапсатаровның күңеле иләс-миләсрәк иде, шулай да ул полиция турәсенә бәйләнеп тормады, «Ладно»сы белән әңгәмәне тәмамлады.

## Иртәнге хәлләр

*Һәркем кояшны үзенчә күрә.*

***Курд халык мәкале***

– Йә, шәһәр буйлап кичәге сәяхәтең нинди тәэсирләр калдырды, Фарук улым, нинди әкиятләр язып алдың? – дип кызыксынды Габделбәр карт, иртәнге чәйне эчеп капка төбендәге эскәмиягә чыгып утырган кунагыннан. Фарук Йосыфович иртәнге шәһәр тормышын күзәтә иде. Кояш, дилбегә буе күтәрелеп әлеге спирт заводының төтене чыкмаган торбасы тиңгәленә житкән иде. Көне бүген дә эссе булырга охшый. Шуның өчендер, күрәсең, халык бүгенге эшләрен,



көндез урамда әлсерәп йөрмәс өчен, иртәрәк башкарып калырга ашыга. Өлгер бичә Хөршидә ишек алдындагы кош-кортларын ашатырга да өлгерде, каядыр йөгереп кенә чираттагы йомышын йомышларга да барып килде, Фарук Йосыфовичның хәлен дә белешергә, ишек алдына кереп Габделбәр карт ясап куйган мунча бусагасына үз бәһасын да бирде, янадан кунак янына килеп утырды.

Каршы йортта көн күргән Сафура йокыдан тормаган иде әле. Аның карауы ире Сакау Бакый торган, йокылы күзләрен тырнаймтырный кыйшайган капкасыннан килеп чыкты. Кырынмаган, кием тузгалган, аягына да иске калуш кенә эләктергән. Ул урамдагы тормышка шатланып китте, булса кирәк. Дөресрәге каршы капка төбендә гәпләшер кешеләр барлыгына. Алпан-тулпан дигәндәй алар янына килде. Авызыннан тәмәкесен ычкындырмый гына:

– Пливет күлшеләлгә, – диде.

Аңа Хөршидә жавап бирде.

– Нихәл, Бакый. Нәрсә бүген дә махмырдан интегәсеңме?

– И Хөлшидә күлше, биглә сизгелсең инде. Үзең үк минем хәлне белеп толасың.

– Көн дә салмышсың, синең хәлеңне белеп тору өчен нинди сизгерлек кирәк булсын?

– Бәй, шулай булгач, бал инде, йөгелеп келеп кенә бел шешә «тенно куганыңны» алып чык. Менә кунак абыйның да башы авыттадыл...

Габделбәл абзыйга кунак килгән дигәнләл иде, күлешелгә дә насип булды. – Ул, ниһаять Фарук Йосыповичка бик үк таза булмаган кулын сузды.

– Мин элекке «Коммунизм юлы» совхозының элекке зоотехнигы Билдегулов Бакый Бәкелович, ягъни дә БББ, булам. Күләсез, әлеге өч Б «Сакау» дигән кушаматыма бик тә килеп тора. Әлеге көндә Әлим бай кибетендә глузчик булып йөлим. Бүген хаклы ялымда...

Запастагы полковник отставкадагы зоотехникның кулын кысарга туры сарга тартынмады. Үз гомерендә нинди генә куллар кысарга туры килмәде аңа. Африка негрынықын да, Мексика индеецынықын да, Никарагуа мулатынықын да, дәүләт эшлекләреренеке дә, автомат прикладына ышкылып шомарып беткән Колумбия партизаны кулын да...

– Ә мин Фарук абзыең булам, Бакый энем. Фольклор жыючы галим. Менә әле туган үскән шәһәремә кайтып төштем.

– Димәк әкиятләп, мәзәкләп җыясың инде, абзый? Тик теге «Кавказская пленница»дагы Шурикка бел дә охшамагансың бит әле. Оппатсың... Ялал, алай булгач, минем дә бик шәп тост бар. Калале, Хәлшидә күлше, Нишләп һаман җәелеп утыласың, бал, алып чык инде!.. Колы кашык авыз җыпта, ди. Хөмелсез тост, ул минем кысыл Сафулам кебек.

Ул арада Хөршидә үзе йөгереп кереп шыптыр пакетта Бакый тилмереп көтеп торган «күчтиз»не алып чыкты.

– Син барыбер көне буе йөдәтәчәксең, менә. Келәтем ишеген юнәтергә вәгъдә биргәнеңне онытма. Югыйсә, Әлтәфемнең бер дә генә вакыты юк.

– Әйдә, киттекме, абзый. Сафуланы уятылбыз, баш төзәтелбез. Минем әйне дә күлеп чыгалсын...

– Юк, туган, – диде Фәрук Йосыпович, елмаеп. – Кунакка чакыруыңа рәхмәт, бүген эшләрем күп.

– Әйе, – дип көлде Хөршидә, – башкала кунагының синең сыек сыеңа гына калган көне бар иде...

– Ул арада каршы капка кыйшайган ягына ачыла бирде, тәүанда хуҗабикәнең чәче тузган башы, аннары иске халат белән генә каплаулы чиксез юан гәүдәсе күренде. Ул урамга күз йөгертте, арт ягын кашып алды, аннары карашын каршы капка төбендә утырган очәүгә юнәлтте. Карап торды да чәрелдәп кычкырып җибәрде.

– Бакый! Син нишләп утырасың анда? Габделбәр карт кунагы белән шешә төбе яларга чамалыйсыңмы? Кайт! Һаман өйне җыештыр-магансың, ашарга пешермәгәнсең.

Бичәсен күрү белән, Бакыйның күзләре, каймак ялап тотылган песинеке төсен алды, ул Хөршидә күршесе чыгарып биргән капны тиз генә кесәсенә яшерде.

– Хәзер, бичәкәем, кайтам, хәзер! – дип үзе таба атлады. – Әле иртә, ун да тулмаган, бәләнге пешкәнче, чәй кайнаганчы ятып торсаң да була.

Хөршидә аның артыннан әллә мыскыллабрак, әллә кызганып карап калды.

– И мескен ир, белеме дә бар... Башы да! Җитмәсә бөек кешеләр генә сакау була ул, әнә Ленин бабай... – дип шаяртакан була бит әле. Юньле бичәгә эләксә, бәлки, менә дигән итеп дөнья көтәр иде. Ә бу ялкавының кулыннан бер эш килми, көне-төне дигәндәй йокы симертә дә, капкасы төбендә сагыз чәйнәп утыра. Кош-корт кыяк да алып асрамый бит...



Фарук Йосыфович Сафура сүзләреннән ни көләргә, ни еларга белми утырып калды. Ул, әлеге бичә күзлегеннән караганда, аның сәрхүш иренең шешәдәше булырга җыенган икән, имеш. Үзен үзе «аклау» өчен янында утырган Хөршидәгә сүз кушты.

– Күрше, Бакый кебек ирләрне урыслар «подкаблучник» дип атаганын беләсеңдер.

– Аны белмәгән кая инде ул, Фарук абый! Ирләр токымы корып бара ич!.. Берәр юньлесен таба алсам, мин ялгыз яшәр идеммени? Юк, Өлфәтемне генә өйләндерәм дә, үзем дә кияүгә чыгам, Аллаһы боерса. Габделбәр күрше өйләнергә йөргәндә... мин аңардан киммени?

– Кандидатура таптыңмы соң, Хөршидә күрше.

– Берәү артымнан йөргән була да ул...

– Соң?

– Әлек, сез партиягә керер алдыннан нинди стаж үтә идегез әле, Фарук абый?

– Кандидатлык стажы инде. Бер ел.

– Вәт, ул да кандидатлык стажы үтә. Бер авызым пешкәч, икенчесен өреп кабарга туры килә.

–Ярар, хәерлегә булсын. Бер мәзәк искә төште әле. Ике «подкаблучник» ир очрашкан, имеш. «Нихал...» «Нихал...» «Ә мин бүген бичәмне тыңламадым». «Ничек?!.» Ул, чүп-чарны контейнерга чыгар, дип әмер бирде. Мин, чыгармыйм, дидем. Ул, чыгар, ди. Мин, чыгармыйм, дим. Ул, чыгар, ди. Мин, чыгармыйм, дим... Ахры да, бик тенкәгә тигәч, күзен чыгарганчы әйттем тегеңә». « Нә әйттең?!. «Хәзер, идәнне генә юып бетәм дә, чыгарам, дидем. Вот!»

Мәзәк Хөршидәгә бик ошады, ахрысы, ул бар урамны яңгыратып көлеп җибәрде.

– Сез, Фарук абый, чынлап та, әкиятләр, мәзәкләр җыеп йөрисез, булса кирәк.

– Җыям, – диде Фарук Йосыфович, җитдиләнә төшеп, – Хәер, алар үзләреннән үзләре җыела.

Фарук Йосыфович Габделбәр картка кичә күргәннәрен сөйләп алды.

– Озак еллар күрешмәгән ике сыйныфташым белән күрештем. Зөбәйдә һәм Виталий белән.

– Кайсы Виталий белән ул? Соломинмыни? Безнең газетнең элекке мөхәррирлемени?

– Укытучы Зөбәйдәне, аның чибәр кызы Сорияне беләсең инде, Габделбәр абзый. Соломинны кайдан беләсең?

– Син дә әнем, мине бик кара кешегә саныйсың, ахры. Гомерем буе үзебезнең «Путь Ленина»ны алдырып укып бармаган дип беләсеңме әллә мине? Ул Виталий дигән сыйныфташың эшемә барып, өебезгә килеп минем турыда мәкалә дә язган иде. Исән-сау гынамы әле?

– Исән-сау. Бичәсе белән бакча үстерәләр, дуңгыз симертәләр.

– Ярар, тик язмагач, яхшы…

– Шәһәребез турында китап язган.

– Монысы бигрәк тә яхшы! Безнең борынгы Бидрәшебез моңа лаеклы.

– Тик чыгарырга акча гына юк, ди.

– Җыярга кирәк. Минем үземнең үлемлеккә дигән маям бар. Бирәм! Җан тәслим кылсам, җирдә яткырып калдырмаслар әле. Башкалар да бирер…

– Юк, Габделбәр абзый, картларның үлемлек акчаларын җыеп алып китап чыгару хилаф эш булыр ул.

Габделбәр карт мангаен җыерып уйга калгандай булды.

– Соң… Өченче көн әллә синең белән мине сыйларга, әллә үзләре сыйланырга күпме акча сарыф иттеләр. Шул акчаны китап чыгарырга тотынсалар…

– Алай итмиләр шул, Габделбәр абзый. Виталий китап чыгарырга ярдәм итүләрен сорап Гапсатаровка кергән дә ул…

– Шуннан?

– Бюджетта андый акча каралмаган дип куып чыгарган.

Габделбәр картның йөзе кызарып китте. Юньсез мәрны тыңлаусыз үгезне суккан кебек сүзләр белән сүгәсе килде.

– Ах, атасының башы. Андый икәнен белсәм өченче көндәге пәри туйларына бармаган булыр идем. Бүген үк бүлмәсенә кереп әллә сүгеп чыгыйммы үзем. «Сволочь!» – диярмен. «Канэчкеч!» – диярмен. «Капкорсак!» – диярмен…

– Фарук Йосыпович картның тузынып бетүен тыныч кына көтеп утырды. Давыл тына биргәч:

– Кызганычка каршы, бер нәрсә дә чыкмас, Габделбәр абзый, – диде.

– Ничек бер нәрсә дә?..

– Акчасын да бирмәс, полиция чакыртып сине КПЗга яптырып та куяр.

– Ни өчен?

– Власть кешесен эш урынында мыскыллаганың өчен.



Әтәчләнгән картның кикригә шинә бирде.

– Нишлибез соң, Фарук улым.

– Минем бу мәсьәләгә карата планым туа бирде инде. Кудеярга кайткач, аның бер очын табарга тырышырмын. Менә син, Габделбәр абзый, әйт әле, Гапсатаровларның, Сайрановларның, Хрипуноваларның, Самохваловларның, Клептомановларның һәм башкаларның бүген власть утырырга хаклары бармы, әллә аларның барысын бергә себереп түгеп, яңаларны куярга кирәкме?

– Юк! – диде һаман да кызуыннан сүрелеп җитмәгән карт. – Кирәк! – диде аннары. Тагы уйланып утыргандай итте. – Бу урлашып череп баеганнарын себереп түксәң, урыннарына яңалар киләчәк бит! Аларына баерга кирәк булачак! Тагы угрылык, тагы ришвәтчелек, тагы кәр…кәр…

– Коррупция дип әйтергә телисеңдер, Габделбәр абзый.

– Әйе, тагы да кәррүпсия!

– Шуннан?

– Белмим, Фарук улым. Ярар, минем башым министрлар советы түгел. Сез инде үзегез карагыз… Кичә кич бит мәчеткә барып килербез дип сөйләшкән идек. Әйдә, җыеныйк.

– Әйе, Габделбәр абзый, башыбызда туган чиксез сорауларга җавапны бәлки, Аллаһы йортында табарбыз.

## АЛЛАҺ ЙОРТЫ

*Исәрләр һәм әрвахлар гына фикерләрен үзгәртмиләр.*

*Д. Лоуэлл*

1917 елда инкыйлаб кәсафәтен кичереп, аның аерылгысыз юлдашы гражданнар сугышы атлы мәхшәрен үткәргәннән соң, яңа, динсез, тормыш төзүчеләр, ул тормыш төзүне кайсы очыннан башларга икән дип, озак уйлап тормадылар. Тоттылар да әле хан заманында ук төзелгән мәчетнең манарасын кисеп аудардылар, атаклы Троицк мәдрәсәсен тәмамлап кайткан указлы мулла Мөхәммәдрәхимне Себергә озаттылар.

Ә бар шәһәргә ямь биреп утырган мәчет бинасы, таҗыннан мәхрүм ителеп, «клуб» исемен алгач, кечерәеп, мескенләнеп калды. Шулай булса да таштан берәр метр калынлыкта салынган диварла-

ры берииндә янгыр-давылларга бирешерлек түгел иде әле. Шөһәрнең икенче читендәге шикәр заводы төзегән Малинин сарае бик үз итмәделәр, шушы клуб тирәсендә чуалып үтте Фарук, Фәрит, Зөбәйдә, Виталийларның балачагы, үсмер еллары. Киноларга, танцыларга йөрделәр, концертларда, спектакльләрдә катнаштылар.

«Коммунизм юлы» совхозы эшчеләре Яңа ел бәйрәме булсынмы, 8 Март, 1 Май, Җиңү көне, Октябрь бәйрәмнәре булсынмы – шушында җыела, шушында күңел ача торган иделәр. Аларның күр кәефен хәтта парторг Садрый Сәүбәнович Ишкуловның Габделбәр карт арканы озынлыгы телмәрләре дә бик боза алмый иде. Шулай кирәк булгач, Садрый әйтмешли, партия, хөкүмәт шулай кушкач. Ә парторг телмәрләрен кылганда... Ай-һай, оста иде бит ул доклад сөйләргә! Дөрес кайсы бер шаянрак адәмнәр, ул докладларның барысы да бер кәгазьдән укыла, парторг аның бары бәйрәмнәренең исемнәрен дә, чакыруларын гына алыштыра, дип көлә иделәр. Булса да булыр. 7 ноябрьдә трибунадан: «Яшәсен Бөек Октябрь социалистик революциясенең ...еллыгы! Коммунистлар партиясе белән совет халкының какшамас бердәмлегенә дан!» – дип кычкырасың да, 8 Мартта «Яшәсен Халык-ара хатын-кызлар көне! Совет хатын-кызларына дан!» – дип кычкырасың.

Ә фойедә сыра сатыла башлауны, залда концерт башлануын зарыгып көткән малчыларга барыбер түгелмени?..

Теге бәйрәмнәр бетте дип әйтерлек. Башкалары барлыкка килде. Хәер, клуб та янадан мәчеткә әйләнде бит инде. Югыйсә, ул клуб килеш калып, Садрый да парторг булып калса,нишләр иде икән. Халык бит яңа бәйрәмнәрне санга сукмый, хәтта сөрсегән алкашлар да ул көннәрдә айнык йөрүне хуп күрә. Мәсәлән, «Халыклар бердәмлеге көне» дип игълан ителгәнен. Исеме матур, җисеме дә начар түгел. Тик ул бит Рәсәй халкы революцияне, революция бәйрәмен онытсын, дип көнә эшләнгән эш. Имеш өч көн алдан монысын бәйрәм итсеннәр дә, тегесенә чыгып тормасыннар. Хәер, яхшы тарихи дата да ул! 1612 елның 4 ноябрендә Кузьма Минин белән Дмитрий Пожарский җитәкчелегендәге яу баскынчы поляклларны Мәскәүдән себереп чыгарган. Урыслар, татарлар, мордвалар, марилар, башкортлар, чувашлар – һәммәсе бергә. Бәйрәм итәргә дә була. Тик мәчет бар, клуб юк. Шуның өчен хәзер инде Садрый мулла җомга вәгазен шушы бәйрәмгә арнаган, диләр. «Яшәсен Рәсәй халыкларының дуслыгы! Урысларга, яһүдләргә, татарларга, башкортларга бүленмик, җәмәгать! Диннәребез төрле булса да, ал-



лаларыбыз төрлечә аталса да, безне Булдыручы, саклаучы һәм яклаучы бер! Һай дөрес әйтә икән! Юкка гына егерме биш ел буе парторг булып тел шомартмаган шул.

Бу мәсьәләдә бер оппозиционер табылулыкка табылган да ул. Ул да булса Сакау Бакый. Кызмача булып алган да, имеш, сөйләнеп йөри, ди.

– Садрый мулланың сүзләре дөрес, агай-эне, әйе Мәскәүне поляклардан җыелма ополчение коткарган. Ләкин ул бит хакыйкатьне ачып бетерми. Гаскәр башында кемнәр торган? Ике татар: Нижгар керәшене Кузьма Минин белән, татар өндән дөньяга килгән кенәз Дмитрий Пожарский. Һай, безнең татарлар белән башкортлар булдыра ул! Нишләптер шәһәр полициясе аның хилаф сүзләрен хулиганлыкка санаган һәм бер төн айныткычта кундырып чыгарган.

Ә Садрый мулланың парторг чагында язган докладлары, чынлап та, әле сөйләр вәгазьләренең нигезен тәшкил итә икән. «Ленин» сүзе урынына Аллаһ исемен куй да, Маркс урынына Ибраһим пәйгамбәрне йә Сөләймән пәйгамбәрне куй. Алар да яһүдтән, Сагалбай да шулар затыннан. Бу шөбһәләре турында Садрый муллага әйтеп караучылар булган, тик ул андыйларга: «Мин элек тә коммунистларны да, гади халыкны да яхшылыкка гына өндәдем, хәзер дә мөслим-мөслимәләрне тик изгелеккә генә өндим», – дип җавап биргән, имеш.

Болар турында Фарук Йосыфовичка Габделбәр карт юлда барганда сөйләде. Картның кунагы бер көлде, бер җитдиләнде. Әйе, заманы нинди, мулласы да шундый шул...

Бидрәш шәһәренең имам-мөхтәсибе Садретдин Ишкулов ике мөслимне мәчет күтәрмәсенә чыгып ук каршы алды. Фарук Йосыфович Габделбәр картның, кичә йомга намазына килүен, Садрый хәзрәтне, иртәгә монда Кудеярдан килгән зур кунакны алып килдем дип кисәтүен белми иде әле.Көн инде байтак эссе, дип тормаган, яшел чапанын ябынган, башына ак чалмасеннәнде дип тормаган, яшел чапанын ябынган, башына ак чалма-

күнегелгән йола иде. Ул Садрый Ишкуловның парторг чагын хәтерләмәсә, аның комсорг чагын хәтерли иде. Мәчет эченә үтәр, әңгәмә башлар алдыннан, ул борынгы бинаның әлеге хәленә игътибар итте. Сыланган-сыйпалган, ап-ак итеп агартылган, түбәсе яшел калай белән ябылган. Дини тәгълимәт өлкәсендә ничегрәк йөзәдер, әмма хуҗалык эшләрен башкарырга тырыша икән, дигән фикергә килде Фарук Йосыфович.

Элекке клуб эчтән дә ярыйсы гына тәэсир калдыра иде әле. Утырышып , хәл-әхвәл орашкач, Габделбәр карт, кесәсеннән чыгарып хәзрәт өстәленә терәтеп куелган өсте ярыклы яшел тартмага алсу кәгазь акча төшерде. Фарук Йосыфович карт хәрәкәтен кабатлады. Тик аңлашыладыр инде, аның төшергән кәгазе икәү, кәгазьләренең төсе дә кызылрак иде.

– Йә, – диде хәзрәт, – Хәзер сездән хәер китеп яткан әрвахларыгыз исәнлегенә дога кылсак та була. Фарук Йосыфовичның әтисе белән әнисе Низаметдин улы Йосып, Хәләфетдин кызы Нәсимә, Габделбәр картның халәл җефете Хилалетдин кызы Гашүрәләргә арнып дога укылды. Әйтергә кирәк, бик җәйләп, бик җентекләп укыды парторгтан мулла булган имам. Фарук Йосыфович хәтта моңа аптырабрак та утырды.

Инде әңгәмә дөньяви мәсьәләгә күчкәч итәгатьле генә итеп әлеге соравын бирми булдыра да алмады.

– Әтием Сәүбән бик дини кеше иде. Миңа баләкәйдән байтак догалар өйрәтте. Заманы шундый булгач, дин юлыннан китмәдем инде. Институт тәмамладым, үзебезнең совхозда баш агроном булып эшләдем, менә Габделбәр абзыйлар (ул да заманында коммунист иде бит) парторг итеп сайладылар… Ә бүген килеп… Әйткәндәй, сез бит инде бездән, бывший парторгларлан, көләсездер. Ә өстә, Кремль тирәсендә, чуалган «демократлар» бөтенләй кешегә дә санамыйлар. Элек вузларда «КПСС тарихы» белән «Фәнни атеизм»нарны укытып йөргәннәрен оныттканнар. Беләсегез килсә, мин, кайсы бер заман муллалары кебек, әлеппе таякка санаганнар токымыннан түгел. Читтән торып укып, Ырынбурның атаклы «Хөсәения» мәдрәсәсен тәмамлаган кеше. Ә инде «Фәнни атеизм»га килсәк, Ленинның, коммунистларның төп хатасы да шул булды да инде. Имеш, дин – халык өчен әфьюн ул…

Габделбәр карт мулланы бүлдерле.

– Син – алдынгы малчыбыз, синең кебекләр дә партиягә кермәгәч, кемнәр керә, дип үгетләгәч кергән идем инде. Үкенмим,



мин партия гә сылтанып, «Алла юк» дип кычкырып йөрмәдем, фермадан катнашазык урламадым. Садретдин мул… парторгның кушкан йомышларын үтәдем…

Габделбәр картның сүзләренә Фарук Йосыфович та кушылды.

– Димәк, хәзрәт, без өчебез дә бывший коммунистлар. Ничәдер еллар үткәч, мәчеттә очраклап эшләр әйтеп, бит сыпырып утырырыбызны күз алдына китерә алыр идек микән?

– Сез ничектер, мөселман кардәшләр, мин китерә алмас идем. Тик барысы да Аллаһ хөкемендә бит. Заманында КПСС-ның «Моральный кодекс строителя коммунизма»сы Коръән Кәримгә таянып язылмаган иде микән? Аның күп маддалары изге китап аятьләренә туры килә түгелме? Димәк, партия идеологлары кемнәр булганнар, Фарук энем?

– Графоманнар дип әйтергә телисеңме Садретдин абзый?

– Шулайрактыр инде… Партия дә бит үз заманында кешеләрне начарлыкка өндәмәде. Христиан тәгълиматенә дә таянды: үтермә, урлашма, зина кылма! Хатынына хыянәт итеп, «читкә йөргәннәрне» бюроларда ничегрәк утлы табага бастыра идек әле? «За моральное разложение исключить из рядов партии, выгнать с работы»мы?

– Аныссын хәтерлим, хәзрәт.

– Нигә, аллә сиңа да эләктеме?

– Юк, минем эштә, андый нәрсәнең булуы мөмкин түгел иде. – Фарук Йосыфович артыгын әйтеп ташлавын аңлады.

Сүзгә Габделбәр карт кушылды.

– Элек булмагандыр да, бәлки, агай-эне, хәзергеләр инде, иң өстәгеләре дә, хатыннарын да аералар, болай да йөриләр, дүртәр-бишәргә дә өйләнәләр… Андыйларны элек партия гына тотып торган булып чыга бит инде… Хәзер дини кешеләр булып кыланалар ич.

– Тап өстенә бастың, Габделбәр абзый, «кыланалар»:

– Әйе, – дип Фарук Йосыфовичның сүзен куәтләп куйды Садрый мулла, – Елына бер чиркәүгә кереп чукынып чыгу – ул әле дини булу, дин кануннарына тугрылык саклау түгел.

– Ә сезнең мәр мәчеткә кергәне бармы соң, хәзрәт?

– Гапсатаровмыни? Бар. Өстәгеләрнең әлеге модасына иярепме Ураза, Корбан гаетләрендә килеп бит сыпырып китә. Хәер, чиркәүгә барып чукынып та китә, диләр. Аның килүеннән ни файда. Мәчетебез һаман манарасыз утыра бит. Манарасыз мәчет… манаМәчетебез һаман манарасыз утыра бит. Манарасыз мәчет – ул таҗсыз хан кебек була ич. Азанны бинаның чоррасыз мәчет – ул таҗсыз хан кебек була ич. Азанны бинаның чор-

масына урнаштырылган динамиктан яңгыратабыз. Манара төзетергә акча сорап кергән идем: «Бюджетта андый акча каралмаган. Әнә мәхәлләгез мөселманнарыннан җыегыз», – дип, куып чыгаргандай чыгарды. Җыелган бераз акча бар да ул, җитенкерамый, – дип көрсенде имам.

– Күпме җитми,– дип сорыйсы итте Фарук Йосыфович.

– Биш йөз мең чамасы тапсак, эшне башларга да мөмкин булыр иде.

Габделбәр картның күзләре маңгай чамасына күтәрелде.

– «Тапсаң»? Ул хәтле акча җирдә аунап ятамыни? Аны ничек табасың?

– Бирдәш «олигархы» игәнә турында ни уйлый? – Фарук Йосыфович

Габделбәр картка күз кыскандай итте.

– Әлим баймыни? – Садрый мулла мыскыллы елмайды. – Урыс баеса, чиркәү сала, татар баеса, хатын ала, дип әйткәннәр бит. Ул да, чыгарса да, кысып кына чыгара шул, туганнар. Илле мең бирде. Шул да булдымы игәнә!..

– Ярар, – диде, – Фарук Йосыфович, – бу теманы калдырып торыйк әле, хәзрәт. Аллаһы боерса, теләгегез кабул булыр.

– Иншалла, иншалла, туган. Аллаһыбызга көн-төн дигәндәй ялбарабыз инде. Ул – миһырбанлы, Гапсаттаров та, Әлим бай да түгел ...

– Халык мәчеткә йөриме соң?

–Азрак шул, кызганычка каршы, азрак... Менә бит, хәтта Габделбәр кордаш та килгәндә килә, килмәгәндә юк.

Габделбәр оялчан елмайды.

– Алласыз заманыбызны онытып бетәлмибез шул, Садретдин. Юк, менә көзгә керәбез, мин өйләнәм, йомга намазларына әби белән икәүләп йөри башлыйбыз, Аллаһы боерса...

– Өйләнәсең?

– Әйе, Садретдин, никахны синнән укытам. Теләкбирде дустан укытмыйм, ул һаман да хәмер чөмерә. Аны мәҗлескә кияү егете генә итеп чакырам.

– Йәрхәмикалла, Габделбәр кордаш. Ә Теләкбирденең тотып арт сабагын укытырмын әле. Мин бит аның нәчалнигe, ягъни дә Бидрәш шәһәре, районы имам-мөхтәсибе. Безгә әле яшьрәк чакта чөмергән гөнаһларыбыз өчен дә күпме догалар кыласыбыз бар.

– Ничек киргеген бирәсең хәзрәт? Бюро җыепмы?



– Картларны җыеп, Фарук энем. Бар эргәмдә абруйлы картларым.

Ә мәчеткә кереп хәер-садака бирүчеләргә килсәк, якшәмбе көн күп була андыйлар. Базар зур бит безнең, тирә-як авыллардан гына түгел, хәтта, ерак шәһәрләрдән дә килә сәүдәгәрләр. Безнең татар, башкорт мәчеткә бик ылыгып бармаса да, казаклар, үзбәкләр, таҗиклар, тау халыклары мәчет тупсасын атлап керүне фарыз күрәләр.

– Ярар, Хәзрәт, – дип әңгәмәгә нокта куярга уйлады Фарук Йосыфович. – Дөньялар үзгәрә, без дә үзгәрәбез. Ул үзгәрүләребез яхшы якка гына булса икән... Хушлашып, дога кылсак та буладыр.

– Бәй, Фарук энем, күргәндәй дә булмадым бит әле. Үзең турында берни дә сөйләмәдең...

– Минем турыда нәрсәсен сөйлисең инде аның, Садретдин абзый. Мин дә пенсиядәмен, исламыбыз турында байтак мәгълүматлымын. Гарәпчә дә бераз сукалыйм, тик, кызганыч, һаман да намазлыкка басгаранчы юк әле. Без бит нидер көтәбез. Иң азаккы көнемме?.. күп еллар канымы юк әле. Без бит нидер көтәбез... Аннары, үземдән соң кайтуым – яшьлегемне сагыну, дип әйтимме... Аннары, үземкүрә эшем дә бар әле – халыкның тел-авыз иҗатын өйрәнү.

Садрый мулла белән Габделбәр карт бер-берсенә караштылар.

– Шуннан, Фарук Йосыфович бездә өйрәндеңме соң инде?

– Күпләр тыңлый, азлар ишетә. Күпләр күзәтә, азлар күрә, диләр бит, хәзрәт. Мактанып әйтмим, мин шул «ишетүчеләр», «күрүчеләр» токымыннан. Байтак тормыш тәҗрибәсе туплаганмын. Менә шунда Габделбәр абзыйны өйләндерешергә кайтачакмын. Менә шунда иркенләп сөйләшербез әле...

## Кичен

*Акчалы бәхетсезлектән, акчасыз бәхет яхшырак*

***Б. Е. Крутиер***

– Йә, безнең Садретдин хәзрәт ничек? – дип елмайды Габделбәр карт, кичке чәйне эчәргә утырып алдыннан.

Фарук Йосыфовичның кәефе яхшы иде. Мәчет ул дингә ышанганнарның да, әлегә намазлыкка басмаган мөселманнарның да җанына тынычлык өсти торган урын. Әле Кояш кичкелеккә авышкан, урамда да, өй эчендә дә әзелек бераз кими төшкән. Аның кәефен хәтта җабызылган, тавышы киметеп куелган телевизордагы «Сихәттә керсни!» кебегрәк галәмәтләр дә төшерә алмый. Мәчеттән кайткач,

Фəридəсенə шалтыратып алган иде. Сагынып та өлгергəн. «Кайчан кайтасың? – дип тенкəсенə тигəн булды. – Теге вакыт сине еллар буе күрəлми идем. Отставкага чыккач, гел бергə генə булырбыз, – дип шатланган идем. Киттен дə югалдың, әтиə буе син юк. Кара аны, Бидрəшендə яшьлек мəхəббəтлəренң белəн очрашып йөрмə..., – дип шаярткан була. «Дүшəмье кайтып җитəрмен, энием», – дип тынычландырды хатынны ире.

– Юлда сөйлəгəн мəзəклəреңнəн, муллагызны килделе-киттелерəк адəм, дип күз алдына китергəн идем, Габделбəр абзый, төпле кеше икəн.

– И Фарук улым, Фарук улым. Мəзəклəре аның кызык өчен бит. Болай начар кеше түгел. Элек тə начар булмады.

– Шулай булгач, ярдəм итəргə кирəк аңа. Үзенə дə... ничек дип әйтим икəн мəчет активистыбулып алырга, юньлерəк картларны да, хəер картларны гына түгел инде, яшьлəрне дə үзен артыннан ияртергə... Син бит тегендə, Тоцкида да, монда, Тавештə дə, заман аахырының ниндирəк икəнен үз күзлəрең белəн күргəн кеше...

Габделбəр карт уйланып утыргандай булды.

– Үзем дə шулайрак исəплим инде, Фарук улым...

Ул арада ак тастымал белəн капланган, суынып өлгермəгəн табасын күтəреп өлгер Хөршидə дə кереп житте.

– Габделбəр бабай, Фарук абзый, тиз генə чəй... коймагым суынмас борын. – Үзе шунда ук кайнап чыккан самоварны өстəлгə утыртты, савыт-сабаны барлап, чəй урыны әзерлəде.

– Коймагың бигрəк тəмле булган инде, Хөршидə, – дип мактап алды унган хатынны кунак ир, өстəлдəге сыйны тəмлəп карагач.

Йорт хуҗасы бу бəһага анлыклык кертүне фарыз санады.

– Ничек тəмле булмасын, заманында өч ел пешекчегə укыды бит ул, гомер буе ашханəдə эшлəде.

Мактаудан хатынның түгəрəк йөзе алсуланып китте.

– Әле дə эшлим, Әлим байның «Бистро» атлы кафесендə. Саран! Эш хакын бер дə юньлəп түлəми. «Сезнен тамагыгыз болай да тук», – дип көлə малгунь.

Тегендə «Версаль», монда «Бистро». Фарук Йосыфовичка кызык булып китте. Европаны үзебезгə күчереп маташабыз түгелме?!.

– Ярар, – дип сүзен дəвам итте әрсез хатын,чəй урынын җыештыргач. – Синнəн ярдəм сорап кердем әле, Фарук абый. Юк, юк, матди ярдəм дип ялгыш уйлый күрмə. Өлфəтемне өйлəндерергə иде бит. Йөргəн кызы да бар.



– Соң?

– Син белəсең аны, укытучы Зөбəйдə кызы Сəрия. Чибəр, уңган! Габделбəр бабайны котларга балалар алып килгəн иде бит.

– Белəм. Бик яхшы кызга охшаган. Йөргəч, өйлəнсеннəр соң! Нəрсə, мине кияү егете итəргə әйтəсеңме? Габделбəр абзыйга – кияү егете, Өлфəткə – кияү егете...

Кызык булып китте. Өчəүлəп көлеп җибəрделəр.

– Юк, – диде Хөршидə, көлешеп туктагач. – Кияү егете итеп түгел, димче дип әйтимме инде...

– Хрен редьки не слаще, – дип көлде кунак тагы да.

– Кыскасы, кыз ялындырып маташа. Бер – син дə мин, бер – кирегə беткəн. Син – полицейский, гади полиция гына да түгел ГИБДДшник, дип әйтə икəн. Ә юлда торганнар алар барысы да – ришвəтче. Халык сезне яратмый, сездəн көлеп күпме мəзəклəр чыгарганнар, дип әйтə, ди. Озакламый китə бит инде ул аннан, уголовный розыскка куча. Өстəге түрəлəреннəн боерык килергə тиеш. Син бит Зөбəйдə апаның классташы, сөйлəшеп кара әле.

– Ярар, икесенең дə колакларын тарткалап карармын, Хөршидə. Тик син дə бик хафаланма. Кавышырлар, кызлар шулай бераз ялындырып маташырга тиеш инде.

Хатынның борчулы йөзе тагын ачылды.

Габделбəр карт күршесенең аркасыннан сөеп алды.

– Өлфəт – күз алдында үскəн егет, милиция мəктəбен тəмамлап эшлəп йөри. Кайсы берүлəр кебек сөмсез түгел. Хəер, Хөршидə үзе дə бит..., милициядəн батырлыгы өчен зур бүлəк алган бичə. Анысын син белмисең әле, Фарук энем.

Күрше хатынның йөзе тагы алсуланды.

– Һи, зур бүлəк дип инде, исемем язылган сəгать... Самохвалов үзе тапшырды.

– Нинди батырлык кылдың соң, Хөршидə?

– Фарук улыма батырлыгыңны үзең сөйлəп күрсəт инде, күрше.

– И, оялам бит әле.

– Сөйлə, сөйлə, оялма...

– Ярар, сөйлəсəм сөйлим инде. Габделбəр бабай белə, мəрхүм Әсламем торганы бер алкаш иде бит. Эчмəгəн көне булмады дияр-лек. Теге хəерсез төндə кайтмый да кайтмый. Тагы күбенгəнче чөмереп кайтыр инде, бирəн, дип каргана-каргана ятып торгач, йокыга талганмын.

Өй эчендә ниндидер кыштырдауга уянып китеп, алгы бүлмәгә чыксам, ярым караңгылыкта ни күрәм! Ир дигәнем бер кулы белән телевизорны кочаклаган, икенче култыгына келәмне урап кыстырган, чыгу ягына китеп бара. «Ах кабахәт! Бар зарплатаңны эчеп бетереп торуың гына җитмәгән, йорт җиһазын сатып эчә башладыңмыни?!, – дип, кулга эләккән саплы таба белән тегенең түбәсенә җан ачуым белән берне кундырган идем, гөрселдәп идәнгә ауды. Ярый әле телевизорым ватылмады. Утны кабызып җибәрдем. Ул арада күрше бүлмәдән, күзләрен тырный-тырный, Әсләмем килеп чыкты. «Нишлисең ул?» – ди. «Күрмисеңмени, сине дөмектердем бит», – дим. Алкашым бер үзенә, бер идәндә яткан мәеткә карый. «Мин дөмеккәч, нишләп синең янда басып торам?» – ди. «Чынлап та, – дим, – Бу әтрәк-әләм син түгел икән дә... Әстәгафирулла! Фатир басучы бур бит! Кая, тере микән, үле микән?» Аңгы-миңге Әсләмем калтырана. Мин тегене капшап карыйм. Бәхеткә, тере булып чыкты. Ярый әле түбәсенә табаның кыры белән түгел, асты белән сукканмын. Югыйсә котылыр иде сотрясение мозга белән генә. Булмаган мие ничек селкенсен инде, шунысы да кызык бит!

Шуннан инде милициягә шалтыраттым. Килеп, алып киттеләр. Ул милиция күптән эзләгән, «Шанхай» атлы тотылмас бур булып чыкты.

Мине чакырдылар, барлык милиционерлар алдына бастырдылар. Тагы котым очты, җир ярылып идән астына төшеп киткәндәй булдым. Самохваловның урынбасары приказ укыды. Милиция хуҗасы үзе кулыма сәгать тоттырды. Алтын түгел, түгеллеккә, шулай да ярый инде.

«За проявленное мужество в поимке опасного рецидивиста» дип язганнар.

«Батырлык» та, «батырлык»... Нинди батырлык булсын ди инде. Әгәр ул кабахәтнең Әсләмем түгел «опасный рецидивист» икәнен белсәм, үземнең йөрәгем ярылыр иде әле, билләһи! Менә шул гына...

Габделбәр карт бу хикәятне, бәлки, йөзенче тапкырдыр, Фарук Йосыфович беренче тапкыр, йә куркыныч хәлне күз алларына китереп кашларын җыерып, йә хатынның соңгы сүзләреннән елмаеп тыңладылар. Хикәят тәмам булгач, Фарук Йосыфович хатынның кулын кысты.

– Молодец, Хәршидә Хөрмәтовна! Шул бандитны милициягә тотып биреп, бәлки, син әллә ни чаклы кешенең гомерләрен саклап алып калгансыңдыр әле. Сиңа сәгать кенә түгел, «Батырлык өчен» медале бирәселәре булган.



– Шулай укмыни, Фарук абзый? – Хатынның мөләем йөзендә тәвәккәллек чалымнары хасил булды. – Башка килеп кенә карасыннар андый хәшәрәтләр. Әлеге табамны мин яныма алып ятам!

Ятар алдыннан Габделбәр карт Фарук Йосыфовичның исенә иртәгә эшләнәчәк эшләрне төшерде. Бердән, базарга чыгалар, андагы хәлләр белән танышалар. Икенчедән, андаТеләкбирде дусты белән күрешәләр, ул сатарга ике сарык түшкәсе алып килә. Өченчедән, үзе белән картның кәләше Фаягөлне дә алып килә. Анысы, имеш, яңа бәйләгән дебет шәлен сатарга килә, ди

– Габделбәр абзый, – дип елмайды Фарук Йосыфович, – Бер сәбәптән ике сәбәп, ул бит кияү егетенең дөнясын күреп кайтырга да килә булыр.

– Үзем дә аңлыйм инде, Фарук улым. Без бит, әбәзтелне, аларны өемә алып кайтачакбыз. Дөньям болай тәртиптә дә ул. Мунчамның кыйшайган морҗасын турайттым, күтәрмәсен яңарттым... Казларым исән-сау. Бер генә нәрсә эчемне пошыра: «Запараем» искереп бара. Көзен кәләшне шул машинам белән төшерерменмикән ни?

– Искереп барса да машина бит әле ул, Габделбәр абзый...

– Машиналыкка машина инде, миңа кырык ел хезмәт иткән машина. Тик яңартасы килгән иде бит әле. Хәзер андыйны чыгармыйлар инде, «Ока» алып мәсхәрәгә каласым килми. Хәршидәнең Әлфәте бер «Жигули» белешкән дә ул... Тугызлы «Жигу-ли», ди. Бер генә кулда булган, ди. Бик таушалмаган, ди. Сиксән мең генә сорый, ди. Эбиркнишкәмдә, Аллага шөкер, маям бар. Алам мин аны. Ә «Запараемны»... Юк-юк, металломга тапшырмыйм, һәйкәл итеп йортымның әнә теге почмагына утыртып куям.

– Һай, Габделбәр абзый, дәртлесең дә инде. Сиксәнне үтеп барганда кем машинада йөри дә, кем машина яңарта!

– Иртән базарга киткәндә, Хәршидә күршегә әйтеп китәрбез, без кайтканчы, дөньяны җыештырып, аш салып, эчәсен-төчәсен караштырып куйсын.

Карт, казларын ашатып, кунар урыннарына аткарып йөргән арада, Фарук Йосыфович, иртәгә көннең ыгы-зыгылы буласын чамалап, кием салымын караштырып, кирәк-яракларын барлап алырга булды. Кейсыннан яңа футболкасын чыгарып, карая биргәнен анда тыкты. Шул чак аның кулы кейс кесәсендәге ниндидер каты тәргәккә төртелде. Анда блокнот белән ручкадан башка нәрсә булырга тиеш түгел иде ич?

Ул аптырап теге төргәкне тартып чыгарды. Акча! Полиэтилен токчайга төрелгән ике кап акча! Бишәр меңлекләр, банк капларында. Тоташ бер миллион. Бу нәрсә? Әллә Бидрәш могҗизаларының чираттагысымы? Вакыт атлы патша сикереш ясап барлык бидрәшлеләрне бер тетрәтеп ала да, Бидрәш кунагы полковник Әюповның кейсына бер миллион акча тыгып куя. Галәмәт! Алай уйласаң, мондагы мажаралар үтте бит инде. Барсы да урынына кайтты.

Фарук Йосыфович алай ук бер катлы кеше түгел. Бу акчаларны токчаена кайчан кем тыкканын шунда ук аңлап алды. Вакытның кысылышы юк монда. Мәңгелекнең кысылышы юк! Бидрәш түрәләренең гап-гади ришвәте. Янәсе, урыннарында арытабан да утырсыннар, аларга тимәсеннәр, аларны кузгалтмасыннар. Хәзер бит инде ришвәтне алай итеп акчалата тапшыру да юк. Кайдадыр ниндидер банкта кем исеменәдер исәп ачыла да, виртуаль миллионнар шунда хасил була. Ә монда – урысча әйтсәң, примитив. Хәзер Фарук Йосыфович нишләргә тиеш була? Гапсатаров кабинетына кызып барып керергә дә, ришвәтне ярсып, аның битенә ыргытыргамы? Әллә, мыскыллы елмаеп, Хрипунова ханымның кулына тоттырыргамы? Алары ни диярләр? Без берни дә күрмәдек, берни дә белмибез диярләрме? Ул дөнья күрмәгән бер катлы малай түгел ич. Тәҗрибәле дипломат. Разведчик!..

«Ярар, кичтән иртә хәерлерәк», – дигән карарга килде Фарук Йосыфович, йоклап китәр алдыннан.

## БАЗАРДА

*Өмет – ул йомырка, берәү аның сарысына ирешә,*
*икенчесе – агына, өченчесе – кабыгына.*

***Дания мәкале***

Шаулый базар, гөрли базар! Халыкның нинди тормышта яшәвен беләсең килсә, базарга бар, диләр бит. Базарда берәү алдый, берәү алданганын да инкяр итеп торасы юк. Шунысы гаҗәп: алдаганы да шат, алданганы да шат. Берсе уйлый, мин оттым дип, икенчесе дә, тегене төп башына утырттым дип, ләззәт хисе кичерә. Габделбәр карт белән Фарук Йосыфовичны әле базар мәйданына кергәнче үк алдадылар. Күз күреме хәтле мәйдан вулкан кратерында кайнаган лавадай базар үзе булса, аның тирәсендә күз күреме хәтлек ялан машиналар белән тулы иде. Ниндие генә юк аларның: «Фольксваген» белән «Форды» да, «Тойота» белән «Мицубиси»е дә... Менә сиңа мескен шәһәрнең ярлы яшәгән халкы! Үзебезнең «Лада»лар да байтак... Чабыш атлары янына китереп куелган ишәкләр кебек, араларында «Москвич» белән «Запорожец»лар да тәсмерләнә. Фарук Йосыфович үзенең экзотик «Жигули»ен шундыйларының берсе янынарак кысылдырып маташа иде. Алар эргәсенә шунда ук чәчен «ирокез» итеп алдырган, кара күзлек кигән, биленә заман токчаен таккан утыз яшьләрендәге бер ир килеп җитте.

– Вы что без моего разрешения тут паркуетесь? – дип янаган тонда дәште ул Фарук Йосыфовичка.

Габделбәр карт тегенә усал итеп карады.

–Нәрсә, сатып алган җирең бармы әллә?

– С тобой не разговаривают, старик. Я обращаюсь к хозяину этой колымаги.

Фарук Йосыфович әлеге «Копейка»сын мыскыл итүләренә күнегеп беткән иде инде.

– Машинаны базар стоянкасына куярга да рөхсәт кирәкмени? – диде ул, бу әтрәк-әләм белән бәхәскә кермәскә тырышып.

«Әтрәк-әләм» арык түшен киерә бирде, озын кулларын биленә таянды.

– А как же! Час стоянки двести рублей.

«Кайда бу җирне арендага алуың турында килешүең, кайда лицензияң?» – дип сорарга кирәк иде дә, Фарук Йосыфовичның күзе читтәрәк сугышчан кыяфәт алган ике әзмәвергә төште. Хәзер, шушында шәһәр бандитлары белән сугышып китәсе генә калган иде! Ул әлеге сөмсезнең учына биш йөзлек кәгазь төртте дә, Габделбәр картның җиңеннән тотып капкага табан юнәлде. Базар мәйданына кергәч тә, аның «барахолка» атлы өлеше башлана. Ни генә чыгармаган Бидрәш сәүдәгәрләре сатарга. Тутыгын тазартып, әлиф сөрткән эш кораллары дисеңме, әллә кайчаннардан әллә нинди техникадан калган запас частьләр дисеңме, кайчандыр кемнәргәдер спецовка итеп бирелгән бишмәтләр, кирза итекләр дисеңме, тәгәрмәчләре 8 саны рәвешенә кергән иске велосипед дисеңме, күреге йомшаган гармун белән кылларыннан язган гитара дисеңме – барысы да бар. Һәм гаҗәп, барысына да ниндидер сатып алучы табыла. Кайчандыр гөрләп эшләгән предприятиеләрдән урлап чыгарылган тимер-томыр, төрле җиһазлар да җитәрлек. Андыйлары хәтта өр-яңа килеш тә сакланган. Фарук Йосыфовичның күңеленә хәтта кызык кына уй да

килеп куйды. СССР шул чаклы куәтле ил булган икән дә: өстөгеләре таркаталар-таркаталар, һаман таркатып бетерә алмый, мондагылары урлаган-урлаган, урлаганын һаман аткарып бетерә алмый.

«Барахолка» да,бәлки, озакка тукталып та тормаслар иде, Габделбәр картның «Запараена» бер тимер кисәге кирәк булып чыкты. Эзли торгач, ул аныйсын да тапты. Кесәсеннән акчасын чыгарып кына да бирә алыр иде, базарда сатулашмыйча булмый шул.

– Биш йөз, – диде авызына чәйнәлеп беткән тәмәке капкан сакалы-мыегы җиткән тимер хуҗасы

– Син нәрсә, акылыңнан язлыңмы әллә? Шушы тутык тимергә биш йөз!.. Фарук Йосыфовичның кесәсеннән чыгара башлаган акчасын кире тыктырып куйды.

– Нинди тутык тимер булсын ул. Яңа заводтан чыккан! Ярый, алай булса, дүрткә бирәм инде.

– Юк! – диде карт кырт кисеп.

– Ә ничәгә аласың соң? – диде сәүдәгәр мескенләнә төшеп.

– Иллегә алам. Иту сиңа яхшылык йөзеннән генә. Күреп торам бит, махмурдан интегәсең.Бер шешә сыралык…

Сәүдәгәр ялынуга ук күчте.

– Илле шешәгә җитми. Хет бер җитмешне бир инде.

– Ярар, җитмеш икән, җитмеш…

«Тутык тимер» Габделбәр картның токчаена төшеп ятты. Ары киттеләр.

– Биш йөз, имеш, тотмыйрак торсын… – дип сөйләнеп алды карт. Аның йөзенә хәтта үз-үзеннән канәгатьлек хисе дә чыга башлаган иде. Бу юлы бит теге әтрәк-әләм отылды, Габделбәр отты.

Ә базар кыза, базар гөрли! Яшелчә, җиләк-җимеш рәтләре дә халык белән тулып өлгергән. Бидрәштә, аның тирә-ягында өлгергән карлыгандыр, чиядер, кура җиләгедер, үзбәкләр китергән өрегечикләвегедер, Әстерхан якларында үскән кавыны-карбызыдыр, Төркия тарафларында пешкән лимоны-әфлисүнедер – нинди генә азык юк монда! Фарук Йосыпфович сатулашмый-нитми генә тегесен монысын алды. Габделбәр карт сатулашырга әйткән иде дә, кунагының беркатлылыгына эче пошып кул гына селтәде. Иң кызыгы: базарда халык ни кадәрле генә күп булмасын, җиләк-җимеш җитәрлек, ана чират юк дип әйтерлек. Бәрәңгегә чират дисәң дә чират! Хәер, иртә өлгергән бәрәңгене базарга чыгаручы да бер генә карт иде шул. Габделбәрнең күптәнге танышы, заманында имәндәй нык башкорт егете була торган иде. Әле дә бик бирешеп бармый.



– Картошка! Молодая картошечка! С зеленым луком, укропом – объеденье! Ярмаланып-ярмаланып кына бешер йәш картуф, агайэне! Каймакһыз-майһыз за ауызза эреп тора! Алығыз! Тәлегезне йотып ебәрһегез зә үкенмәҫһегез! Килограммымы? Бушҡа, илле генә тәңкә!

– Әссәламмәгаләйкем, Тимергали кордаш! – дип сәлам бирде Габделбәр карт аңа, чират төркемен ерып үтеп.

– Вәгаләйкемәссәләм, Габделбәр дус! – дип перчаткаларын салып кул бирде аңа сатучы. Үзе сатып алучыларына өндәште, – Гафу итегез, агай-эне, күрәсез, бәрәңгем бетеп бара, сәүдәмне туктатып торам. Таралышсагыз да була.

Ризасыз тавышлар яңгырады. Тик нишләсен сатып алучылар? Базар сәүдәсе – кибет сәүдәсе түгел. Сатучы кайчан сатарга, сәүдәсен кайчан ябарга икәнен үзе белә.

– Менә минем кунагым Фарук атлы егет, таныш бул.

– Син дә инде, Габделбәр кордаш. Әтисе Йосыф мәрхүм белән заманында бергә эшләдек ич, – Тимергали карт кунакка көрәктәй уң кулын сузды, сулы белән Фарук Йосыфовичның аркасыннан сыйпады.

Шартына китереп дога кылдылар. – Бик зур кеше булып киткәнсең икән, дип сөйләгәннәр иде. Кайтып, безнең хәлләрне белергә форсат тапкансың икән, молодец!

Фарук Йосыфович оялчан елмайган булды.

– Әллә ни зур түгел дә ул, Тимергали абзый. Менә, акиттер, табышмактыр мәзәктер, башка чурт-чурамандыр җыеп йөргән булам әле.

Тимергали аптырабрак Габделбәргә карады. Аның дустына күз кысты. Мәгънәсе болайрак иде. Янәсе, дөньяда кайсы шпион үзенең шпион икәнлеген кычкырып йөри.

– Шурик кебекмени?

– Шулайрак була шул, Тимергали абзый.

– Алай булгач, менә мин сиңа бер мәзәк сөйлим. Габделбәр кордаш, син инде аны беләсең.

– Ә-ә-ә, тегенемени?

– Әйе. Әйдә, базар шаулый торсын, беркая да качмас… Карчыгым дөнья куйгач, шәһәр артындагы бакчамны ташлаган идем. Хәзер күпләр ташлап бетеп бара бит. Былтыр яз дәртләнеп киттем дә, башкасы үсмәсә, хет бәрәңгесе генә булса да үссен дип, утыртып ташладым. Юанырга эшем булды. Утадым, күмдем, кор-

тын чүпләдем, көннәр корыга тарткач, хәттә суын да сиптем. Иртә утырткач, иртә өлгерде. Бер көнне, казырлык булды микән дип карарга бакчама киттем. Якынлашсам, ни күрәм! Эскерт хәтле кара джип, амбар капкасы чаклы арткы ишеге ачык. Әзмәвердәй ир тал чыбыгыдай ханым белән, көченә-көчәнә, машиналарына капчык салып маташалар. Бәрәңге! Минем бәрәңгене төйиләр! Җан ачуым белән кычкырып җибәргәнемне сизми дә калдым.

– Һай! Нишлисез, сволочьлар! Минем бәрәңге бит ул!

Карак куркак була. Югыйсә, әзмәверс мине борып кына тыгып куяр иде. Болар, машиналарының ишеген дә ябып тормый, утырдылар да сыпырттылар. Артларыннан тузан гына борхып калды. Ажгырып торган айгырдай джип алырга акчалары бар, бәрәңгегә – юк. Сөмсезләр! Безнең урыс илендә генә шулай булырга мөмкиндер. Бакчама керсәм – хет утырып ела, яртысын казыганнар!..

Алачыгыма терәтеп эшләнгән эскәмия янына килдем. Хәзер инде еласаң ела, көлсәң көл. Заман бурлары бәрәңгемне казып төягәндә шул эскәмиягә, пычранмасыннар дипме, әллә башка берәр сәбәп беләнме, зиннәтләрен салып торганнар. Ире – эт бәедәй алтын чылбыр, «печатка» атлы авыр балдак, бичәсе – асылташлы өч йөзек, алтын кулон калдырып качканнар. Игелеклеләр дисәм инде...

Бу хикәятне ничәдер мәртәбә ишетсә дә, Габделбәр карт хихылдап көлеп куйды.

– Нишләп тагып фарсит итеп йөрмисең соң аларны, кордаш?

– Хәзер! Гомерем буе заводта тимер-томыр белән эшләп катып беткән бармакларыма алтын балдаклар гына кияссе калган. Синең белән бит без аның алтынын түгел, бакырын да күрмәдек. Тегеләр килерләр, таптырырлар дип уйлаган идем. Ярты ел көттем, килмәделәр. Кызым белән кияvем фатирларына ипотека түли алмый изаланалар. Шуларны сатып түләгез дип, ахыры да балаларга бирдем. – Карт Фарук Йосыфовичка карады, – Әле торасыңдыр бит але, Фарук улым?

– Юк инде, Тимергали абзый. Кунакның беренче көне – алтын, икенче көне – көмеш, өченче көне – бакыр, дүртенче көне – юлы такыр, диләрме але. Ә мин алты көн торып ташладым. Иртәгә таң белән кузгалырга иде.

– Һи-и, күрмәгән дә кебек торып калабыз ич!

Габделбәр карт җанланып китте.

– Беләсеңме, кордаш, бәрәңгеңне сатып бет тә бергә кил.



– Сездә нишлибез?

– Кунакны озату кичәсе дә була, мина калаш әйттерү дә...– Калаш?.. Ничек калаш?.. Ни чыкса, синнән чыгар инде, Габделбәр. Алай булгач, токчаеңа бәрәңге тутырып ал але. Синеке өлгереп җитмәгәндер.

Хатын-кыз кул эшләре саткан җирдә халык әрәк иде. Җәй челләсендә кем инде дебет шәл, дебет бияләйләр турында кайгыртсын. Фаягөл аларны әллә кайдан ук күреп калды. Йөзе балкып китте, кулын болгады.

– Исәнме, Фаягөл!

– Исәнмесез, абыйлар!

– Сине дә күрер көнебез бар икән...

– Мин дә сезне күрүемә бик шатмын.

– Сәүдәң ничек бара?

– Аллага шөкер, шәлемә хуҗа табылды инде. Акчасы җитенкырамады, өенә кайтып китте.

– Теләкбирде кайда?

– Кайда булсын, ит рәтендә инде...

– Алай булгач, без аны барып табыйк та, сарыклары сатылып бетсә, сине килеп алырбыз да...

– Шәлемне биреп җибәрсәм, үзем дә Теләкбирде абзый янына барып җитәрмен.

Ул арада ирләрнең игътибарын бер як читтәрәк тавык йомыркасы сатып торган кортка җәлеп итте.

– Халал күкәй сатам, халал күкәй! Яйтса мусульманские, пакупайте!

Халалные яйтса, арзан бирәм, алыгыз!

– Нихәл, Зәмзәмбикә, – диде Габделбәр карт, аның эргәсенә якынрак килеп, – Сәүдәң барамы?

– Саумы, Габделбәр, – дип җавап кайтарды кортка, – Этсәң бара, этмәсәң – юк. Үзе тагы да янәшәсенә туплана башлаган ачыкавызларга хәбәр салды:

– Күкәй сатам, халал күкәй сатам!..

Габделбәр карт башындагы түбәтәен арткарак шылдырды, хәйләкәр елмаеп Фарук Йосыфовичка күз кысты.

– Йомыркасы, бәлки, халалдер дә аның, итәгең белән каплап куйган тартмадагы «тәнкә куганы» нинди була инде?

– Зәмзәмбикәнең әле генә елмайган йөзе ыржайды, ул нәфрәтле карашын картка юнәлтте.

– Чукынып торма монда, Габделбәр, сәүдәмне бозма, юлыңда бул! Минем итәк астында ни барын гына тикшерәсең калган иде…

Чәче кырып алынган башына түбәтәй эләктергән бер ир бу әңгәмәне өзде.

– Ничек инде синең күкәйләрең арзан, әби кеше, әнә павильон эчендә дистәсе җитмеш тәңкә, синеке – туксан. Шул арзан була димени?..

– Аларныкы бит простуй күкәй, хәерсез адәм. Минеке халялни! Эчемне пошырма. Алсаң – ал, алмасаң, шыл моннан!

Ул арада болар янына ачыкавызлар җыелып өлгерде.

– Соң, туктале, – дип ныкышты түбәтәйле. – Ул күкәйләреңне тавыкларың «Бисмиллаһ» әйтеп салганмыни?

– Кит дип әйттем бит инде мин сиңа, имансыз! Иманлы әдәмнәргә халәл ризык алырга мишәйт итәсең.

– Әйтсәң әйт тә, аннан китәм…

– Тавыклар әйтмәгән «Бисмилла»ны. Тавыкларны әтәч «Бисмиллаһ» әйтеп өшкергән.

–Ничек әйткән?

– «Кикррикку» дип әйткән, беләсең килсә, надан. Аның телендә шул дога була бит инде, мәгънәсез.

Җыелган халык арасыннан бу тартышуга тагы берәү кысылмый кала алмады.

– Әби, урысларның әтәчләре дә шул ук «дога»ны укый бит инде.

– Укый пычагым! – дип сүгенеп җибәрде ахыры да кортка, – Безнең әтәч «Кик-рик-кү-ү-ү-к!»ди, аннары «Кор-р!» дип тә өстәп тә куя әле. Урыс әтәче «Кукареку» гына ди. Аерма бармы наданнар?!.

Кемдер елмайды, кемдер тыйнак итеп көлде, кемнәрнеңдер бу мәзәктән сыннары катты. Ә кортка сәүдәсен дәвам итте.

Халал күкәйләр! Халялни яйтса! Бирите, ыхватайте! Канчаетса, пәслидний дисәтек…

– Йомыркасы аның конспирәтсия өчен генә, – дип көрсенде Габделбәр карт, читкәрәк киткәч, – Настоящий сәүдәсе бит аның – самогон. Эчкечеләрне аздырып, йортыннан да сата, менә шулай базарга да алып чыга. Кешедән дә оялмый, Алладан да курыкмый.

Базар шаулый базар герле. Ит рәте бигрәк тә нык шаулый иде. Бу күренешне бер читтәрәк Теләкбирде күзәтә. Күрешеләр, хал-әхвәл белешеләр.

– Нишләп читтә генә торасың, Теләкбирде абзый? Әллә итеңне сатып та беттеңме? – дип аның кулын кысты Фарук Йосыфович.



– Рәтнең урыннары сатып бетелгән шул. Фарук энем, капкорсак перекупщиклар безне анда якын да җибәрми. Бер танышым аша саттырам.. Ярты файдасы аңа кала инде… Нишлисең?… Ярар, минем иткә сорау зур, инде сатып бетеп тә килә.

– Сатып та бетерәбез, безгә дә китәбез, – диде Габделбәр карт.

– Менә бу токчайда табынга дигәне, Габделбәр дус. Һай! Фаягәл пешергән пылау!..

Ул арада базарчыларның игътибарын аргы рәттә купкан ыгы-зыгы җәлеп итте. Өчәүләп шунда барып кысылдылар.

Бәхәс аллә нәрсә тирәсендә түгел, үгез башы тирәсендә генә купкан булып чыкты. Чәйдә эленеп торган баш, чыннан да, матур иде. Хәзер кеше бит аны кадерләп өтеп тормый, туный да чыгара. Ә туналган башның ни тәме, ни яме! Ә бу баш өтелгән, балавыз төсенә кергәнче тазартылган, койка яраткан кешенең авыз суларын китерерлек!

– Күпмегә бирәсең? – дип сорады хуҗадан койка яратканнарның берсе, торышы белән зыялы ир.

– Хуҗа калын кашларын җыерды, күзлеклегә дошманына карагандай карады.

– Туләем мең тәңкә!..

Тегенең күзләре, күзлеге астыннан чыгып, маңгаена күтәрелде.

– Мең тәңкә?.. Бер башка мең тәңкә! Сез нәрсә… Гади башка… Төш бераз, бишйөзгә бир.

– Ты што, энем. Нишләп гади булсын ул? Әтисе – нәсел үгезе, әнисе – сөт бирү буенча рекордсменка. Бер тиенгә дә төшмим. Алсаң – ал, алмасаң шыл моннан!

Бу бәхәскә гомер буе ит белән эш иткән Теләкбирде кысылмый кала алмады.

– Дөрес, – диде ул әлеге сәүдәгәргә, – бер тиен дә төшмә, туган. – Бу бит баш кына түгел бөтен башларга бергесез баш. Телисеңме, – дип ярым пышылдады аның колагына, – Башыңны икс меңгә сатып бирәм.

Баш хуҗасының күзе акайды.

– Ничек?

– Шулай. Тик бер мең минем кесәгә…

Кулларын кулга чәбәктерде ике сәүдәгәр. Һаман ыргакта эленеп торган үгез башы аларга күз кысандай булды.

Теләкбирде карт эргәсендә пәйда булган таныш ит чабучысына өмер бирде. Яңасе теге төшен тегеләй, бу төшен болай чапсын. Менә

шулай баш өч өлешкә бүленде: мөгез ягы, төбе-тамыры белән кисеп алынган теле, аскы өлеше. Бу сәхифәгә җыелып китүче тәмлетамаклар шунда ук телгә ымсынды. Теләкбирдә карт реклама фәнен бик яхшы үзләштергән булып чыкты.

– Батчак сөзеп мыркылдаган дуңгыз теле түгел, агай-эне. Чәчкәле тугайда сусыл үлән көйшәгән яшь үгез теле! Һич тартынмый затлы ресторанга алып барып тапшырырлык. Хакы? Килограммы дүрт кенә йөз. Бер килограмм ит өч йөз илле чыгында, мин бу деликатесны бушка биреп утыра алмыйм бит инде, ханым. Тәк, ике килограмм ярым, төгәл мең сум. Синең чибәрлегең хакына гына, ханым. Миннән булсын яхшылык. Ярар, тәмләп ашагыз!

Габделбәр карт зәңгәр кәгазьне кесәсенә аткарды.

– Баш ите күпмедән, дядя?

– Менә бу аскы өлеше биш йөз.

– Килограммымыни?

– Юк, ышту син! Мине кем дип беләсең? Тоташлае белән биш йөз, үлчәп-нитеп тормый.

Какча урыс, откан кыяфәт белән, үгезнең как янак сөяген токчаена салды, Теләкбире карт кесәсенә хәзер алсу кәгазь кереп ятты. Ул ике дустына мәгънәле итеп күз кысты.

– Чәчкәле тугайда гына сусыл үлән уртлап симергән яшь үгез башы! Арзанга бирәм, алып калыгыз! Мие, колак ите, күз мае, аңкау кетерлеге – торганы деликатес! Хакы – бушлай дип әйтерлек. Башкалар сузылганчы, эләктереп калыгыз, мадам. Югыйсә, хуҗа хәзер табылыр. – Чынлап та, тирә якта «миңа» да «миңа» дигән тавышлар яңгырагандай булды.

Шулай итеп, үгез маңгае аны алырга да уйламаган, базарга дуңгыз башы алырга чыккан маржага эләкте. Аның биш йөзлеге тагы да Теләкбирде учына чумды.

Баш хуҗасы учына Теләкбирде суган меңлекне йомып, әле һаман баш сату күренешен күзәтеп торган күзлекле адәм аптырап торып калдылар.

-Ну үзең дә!.. – диде Фарук Йосыфович аптырау катыш соклануын ничек белдерергә белми.

– Анысын гына булдырабыз инде без аның, – дип өч бөртек сакалын сыйпап алды Габделбәрнең служагы. Горурлыгын йөзенә чыгармаска тырышты.

Ул арада Теләкбирденең ите дә сатылып беткән иде, Фаягөлнең шәле дә. Бергә җыелып беттеләр, Фарук Йосыфович машинасының



багажнигына кавын-карбыз салдылар, җиләк-җимеш тутырдылар, алдан – «копейка», аның артыннан Теләкбирденең «Москвич-412»се кайтырга кузгалдылар.

## ИЛЧЕНЕ ОЗАТУ КИЧӘСЕ

*Начар заманалар булмый, начар кешеләр генә була.*

***Р. Рәхман***

Илчеләр илчелек иткән илләреннән кайтып киткәндә, аларны ничек озаталардыр, белсә, аны Фарук Йосыфович үзе генә белә инде.

Йәкшәмбе көн төштән соң Габделбәр картның иркен йорты сабантуй мәйданын хәтерләтә бирде. Тәү хуҗа белән кунак, Теләкбирде өчәүләп сыйландылар. Хөршидә әзерләп куйган язык, Фаягөл белән икәүләп әзерләгән сый шәһәр башлыгы Гапсатаровның Фарук Йосыфович күзенә «төтен очыруыннан» калышса, шул күләме белән генә калышкандыр. Кешенең тамагы бит берәү генә, анда барысын да тыгып бетеп булмый. Иртән генә суелган сарык ите белән шулпасы да, каклаган каз ите дә, вакбәлеш белән өчпочмак та, ярмаланып пешкән, каймак белән тәмләтелгән яшь бәрәңге дә, помидоры-кыяры, суганы-укробы да... Өстәл артына утырып кына торалар иде Габделбәрнең яшьтәше Тимергали карт та килеп житте, болай да сыйлы өстәл өстендә аның куеныннан чыгарган шешә хасил булды.



– Зәмзәмбикәнең тавык тизәге кушып әчеткән кәмешкәсе түгел, агай-эне, – диде ул кунакларга күз йөгертеп чыгып, – Үземнең производство. Минем кырык ел буе спирт заводында эшләгәнне беләсез.

Табын шау-гөр килеп алды. Ә Хөршидә белән Фаягөл табынга әледән-әле яңа ризыклар китерә тордылар, кунакларны кыстый тордылар.

Кунаклары да аларның өстәлә торды шул. Фарук Йосыфовичның иртәгә кайтып китәсен кайдан белеп, кайдан ишетеп калганнардыр, хатыны Марияны ияртеп классташы Виталий Соломин да килеп житте. Зөбәйдә белән аның кызы Сәрия дә әллә кайсы арада Хөршидә белән Фаягөл эргәсендә урын алдылар. Халык күбәйгәч, хәтта өстәлләрне өйдән йортка чыгарырга туры килде.

Монысы бик вакытлы эшләнде. Чөнки, капканы кыюсыз гына ачып, күршеләре Бакый белән Сафура да кереп киләләр иде. Бакые айнык, сакал-мыегын кырган, таза киемнәрен кигән, Сафурасының да юанайганнан-юаная барган тәненә ярарлык кайсы бер күлмәкләре калган икән дә.

Габделбар карт горур, аның йорты аллә кайсы заманнарда улы Салимне өйләндергәннән бирле, бу хәтле кунакны күргәне юк иде әле.

Медаль тапшыру тантанасын исәпкә алмаганда. Анысы инде үзенә бер эш. Чын күңелдән эшләнгән нәрсә түгел. Монысы – үзенә...

– Әйдә, үтегез, туганнар, ишек алдында урын җитәрлек, дип каршы ала торды ул һәрберсен, – Сый да...

Иң кызыклысы шул булды. «Штрафной» дип Бакый күршесенә рюмка тутырып салып биргән иде, анысы хәмердән баш тартты. Алкаш Бакый, ни галәмәт, аракы эчмәде. Хәер, иң беренче булып, капкадан Садрый мулланың килеп керүен дә ул күрде шул.

Фарук Йосыфович урыныннан күтәрелде, хәзрәтне капка төбенә барып каршы алды.

– Хуш киләсез, хәзрәт!

– Әссаламмәгаләйкем, дин кардәшләр!

Ул арада дин әһеле янына йорт хуҗасы да килеп җитте.

– Өстәлгә «шайтан тәкерәге» куелуын гаепкә алма инде, Садрый кордаш. Монда үзебезнең урыс шәһәрдәшләр дә бар бит...

– Ярар, анысы һәр кемнең ирегендә, Габделбәр,– диде мулла тамагын кырып, – Берәүнең авызына да хәмерне шайтан көчләп коймый. Фарук туганның иртәгә китәсен ишеттем дә, килеп җиттем әле. Ярар, Фарук Йосыф улы, бу килүең хәерлегә булды дип уйлыйм. Моннан соң да туган шәһәреңә эзеңне суытмассың. Иппе кешенең туган ягына кайтуы – үзе бер бәйрәм бит ул. Бәйрәм генә түгел, фәһемле бер чара. Күрәсеңме, хәтта Бакый да бүген салмыйш түгел. Синең алда, менә мондагы шәһәрдәшләр алдында эчкече Бакый булып күренәсе килми икән, димәк, аңа кул селтәргә иртәрәк әле.

Мулланы каршылап кузгалган халык тагы өстәлләр янәшәсендә урын алды. Мулла хәмерле өстәл артында дога укырга кыймады. Хәер, ул арада төрле төстәге шешәләр дә каядыр китеп олаккан иделәр инде.

– Агай-эне, –дип башлады сүзен йорт хуҗасы. – Менә Фарук Йосыфович туганыбызга китәргә дә вакыт җитте. Иртәгә таң белән



юлга чыга. Озак еллардан соң аның кайтуы минем өчен зур бәйрәм булса, сез дә бу хәлгә битараф калмадыгыз. Яшерен-батырыны юк, без Бидрәшебездә сөрсеп ятабыз дип әйтимме. Теге төңлеге давыл безне бер тетрәтсә, Фарук Йосыфовичның кайтуы бер селкетте. Сез ничектер, әмма мин үзебезнең яшәү рәвешенә икенче күз белән карый башладым әле. Ничек дип әйтим икән: әкиятне әкият дип, чынбарлыкны чынбарлык дипме ? Бәлки, түрәләребез күңелендә дә ниндидер уйлар тугандыр... Фарук улым, менә шулай әкият, бәет, табышмаклар җыярга ешрак кайтып тор. Сүзенең бу төңгәлендә Габделбәр карт тагы хәйләкәр елмайды. Башкаларның да йөзләрендә елмаю пәйда булды.

Кунаклар таралыша башлагач, Фарук Йосыфович Садрый мулланы өй эченә чакырды.Ул кейсыннан әлеге ике капның берсен чыгарды.

– Хәзрәт, менә сезгә Бидрәш мәчете манарасын күтәрергә акча. Җитмәгән биш йөз меңе.

– Бәй, Фарук Йосыфович, күктән сораганны Ходай җирдә биреп куйды була, түгелме бу? Синең хәерең ме? Рәхмәт! Рәхмәт!..

– Юк, хәзрәт, үзең әйтмешли, Ходаныкы. Рәхмәтеңне аңа җиткер...

Киредән ишек алдына чыккач, аны сыйныфташлары Виталий белән Зөбәйдә култыклап алдылар. Сәрия дә эргәләрендә иде.

– Йә, Фарук, – диде Зөбәйдә моңсу елмаеп, – Синең янәдән шәһәребезгә кайтуыңны тагы кырык ел көтәргә туры килер микән?

Виталий белән Сәрия көлеп җибәрделәр.

– Ул чакта, Фарук абый, миңа алтмыш ике яшь була бит.

– А нам троим будет по девяносто семь лет, – дип өстәде Виталий.

– Юк, – диде Фарук Йосыфович, – иптәшләренең өчесен бергә кочып. – Көзен кайтам, Аллаһы боерса. Салим белән дә сөйләштек. Блюменталь дә килә.

– Анысы нинди Блюменталь тагын?

– Килгәч күрерсез. Безнең өчен Вакыт – ул усал бер патша. Аның өчен әллә инде дус, әллә сердәш. Күңелем йомшарып китте әле. Әллә сезгә бер шигыремне дә укып күрсәтимме?

– Укы, укы, Фарук абзый, – диде Сәрия түземсезләнеп.

– Тыңлагыз алайса. Тик мин шагыйрь түгел, әкият җыеп йөрүче генә.

*Вакыт – патша. Вакыт – усал патша!*
*Аямый ул безне – колларын.*
*Берәм-берәм тартып алып тора*
*Санап кына биргән елларын.*

*Бирәүгә дә артык гомер бирми,*
*Каруннарның ул бит каруны.*
*Табигатьнең шундый кануннары,*
*Яшәешнең шундый кануны.*

*Биргәненә риза яшәү кирәк,*
*Үткән еллар әйдә үтсен дип.*
*Сүтеп бетелмәгән йомгакларны*
*Соң килгәннәр бездән сүтсен дип.*

*Узган еллар барысы безнекеләр,*
*Хаталары безнең хаталар.*
*Хәтер сандыгының иң төбендә*
*Күңелләрне әйкәп яталар.*

*Казанышлары да юк түгелдер,*
*Күрсә, аны дуслар күрәләр.*
*Очрашулар килеп җитсә әгәр,*
*Үтереп тә мактый беләләр.*

*Ә без һаман Вакыт хаклыгында*
*Үзебечә сукмак ярабыз.*
*Тапканнарны әллә югалтабыз?*
*Югалтканны әллә табабыз?..*

Шигырь укылып беткәч, бераз уйчанланып тын тордылар.

– Әйе, – диде Зөбәйдә, уйчанлыгыннан арына биреп, – «тапканнарны әллә югалтабыз, югалтканны әллә табабыз?» Менә сиңа, Фарук, Бәшир Бадрошин мирасының кечкенә бер өлеше. Мин әйткән идем бит, шигърияттә матур гына сукалыйсың булса кирәк, үзеңне тәрҗемәдә дә сынап кара әле. – Ул сумкасыннан бер папка чыгарып сыйныфташына сузды. Күзен бергәләп карарбыз.

– Ярар. Хушлашыйк инде, дуслар. Ә сиңа, Сәрия, киңәш шул: Өлфәт яхшы егет күренә. Әнисе Хөршидә дә эшчән, әйбәт хатын. Чык шул егеткә кияүгә. Ялындырышып, тарткалашып йөрмәгез. Яшьлегегезнең кадерен белегез...

– Сәрия кызарып китте.



– Ялындырмыйм да инде, Фарук абый, икенче эшкә күч, дип кенә әйтәм.

– Күчәр, Аллаһы боерса, эшнең дә ниндиенә күчәр әле...

Зөбәйдә белән Сәрия кайтып киттеләр.

Алар күздән югалгач, Фарук Йосыфович, Виталий белән Марияны урам чатына чаклы озата китте. Дәшми – сөйләшми генә бардылар. Күңелләре бераз иләс-миләсрәк иде. Чатка җиткәч, кочаклаштылар.

Фарук Йосыфович, кесәсеннән теге капларның икенчесен чыгарды.

– Менә, Виталий, Маша, сезгә.

Әллә күпме гомер яшәп, әллекке редактор кулына бу хәтле акча тотып караганы юк иде әле.

– Бу – нәрсә, Фарук? Бу нинди могъҗиза?

– Сиңа китап чыгарырга акча. Шәһәребез турында китапны йомшак тышлык белән газет кәгазендә чыгарырга ярамый. Каты тышлык булсын, ялтыр кәгазь төсле сурәтләр. Тиражы зур булсын.

Виталийның ирексездән авызы ачылып киткән иде.

– Бу бит… бу бит…

– Әйе, барысына да җитә, Виталий дус. Эшлә генә.

– Димәк, китабымның спонсоры син буласың?

– Мин түгел.

– Ә кем?

– Мәчетебезнең имам-мөхтәсибе Садретдин хәзрәт бу очракта Аллага рәхмәтләрен җиткерә.

– Мин дә шулай итимме?

– Ит. Теләсәң, Всевышниеңа рәхмәт укы.

Фарук Йосыфович кайту ягына борылды. Башына кызык фикер килеп, капыл-гына кычкырып көлеп җибәрде. Садрый мулланың Тәңре дигәне бу очракта Бидрәш шәһәре мэры Гапсатаров булып чыкты түгелме? Ә Виталий Соломинның Всевышние... Хрипунова ханым булып чыга, ләбаса...

Бу төнне дә Фарук Йосыфович озак йоклый алмый ятты. Тәэссоратлары чагу, уйларының очы-кырые юк иде. Ахыры да баш очындагы гына лампасын яндырды да ноутбугын алып утырды.

*"Губернатору Кудеярской области*
*А. С. Буйновскому*

*Уважаемый Аристарх Федорович!*

– дип язып куйды да ул, уйга калды. Барлык тәэссоратларын тасвирласа, хат зурга китәчәк,ул күп сүзле булачак иде. Ә безнең халыкта: «Күп сүз – буш сүз», – дип юкка гына әйтмәгәннәр. Әйе, белешмә кыска гына булырга тиеш. Әгәр дә инде хат түрәне чынлап та кызыксындырса, Фарук Йосыфовичны чакыртып алып сөйләшсә, чыгарган нәтиҗәләрен җентекләрәк дәлилләргә мөмкин булачак.

*...Выполняя Вашу просьбу,* дип дәвам итте ул белешмәне, – *Я посетил город Бедряшево, прожил там шесть дней.*

*Странное поведение мэра Э. З. Гапсатарова и некоторые интересные явления в жизни города объясняются некоим природным явлением. Я пришел к этому выводу, посоветовавшись по телефону с выдающимся ученым-астрофизиком Ароном Ариевичем Блюменталем. К счастью странные явления без особых последствий исчезли из жизни города в течение трех дней. Однако, Блюменталь обещал приехать к нам осенью текущего года для более серьезного изучения вышестоящего природного явления.*

*Что касается, социально-экономического положения города, как я уже сказал по телефону, он мало чем отличается от сотни других малых и больших городов России. Для того, чтобы положение улучшилось, я считаю, необходимо заняться серьезным образом подбором, воспитанием и расстановкой руководящих кадров. Простые люди считают, заменив одних нечистоплотных другими, жаждущими богатства, положение не улучшить. А народу надо дать работу, восстановив разрушенные предприятия и построив новые.*

*С уважением Ф. Ю. Аюпов*".

## ХУШЛАШУ

*Туган илне итек табанына ябыштырып алып китеп булмый.*

***Ж. Дантон***

Таң атты. Кояш чыкты. Чыкты да үзенең бихисап нурлары белән бар галәмне барлап алды. Шул нурларның берсе, тәрәзә пәрдәсенең чак кына ябылмый калган бер чите аша үтеп кереп, Фарук Йосыфовичны уятты. Ул урыныннан торып тышка чыкты. Ишек алдында үз мәшәкатьләре белән булган Габделбәр картка сәлам бирде.

– Хәерле иртә, Габделбәр абзый.



– Хаерле иртә, Фарук улым. Тыныч кына йокладыңмы?

– Туган шәһәремдә, синең йортыңда ничек инде, йоклый алмый борсаланып ятыйм. Бик тә тыныч, тәмле итеп йокладым.

– Алай булса, бит-кулларыңны чайкат та, керик, иртәнге чәйне эчик…

– Аннары мин юлга чыгармын, Габделбәр абзый.

– Менә шуна күрә дә күңелем моңсурак шул, улым. Биллаһи, сине урысларың янына кайтарып җибәрми, үземдә генә тотар идем.

– Ә минем Фәридәмне кайда куяр идең?

– Һи, монда аңа да урын җитәр иде.

– Ярар, Габделбәр абзый, сөйләштек бит инде, көзен очрашабыз дип…

Менә шулай Җир кешеләре Фарук белән Габделбәр үзләренчә фикер алыштылар. Күк җисеменә Вакыт, гадәтенчә, иртәнге сәламын җиткерде.

– Нихәл, Кояш. Аллаһы тарафыннан йөкләтелгән бурычыңны тагы да иренер-иренмәс кенә башкарасыңмы?

– Иренсәң дә, иренмәсәң дә башкарырга кирәк бит инде дип әйттем сиңа, ләбаса. Тик бу эшемнең әллә мәгънәсе бар, әллә юк дип кайвакыт эчем генә поша. Җирдә, мин яктырткангa шатланып кайвакыт котырып китәләр. Сугыш чыгаралыр, яшилләр-яшилләр дә, кайвакыт котырып китәләр. Сугыш чыгаралыр, бер-берсен үтерешәләр, хәрамлашалар, алдашалар, комсызланып бер-берсенең азыгын ашыйлар… Син аларны бер селкетеп алырга да вәгъдә иткән идең түгелме?

– Уйлаган идем. Чак кына тетрәттем дә.

– Нәрсә? Мәскәүнеме, Нью-Йоркнымы, әллә Токионымы?

– Юк, аларны тетрәтсәм, эшнең зурга китүеннән курктым. Тетрәтүемне бер-берсенә япсарып, ядро сугышы башлап җибәрерләр, кырылышып бетәрләр дә, ул вакытта инде аларга синең дә минем дә кирәгем калмас.

– Синеке дә дөрес.

– Чираттагы тәҗрибәмне урыс илендәге кечкенә Бидрәш дигән шәһәр өстендә эшләдем.

– Шуннан? Үзгәрдеме соң ул шәһәрдәге хәлләр.

– И Кояш! Үзгәрмәде шул! Эшләмәгәне һаман эшләми, алдаганы һаман алдый, урлаганы һаман урлый.

– Карале, Вакыт, бәлки, кодрәтлеләрдән кодрәтле хуҗабызга мөрәҗәгать итәргә кирәктер. Заманында урыс иленең башлыгы итеп кемне җибәргән иде әле?

– Кемне булсын, Сталинны инде.

– Тагын җибәрсен Җиргә шундыйрак хакимне. Әйдә, асасыларын ассын, атасыларын атсын, утыртасыларын утыртсын!

– Ходабыз – мәрхәмәтле, алай эшләмәс. Кешелек табигый юл белән үсәргә тиеш, дип исәпли ул. – Вакыт тагы әлеге усал шаяртуын исенә төшерде. – Хәер, Кояш, озак көтәсең калмады бит инде. Алты миллиард ел гына. Син сүнәчәксең, кешелек барлык бөек эшләре һәм бозыклыклары белән бергә юкка чыгачак…

…Автор тагы фәстерә, Кояш та, Вакыт та сөйләшә белмиләр дип, менә битләрләргә ашыкма, хөрмәтле укучы. Аларның сөйләшә белмәгәнен без кайдан белик. Ничәмә гасырлар фани дөньяда яшәп кешелек бит әле Кояш телен генә түгел чыпчык телен дә анларга өйрәнә алмаган. Ә чыпчыклар сөйләшә белә. Туйдырткычларына җем салганда үзем тыңлап торганым бар.

– Бу карт – дөньядагы иң игелекле чыпчыкларның берселәр, агай-эне.

– Әйтергә генә дә түгел, зур рәхмәт инде аңа, көн саен безне туендыра. Ач булсак, бу чатлама суыкта кырылып та бетәр идек әле.

– Кеше атлы игелекле чыпчыкка дан! Игелекле чыпчыкка дан!

– Әйдәгез, җәмәгать, аңа рәхмәтләребезне җиткердек, чукый башлыйк инде булмаса.

– Башладык. Туендыргычы таррак, шуңа күрә әйдә чиратлап чукыйк. Беребезнең бүксәсе дә беребезнекеннән артык түгел. Барыбызга да җитәр…

Ә мин, башка әллә ни бөек эшләрем булмагач, «Игелекле чыпчык» булуым белән горурланып, аларның сыйлануын күзәтәм.

Зәмзәмбикә карчык тавыкларының сөйләшүен без алда тасвирлап киткән идек инде.

Җиһандагы барлык җан ияләренең, үсемлекләрнең, туфракның, җансыз саналган ташлар, планеталар, йолдызларның сөйләшә, серләшә белүенә тагы да бер дәлилем бар. Кешелекнең иң күренекле галимнәре әле мөхитебез, булмышыбызның бары дүрт процент чамасын гына өйрәнә алганбыз дип исәпли. Язмабыз герое Фарук Әюповның дусты астрофизик Блюменталь дә шул ук фикердә. Ә калган туксан алты процент серләр? Тоташ сер! Шул исәптә аралашуыбыз ысуллары. Аларны кемнәр ачар да, кайчан ачарлар? Бер генә нәрсә безне тынычландыра. Алда башланмаган алты миллиард ел гомеребез бар бит әле…



Фарук Йосыфович, Габделбәр карт, Хөршидә, Бакыйлар белән хушлачкач, кайтуы ягына юнәлмәде әле. Шәһәр хакимиятына барып Гапсатаров белән хушлашмаса, әлеге миссиясе тәгамләнмәс кебек тоела иде.

Гапсатаров иртәнге оперативкасын тәмамлаган. Аның кабинетыннан кайсысы елмаеп, кайсысы ыржаеп дигәндәй хезмәткәрләре чыгалар. Елмайсалар да, ыржайсалар да йөзләренә эшкә атлыгып торган кыяфәт чыгарырга тырышалар.

Руфина ханым кереп әйткәч, Гапсатаров кабинетыннан үзе чыкты. Кунакны култыклап дигәндәй эчкә алып кереп китте.

– Рәхим итегез, рәхим итегез, Әюпов әфәнде. Хәзер мин тиз генә чәй өстәле әзерләтәм.

– Юк, – диде Фарук Йосыфович коры гына. – Чәйләп-мәйләп утырырга форсатым юк, Энгель Заһидуллович. Кайтырга кузгалдым. Командировкамның вакыты бетте.

– Ничек соң, Фарук Йосыфович, командировкагыз җимешле булдымы?

Кунак кабинет хуҗасына сораулы карашын ташлады.

– Әкиятләр, табышмаклар җыюыгыз дим инде…

– Ә-ә-ә. Җыйдым. Әкиятләрен дә күп җыйдым. Табышмаклар да күп.

– Андагы фәнни җитәкчеләрегез эшегез нәтиҗәләреннән риза булырлармы соң.

– Анысы инде, Энгель Заһидуллович, аларның эше.

Гапсатаровның «риза булырлар» дигән сүзне ишетәсе килгән иде. Аның йөзе караңгылана бирде.

– Менә җылы каршы алуыгыз өчен рәхмәт. Картларга игътибар күрсәтә белүегез дә миңа ошады. Ә инде Бидрәш мәчетенең манарасын күтәрүгә, шәһәребез турында китап чыгаруга күрсәткән матди ярдәмегез өчен бигрәк тә зур рәхмәт.

Бу сүзләрдән Гапсатаровның авызы ачылып китте.

– Нинди мәчет, нинди ярдәм? – дип чак кына ычкындырмый калды. – Кулдан килгәнчә, кулдан килгәнчә инде, Фарук Йосыфович… – дип мыгырданды.

– Музей бинасын ремонтлап, аның алдына шәһәребезнең даны, шагыйрь Бәшир Бидрәшигә һәйкәл куйдырырга да кулыгыздан килер дип ышанам. Хушыгыз…

Фарук Йосыфович чыгып китте. Гапсатаров, ачык авызын ябарга онытып, аны озатырга да чыгалмый торып калды.

70-00

Литературно-художественное издание

**_Акберов Закир Насырович_**

**_Запах денег_**

Повесть и сатирический роман
(На татарском языке)

Әдәби-нәфис басма

**_Әкбәров Закир Насыйр улы_**

**_Акча исе_**

Повесть һәм сатирик роман
(Татар телендә)

Мөхәррире Рима.Арсланова.
Версткалаучы, бизәүчесе, макетлаучы Зилә Насыйрова.
Корректоры Рәсимә Хажиева.

Отпечатано в типографии ИП Ахмедов И. А. 8-905-000-11-22.
г. Кумертау, ул. М. Гафури, 26.

